ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№09 (380)
СЕНТЯБРЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ХАЛЫКЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ ФОРУМНАР

№09 (380)
СЕНТЯБРЬ 2023

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК АРАЛАШУДАН БАШЛАНА

Сентябрь аенда Татарстан Кытайдан кунаклар кабул итте. «РОСТКИ» Халыкара бизнес-форумы Россия төбәкләре һәм Кытай провинцияләре арасында икътисадый хезмәттәшлекне үстерү өчен ел саен үткәрелә торган мәйданчык булды. «Татарстан» килгән кунаклар белән аралашты һәм кытай теленең никадәр образлы, матур булуына гаҗәпләнде. Хәтта саннар, процентлар һәм фаразлар белән тулы җитди икътисадый темаларга сөйләгәндә дә, кытайлар үзләренең гасырлар дәвамында тупланган зирәк гыйбарәләрен куллана икән. Канатлы сүзләрнең кайберләре безнең мәкаль һәм әйтемнәргә бик тә охшаш. Сезнең игътибарыгызга да шуларның кайберләрен тәкъдим итәбез:

欲速则不达
Әгәр тизлек артыннан кусаң, теләгеңә ирешә алмассың!
(Ашыккан ашка пешкән.)

凡人不可貌相，海水不可斗量
Кеше турында тышкы кыяфәте буенча фикер йөртмиләр, диңгезне чүмечләп үлчәмиләр.
(Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар.)

只要功夫深，铁杵磨成针
Әгәр сез зур тырышлык белән эшләсәгез, тимер кендекне дә энә зурлыгында калдыра аласыз.
(Тырышлык һәр авырлыкны җиңә.)

种瓜得瓜，种豆得豆
Кавын утыртсаң – кавын алырсың, ногыт чәчсәң – ногыт җыярсың.
(Ни чәчсәң, шуны урырсың.)

三思而后行
Өч кат уйлагач кына, эшли башла.
(Җиде кат үлчә, бер кат кис.)

Сезнең редакция

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Сафа Гәрәев, Богдан Ткаченко, Илдус Заһидуллин, Ихтыяр Кыямов, Әхмәт Шакиров, Луиза Янсуар, Елена Симакова, Ульяна Макарчикова
Фотографлар: Александр Ефремов, Тимур Яковлев
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Лиана Баһавиева, «ТР эшлекле хатын-кызлары» бизнес-клубы президенты һәм идея илһамчысы.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–2452
Басарга кул куелды: 11.09.2023
Чыгу көне: 15.09.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 102 ЯШЬ

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

\# БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

СЫЧУАНЬ ПРОВИНЦИЯСЕНДӘ ТАТАРСТАН ПОЧМАГЫ

Кытайның Чэнду шәһәреннән Казанга кадәр туры юлдан – 5074 километр. Ара ераклыгы Сычуань провинциясендә яшәүчеләргә һәм кунакларга Татарстан, аның икътисады һәм мәдәнияте белән танышырга комачауламый. Күптән түгел генә Чэндуда чит ил тугандаш шәһәрләре музее ачылды, һәм анда Татарстанның даими экспозициясе дә урнаштырылды. Экспонатлар арасында татар милли костюмнары һәм аяк киемнәре, курай, татар бизәнү әйберләре һәм чигешләре, түбәтәй, калфак, милли орнаментлы савыт-саба, шулай ук Ми-38 вертолёты һәм «КАМАЗ» макеты бар. Казан Кремленең кечкенә күчермәсе һәм, әлбәттә, чәкчәк тә куелган. Татарстан белән Сычуань провинциясе арасында тугандашлык мөнәсәбәтләре урнаштыру турындагы килешү инде җиде ел гамәлдә, ТРның Чэндуда даими экспозициясе – булган элемтәләрне ныгыту өчен тагын бер мөмкинлек. Чит ил тугандаш шәһәрләре музее көн саен ачык, анда керү бушлай.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Россия – Кытай хезмәттәшлеге
Казанда узган халыкара икътисадый форумнан нәрсәләр көтәбез

6. «Хайер», «Вейчай», «Камасталь» һәм башкалар
Татарстанда Кытай компанияләре белән нинди уртак проектлар тормышка ашырыла

8. Тизләнеш төймәсенә басылды
Татарстан белән Кытай хезмәттәшлегенә нәрсә ярдәм итәр

14. Аш-су
Кытай ризыкларының сере нәрсәдә

20. Юлбашчы утырган партада
Казан кай ягы белән Кытай туристларын үзенә тарта

игелекле эшләр

38. Миллион сумны ал һәм бәхетле бул
Хобби ничек тормыш мәгънәсенә әверелә

40. Ипи пешерү бизнесы
Ни өчен аның хуҗасы төннәрен йокламый

42. Миллион сумлык хобби
Мавыгу ни рәвешле бизнеска әйләнә

46. Студент стартабының бәясе
Миллион сумга балаларны ничек бөер авыруыннан коткарырга

48. Гамьле әңгәмә
«Мәскәүдәге бер татарның да миңа русча эндәшкәне юк!»

52. Әбидә кунакта
Чабагач белән нәрсә эшләгәннәр

мәңгелек кыйммәтләр

56. Җирдә түгелсең кебек!
«Татарстан» фотохәбәрчесе кайларда булды

68. Тарихи сәхифә
Кызыл комиссар Шамил Усманов

80. Татар авыллары
Нарат-Елга – тырышкан хур булмас!

86. Афиша
Кайда нәрсә карарга мөмкин

88. Җәйне озату
Республика көне ничек үтте

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: russian-chinse.com

Акыллы гамәлләр

24.08

Сергей Собянин, Россия башкаласы мэры, – Мәскәүдә традицион Татарстан көннәренә багышланган концертта:

– «Без бергә» дигән сүзләр ил авырлыклар кичергәндә бигрәк тә мөһим, без бүген фактта сугыш халәтендә. Мәскәү һәм Татарстан кебек көчле төбәкләр илебезнең оборона-сәнәгать комплексының гына түгел, икътисадның да таянычы булып тора. Җиңүгә юл безнең ничек эшләвебездән, безнең ничек бергә эшләвебездән тора.

08.08

Марат Хөснуллин, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Югары Ослан районында, «Көнчыгыш» М-12 трассасының Идел елгасы аша төзелә торган күпере янында:

– Сентябрьдә без Арзамаска кадәрге юлны ачарга планлаштырабыз. Бу инде юлның яртысы диярлек. Ә инде ел азагына Казанга кадәр юлны тулысынча ачарбыз дип өметләнәбез. 2024 елда Екатеринбург белән элемтәне ачарга тиешбез. Һәм инде 2025 елда – Төмән белән. Бүген биредә Татарстан Республикасында иң зур ясалма күпер корылмасының бер өлешендәге эшләр вакытыннан алда тәгәлләнә. Яңа күпер Иделнең Казан янындагы уң як яры инфраструктурасы үсешенә этәргеч бирәчәк. Шулай ук елга аша гамәлдәге транспорт трассасына йөкләнешне дә шактый-га киметәчәк.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр



09.08

Данис Зарипов, хоккей буенча өч мәртәбә дөнья чемпионы, Гагарин Кубогына биш тапкыр ия булган бердәнбер уенчы, – «Татнефть Арена»да хушлашу матчында:

– Нәрсә белән горурланам дигәндә, үземнең ихтыяр көчем, теләгем белән. Бүген мин иң зур титулларга ия уенчыларның берсе. Мин үземә аннан-моннан уйнамаганым, кистермәгәнем, хәрәмләшмәгәнем һәм бөтен көчемә эшләгәнем өчен рәхмәтле.

Фото: tatar-inform.ru, sobyanin.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

төп тема

Бу санда тәкъдим итәбез:

Казанда **нинди** халыкара форум узды

Татарстан һәм Кытай **нинди** уртак проектларны гамәлгә ашыра

ТР белән Кытай хезмәттәшлегенә **нәрсә** ярдәм итәр

Кытай ризыкларының сере **нәрсәдә**

Казан **кай** ягы белән Кытай туристларын үзенә тарта

«РОСТКИ: РОССИЯ ҺӘМ КЫТАЙ – ҮЗАРА ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК»

КАЗАН

«РОСТКИ» – ул Россия төбәкләре һәм Кытай провинцияләре арасындагы икътисадый хезмәттәшлекне үстерү максатында ел саен үткәрелә торган яңа мәйданчык

«РОСТКИ»

русча өч сүздән ясалган: Россия, Татарстан (уздырылу урыны), Китай

3000нән артык –

катнашучылар саны

Кытайдан 19 рәсми делегация

форумда катнашачакларын раслады һәм түбәндәге Кытай шәһәрләре һәм төбәкләреннән Татарстан башкаласына киләчәк:

Ханчжоу, Шэньчжэнь, Чэнду, Юйхуань, Вэнлинь, Мэйшань, Дэян, Сиань, Дунъин, Ляньшань, Нэйцзян, Ляочэн, Гуанъюань, Пэнчжоу, Цицикар, Гуанчжоу, Маньчжурия.

Россия предприятиеләренең Кытай партнерларыннан

бизнес-делегацияләр булачак.

Катнашучылар арасында:

Шанхайдагы Рус-Азия сәнәгатьчеләре һәм эшкуарлары берлеге, Машина төзелеше һәм электрон продукция импорты һәм экспорты буенча Кытай сәүдә палатасы, China Daqing International Industry and Trade Company Халыкара сәүдә компаниясе, Shengli oilfield kangbei petroleum engineering and equipment co., ltd, Qingdao huixin international trade co., ltd.

ХАЛЫКАРА ФОРУМЫ

2023 елның 7–8 сентябре

42 эшлекле сессия
«РОСТКИ» форумы кысаларында узачак

Игътибар үзәгендә –
мәгълүмат технологияләре, машина төзелеше, финанслар, транспорт, туризм, мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт, мәгариф, инвестицияләр

«Россия–Кытай: икътисадый якынаю, зур проектлар, инфраструктура перспективалары»
пленар утырыш темасы

«РОСТКИ»: ихтимал булган нәтиҗәлелек –
яңа инвестицияле проектларны гамәлгә ашыру һәм Кытай партнёрлары белән уртак җитештерүләр ачу

Шәһәрләрне берләштерүче форум
шул ук көннәрдә үтәчәк һәм бөтен дөньядан **150** гә якын җирле хакимият вәкилен җыячак

Russia – China Expo Халыкара күргәзмәсе
РФ белән КХР арасындагы сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек турында сөйләячәк

Экспозициядә – 30 дан артык Кытай автомобиле моделе,
аларның мөмкинлекләрен тест-драйв вакытында сынап карап булачак

Форум көннәрендә узачак:

- «Ак барс» – «Куньлунь Ред Стар» Континенталь хоккей лигасының даими матчы;
- Россия–Кытай дуслыгы яшьләр фестивале;
- Көнчыгыш һәм милли көрәш осталарының күрсәтмә чыгышлары;
- Кытайның Вэйци борынгы уеннары турнирлары;
- Кытай киносы фестивале;
- Нобель премиясе лауреаты Мо Янь әсәре буенча куелган «Наш Цзинь Кэ» спектакле;
- Россиядәге Кытай студентлары көче белән әзерләнгән бөтендөнья музыка мирасы концерты;
- Кытай чәй церемониясе серләре белән таныштыру.



ТАТАРСТАН–ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

1 600 000 000 $ артык

2022 елда Татарстан белән КХР арасындагы товар әйләнеше шул күләмдә

Узган ел белән чагыштырганда үсеш

58 %тан артык

740 000 000 $

2023 елның I кварталында Татарстан белән Кытай арасындагы товар әйләнеше

Татарстанда «Хайер», «Вейчай», «Камасталь», «Хуавей», «Мидеа» һ.б компанияләр белән **уртак икътисадый проектлар** тормышка ашырыла

Хезмәттәшлек турында

7 килешү

Татарстан белән Кытайның

Шаньдун,

Сычуань,

Хунань,

Аньхой,

Чжэцзян,

Хэйлунцзян,

Чунцин шәһәре

арасында гамәлдә

Хезмәттәшлек турында

14 килешү

ТР муниципаль берәмлекләре һәм КХР арасында имзаланган

Дэн Сяопин исем. логистика комплексы

«Алабуга» МИЗнда төзелә. Россиядә иң зур шундый комплексларның берсе Кытайдан йөкләрне кабул итәчәк һәм «Этилен 600» индустриаль паркы территориясендә җитештерелгән полимерларны кире юнәлештә җибәрәчәк. Терминалның проект куәте – елына 100 000 контейнер

КЫТАЙ.
КЫРЛАРЫ

Татарстан белән Сычуань провинциясе

тугандашлык мөнәсәбәтләре турындагы килешү нигезендә хезмәттәшлек итә

Казанның тугандашлары һәм партнёрлары булган КХР шәһәрләре

Цицикар, Сиань, Чэнду, Шэньчжэнь, Ханчжоу, Гуанчжоу

---

1 600дән артык Кытай гражданы

КФУда белем ала

523 фәнни эш –

биш ел эчендә Казан университеты хезмәткәрләре Кытай фәнни-мәгариф үзәкләрендәге коллегалары белән шулкадәр уртак эш бастырып чыгарды. Бу физика һәм астрономия, Җир һәм планеталар турындагы фән, авыл хуҗалыгы һәм биология фәннәре, химия, әйләнә-тирә мохит турындагы фәннәргә караган тикшеренүләр

КФУның 15 хезмәткәре

КХР гражданнары

785 Кытай гражданы

үз анкеталарында яңа уку елына кабул итү кампаниясе барышында* РФ Хөкүмәте квотасы буенча ТР вузларында укырга теләүләрен белдерде

Пекинда

ТРның КХРдагы сәүдә-икътисадый вәкиллеге эшли

Казанда

КХРның Генераль консуллыгы ачылды

* Кабул итү кампаниясенең якынча йомгаклары буенча

向波《中俄地方合作已按下"加速键"》

Сян Бо:

«ИЛЛӘРЕБЕЗ АРАСЫНДА ТӨБӘКАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕ ТИЗЛӘТҮ ТӨЙМӘСЕНӘ ИНДЕ БАСЫЛДЫ»

Фото: Александр Ефремов, tatar-inform.ru

Әхмәт Шакиров

Татарстан һәм Кытай компанияләре арасында хезмәттәшлек перспективалары нинди? Кытайда Сабан туе уткәрү мөмкинме? Татарстанда яшәүче кытайлар үзләрен ничек хис итә? Татарстан Республикасына Кытайдан оешкан туристлар төркеме кайчан килә башлаячак? ТР башкаласында Кытай киносы фестивалендә нинди фильмны карарга кирәк? Әлеге һәм башка сорауларга Кытай Халык Республикасының Казандагы Генераль консулы җавап бирә.

ҮЗАРА МӘНФӘГАТЬЛӘР: ЭЛЕКТРОМОБИЛЬДӘН АЛЫП АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА КАДӘР

– Татарстанда Кытай белән хезмәттәшлектә тормышка ашырыла торган уңышлы проектлар арасында Яр Чаллы һәм Алабугадагы Haier заводлары, автомобильләр җитештерүе бар. Тагын кайсы өлкәләрдә үзара хезмәттәшлек алып барырга була? Бу юнәлештә нинди перспективалар бар?

– Кытай – Россия арасындагы киң күләмле партнерлык һәм стратегик хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре яңа эпохада моңарчы күрелмәгән югары ноктага җитте. Ике яклы мөнәсәбәтләр үсешенә КХР рәисе Си Цзиньпин белән РФ Президенты Владимир Путинның март аенда Мәскәүдә узган очрашуы көчле импульс бирде. Хәзер ике ил арасындагы төрле өлкәләрдә хезмәттәшлек күләм ягыннан да, сыйфат буенча да үсүен дәвам итә. Илләребез арасында төбәкара хезмәттәшлекне тизләтү төймәсенә инде басылды.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең мөһим субъекты булып тора. Аның территориясендә КАМАЗ һәм Казан авиация заводы кебек традицион сәнәгать тармаклары предприятиеләре, шулай ук Россиянең төп инновацияле парклары: «Алабуга» махсус икътисадый зонасы һәм «Иннополис» инновацияле зонасы урнашкан. Соңгы елларда Татарстан белән Кытай төбәкләре арасында хезмәттәшлек актив үсеш ала, товар әйләнеше шактый үсте. 2022 елда сәүдә күләме 1,6 миллиард АКШ долларына җитте, бер ел эчендә 58 %ка артты, бу – тарихи рекорд. Haier һәм Midea кебек Кытай корпорацияләре инвестицияләр кертү һәм үз бизнесларын үстерү мәйданчыгы буларак Татарстан Республикасын сайлыйлар.

Кытай һәм Россия арасында ике яклы мөнәсәбәтләрнең тиз үсеше төбәк дәрәҗәсендә хезмәттәшлек итү өчен дә яңа мөмкинлекләр ача. Аның алга таба үсеш юллары турында ике илнең төбәкләре һәм компанияләре вәкилләре «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы кысаларында фикер алышачак. Перспективалы юнәлешләр арасында – станоклар төзелеше, авыл хуҗалыгы машиналары төзелеше, төп комплектлаучылар, электроника, көнкүреш

техникасы, транспорт логистикасы, төрле энергия чыганакларында транспорт чаралары җитештерү һәм башкалар. Ике якның да кызыксынуын уяткан өлкәләрнең берсе, мәсәлән, электр автомобильләре җитештерү. Кытай әлеге юнәлештә алдынгы позицияләрне били, Россия, үз чиратында, яңа энергетика транспорт чараларын үстерүне хуплый. Татарстан компанияләре электр автомобильләрен эшләү белән актив шөгыльләнә. Шуңа күрә ике як предприятиеләре дә әлеге өлкәдә хезмәттәшлек перспективаларын карый һәм яңа энергетика транспорт чаралары базарында тәҗрибә уртаклаша ала.

Авыл хуҗалыгы, экология кебек өлкәләрдә дә зур хезмәттәшлек потенциалы бар. Узган ел ике ил арасында авыл хуҗалыгы продукциясе белән сәүдә итү күләме 41,8 %ка арткан. Күп еллар дәвамында Кытай Россиянең авыл хуҗалыгы продукциясе һәм ит буенча иң эре экспортеры булып тора. КХР Генераль консуллыгы элемтәләр урнаштыруга актив ярдәм итәчәк һәм икътисад, сәүдә һәм инвестицияләр өлкәсендә яклар арасында хезмәттәшлекне үстерүгә ярдәм итәчәк.

КЫТАЙДА САБАН ТУЕ? НИК БУЛМАСЫН, ДИ!

– Россия белән Кытай арасында килешенгән нинди мәдәни проектлар Татарстанда тормышка ашырыла?

– Бу ел Татарстан Республикасында милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы булып тора. КХР Генераль консуллыгы Кытай белән Татарстан Республикасы арасындагы мәдәни элемтәләргә аерым игътибар күрсәтә, аларның үсешенә актив ярдәм итә. Ел башыннан без кытай теле буенча «Кытай күпере» конкурсы, «Халыкара кытай теле көне», Казанда вейци (го) буенча КХР Генераль консуллыгы Кубогының дүртенче уеннары, «Кытай аждаһа көймәләре бәйрәме» кебек чараларны матур итеп уздырдык. Әлеге чаралар дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытуга, ике як арасында үзара аңлашуны тирәнәйтүгә ярдәм итә, дип уйлыйм. Аерым алганда, Сабан туе бәйрәме вакытында Татарстанда безнең традицион «Аждаһа көймәләре бәйрәме» үткәрелде, сез аны «Кытай Сабан туе» дип атадыгыз. Анда 20 җирле команда катнашты, ә тамашаны 15 меңнән артык кеше карады. Бәйрәм барлык катнашучыларга

Кытай, Россия һәм Татарстан арасындагы мәдәни чараларның кабатланмас рухын тоярга мөмкинлек бирде.

Сентябрь башында КХР Генераль консуллыгы, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм «Татарфильм» кинокомпаниясе белән берлектә, Казанда Кытай киносы фестивален оештыра. Фестиваль программасы кысаларында тамашачылар Кытайның алты танылган кинофильмын күрәчәк, алар арасында культ дәрәҗәсендәге «Өйгә кайту» (Home Coming) фильмы да бар. Без Россиядәге дусларыбызны әлеге чарага килергә чакырабыз, бу Кытай мәдәниятен һәм сәнгатен тирәнрәк аңларга ярдәм итәчәк, дип уйлыйбыз. Кытай мәдәни төркемнәре шулай ук Казанда «СоТВОРЕНИЕ» Халыкара музыка фестивале һәм «Көнчыгыш базары» кебек чараларда катнашырга чакырылачак.

– Кытайда Сабан туе үткәрүгә ничек карыйсыз?

– Киләчәктә ике як та мәдәни-иҗади коллективлар юнәлеше, мәдәни һәм сәнгать күргәзмәләре оештыру, шулай ук музей эше өлкәсендә үзара хезмәттәшлек аша мәдәни алмашуларны ныгыту мөмкинлеген карый ала. Без шулай ук ике ил арасында үзара аңлашуны тирәнәйтү һәм дуслык бәйләнешләрен ныгыту максатыннан Кытай территориясендә Сабан туе бәйрәмен оештыру мөмкинлеген дә карый алабыз.

ТУРИСТЛАР ӨЧЕН СТИМУЛ БАЛАРАК БРИКС САММИТЫ

– Татарстанда Кытайдан килгән ничә кеше яши? Алар монда үзләрен ничек хис итә?

– Татарстан этник күптөрлелеге белән аерылып тора һәм төрле этник төркемнәрнең гармониядә яшәве үрнәге булып тора. Бүген республикада Кытай Халык Республикасыннан килгән 2200 граждан укый һәм эшли, шул исәптән 1900 студент һәм 300 эшкуар һәм Кытай предприятиеләре хезмәткәре. Төбәк хакимияте аларның белем һәм һөнәри үсеше өчен уңай шартлар тудыра. Татарстанда яшәүче Кытай гражданнары төбәкнең социаль-икътисадый үсешенә һәм ике ил арасында дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытуга актив ярдәм итә. Агымдагы елның март аенда Татарстан Республикасы ведомстволары ярдәме белән рәсми рәвештә Кытай берләшмәсе төзелде. Бу Татарстанда Кытай гражданнарын үзара бәйләп торучы үзенчәлекле звено, ул шулай ук Россиядәге дусларыбызны Кытай тарихы һәм мәдәнияте белән таныштырырга, ике ил арасында дусларча мөнәсәбәтләрне үстерергә ярдәм итә.

– Сезнеңчә, Татарстан Кытай туристлары өчен кызыклымы?

– Татарстан бай чал тарихка ия, ә Казан меңьеллык мирасы белән горурлана ала. Аның территориясендә бик күп борынгы һәйкәлләр бар. Бу Казан Кремле дә, борынгы чиркәүләр дә, мәчетләр дә һәм В.И. Ленинның музей-йорты да. Республикада төрле дин вәкилләре үзара татулыкта яши. Бу, әлбәттә, Кытай туристларын җәлеп итә.

Кытай ике ил арасындагы туристлык хезмәттәшлеген үстерүгә зур әһәмият бирә. Статистика буенча, 2019 елда пандемия башланганчы, Россиягә 2,25 миллион Кытай туристы килгән, шул ук вакытта 2,72 миллион Россия туристы Кытайда булган. Ике ил дә туристлар алмашуның мөһим чыганагы булып тора. Агымдагы елның февралендә Кытай пилот режимында үз гражданнары өчен берничә илгә төркемләп сәфәр кылу турларын яңартты, алар арасында Россия беренче егерме ил арасында иде. Күптән түгел Кытай һәм Россия туристлар төркемнәре өчен визасыз режимны яңадан эшләтеп җибәрде. Кытай–Россия туристлар алмашуы өчен ишек хәзер ачык, гәрчә аларны тулысынча торгызу этаплап башкарылырга тиеш булса да.

– Кытай туристларының оешкан төркемнәре Татарстанга кайчан килә башлаячак?

– Агымдагы ел башында мин туризм өлкәсендә хезмәттәшлекне тирәнәйтү һәм илләребезнең туристлык оешмалары арасындагы элемтәләрне ныгыту мәсьәләләрен тикшерү максатыннан Татарстан Республикасының рәсми вәкилләре һәм Казанның туризмны үстерү комитеты белән берничә очрашу үткәрдем. Киләсе елда Казанда БРИКС саммиты узачак, бу Казанга һәм Татарстанга тагын да күбрәк Кытай туристларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк. Кытай туристларының Татарстан Республикасына кызыксынуы арта гына барачагына ышанам.

БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ ТӘМНӘР ҺӘМ АШ-СУ ТУРЫНДА

– Татар ашлары сезгә ошыймы?

– Узган елның сентябрендә Казанга килгәннән бирле мин традицион татар ашлары, аерым алганда, сыер итеннән ясалган өчпочмак һәм баллы сый – чәкчәк кебек ризыкларны ашап карадым, алар миңа бик ошады.

– Ә татарстанлыларга нинди милли Кытай ризыгын тәмләп карарга киңәш итәр идегез?

– Кытай кулинария традицияләре тамырларының тирәнлеге һәм төрлелеге

белән аерылып тора. Аның формалашуына күп факторлар, шул исәптән җирле гореф-гадәтләр, климат һәм ризык әзерләү үзенчәлекләре йогынты ясаган. Бу сигез төп кулинария юнәлешенә китерә, аларның һәрберсе уникаль тәмгә ия. Мин Чунцин шәһәрендә тудым, аны еш кына «хого башкаласы» дип атыйлар. Чунцинның визит карточкасы булып чунцинча хого тора. Аш үзенең «әче, тозлы, хуш исле һәм кетердәвек» тәме белән аерылып тора. Аның үзенчәлеге – ингредиентларының төрлелегендә, уникаль тәмләткечләр куллануда һәм гадәти булмаган ысул белән табынга бирүдә. Чунцинча хого пешерү әллә ни зур осталык сорамый, аны һәркем өендә рәхәтләнеп әзерли ала. Россиядәге дусларымны Кытайда Чунцинга барырга, чунцинча хого ашап карарга һәм туган илемнең аш-су культурасы белән танышырга чакырам.

редакция кухнясы

КЫТАЙ ХАЛЫК АШЛАРЫНЫҢ ТӨП СЕРЕ

Татьяна Вафина

Пекинча үрдәкнең безнең Татарстанда пешерелгәненнән нәрсәсе белән аерылуын һәм «коры бәрәңге»нең фри бәрәңгесеннән ни өчен тәмлерәк булуын безгә чын кытай ашчылары Ван һәм Чжан аңлатты. Алар «Татарстан» журналын әлеге данлыклы (императорлар сые бит!) кытай ризыкларын әзерләргә өйрәтеп кенә калмыйча, милли ашларының төп серен дә ачты.

ВАННАН – «ПЕКИНЧА ҮРДӘК»

БАРЫСЫ ДА МӘХӘББӘТТӘН БАШЛАНГАН

Һәрвакыттагыча, барысы да саф мәхәббәттән башланган. КФУның Көнчыгыш телләре институты студенты Аида Демьянова кытай телен шундый шәп өйрәнгән ки, аның тавышы һәм искиткеч сөйкемлелеге бу вакытта Казанда укыган Юй исемле гади кытай егетен әсир иткән. Ә Юй исә Аиданы үзенең аш-суга осталыгы һәм кайгыртучанлыгы белән таң калдырган.

– Күз алдына китерә аласызмы, мин төнгә кадәр тәрҗемә итеп утырганда, ул миңа хәтта аш та пешереп килә иде... Гомумән, кытайларга безнең кызлар бик ошый. Алар, иң матур кызлар Россиядә яши, дип саный.

Законлы никахтан соң исә (ни генә дисәң дә, хатын-кыз йөрәгенә дә юл ашказаны аша салына шул!) гаилә Казанда яшәргә карар кыла һәм үз кафесын ачарга була.

КЫТАЙЛАР ХЫЯЛЫ БИК ГАДИ

– Эш шунда ки, башка илгә килеп урнашкан теләсә кайсы кытай анда кечкенә генә булса да үз ресторанын ачу турында хыялланa, – дип аңлата Аида. – Без дә иремнең хыялын тормышка ашырдык.

– Аларны биредә начар ашаталармыни? Әллә аларга безнең борщ һәм өчпочмак ошамыймы?

– Аларга барысы да бик ошый! – дип көлә Аида. Һәм гомумән, Кытайдан килгән туристларның милли аш-судан, беренче чиратта исә легендар өчпочмактан авыз итәсе килә. Әле алар тагын борщ, токмачлы ашны да бик ярата, токмач кулдан киселгән булса бигрәк тә. Әмма аларның икенче көнне үк үз милли ашларын ашыйсы килә башлый, безнең ризыклар аларга артык төче тоела. Алар әйтүенчә, бездә «тәмнәр аз» – тоз, борыч, ниндидер үләннәр һәм шуның белән вәссәлам, диләр. Алар исә бик күп тәмләткеч, борыч, төрле соуслар өстәп ашарга күнеккән... Гәрчә менә казылык һәм каклаган казны әллә ни өнәмиләр – аларны артык тозлыга саныйлар.

– Әйе шул... Безнең климатта эссе яратучан чит ил кешеләре шул борыч белән генә җылынса инде...

– Чынлыкта исә Юй – төньяк Кытайдан, – ди Аида. – Анда әле биредәгедән дә салкынрак. Шунлыктан безнең кояшлы Казаныбызда аңа бик рәхәт, ул туңмый.

Гомумән, кытайлар сыйланырга бик ярата. Төшке аш вакыты исә бөтенләй изге санала. Бөтен нәрсә туктап кала – Кытай төшке аш ашый. Шунлыктан анда «чшифанькалар» бик күп – тиз арада тәмле ашап була торган кечкенә кафеларны кытайлар шулай атап йөртә. Һәм алар тәмле ризык әзерләнгән җиргә генә йөри. Казанда исә ул чакта чын «Пекинча үрдәк» белән берничә урында гына сыйланып була иде, шунлыктан без үз кафебызны «Кытай үрдәге» дип атадык. Биредә без пекинча һәм кантонча үрдәк әзер-

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- үрдәк түшкәсе – 2–2,5 кг;
- тоз;
- тавык тәме килә торган тәмләткеч;
- дөге серкәсе;
- шикәр;
- «Биш тәмләткеч» кушылмасы:
  - сычуань борычы,
  - кытай дарчины,
  - бадьян,
  - канәфер,
  - фенхель.

Фото: Александр Ефремов

Әмма безнең каршыда инде юылган-йолкынган гына түгел, тиресе агарсын өчен шау кайнар су коелган үрдәк тора иде.

1 Тутырабыз

2 Әйләндерәбез

3 Сылыйбыз

4 Турыйбыз

5 Төрәбез

6 Табынга бирәбез

либез. Гомумән, кытай халык ашлары төп 8 төбәкнекенә бүленә. Иң гади һәм киң таралган ризык – йомырка белән кыздырылган дөге – сигез төрле әзерләнә ала, һәм аларның тәме бер-берсеннән аерылып тора.

ИМПЕРАТОРЛАР СЫЕ

Юйга ярдәмгә Кытайдан ике дустын чакырырга туры килә. Ван һәм Чжанны озак үгетлиләр, чөнки Кытайда яхшы ашчылар алтын бәясенә йөри бит.

Һәм менә инде хәзер Ван, махсус элмәкләргә асып куелган үрдәгән тоткан килеш, безне Кытайда иң популяр булган һәм иң борынгы саналган ризыкны пешерү серләренә өйрәтергә әзер. Аны императорның шәхси ашчысы моннан җиде гасыр элек уйлап тапкан бит. Эш Шаньдунь провинциясендә, Пекинда булган. Исеме дә шуннан килә. Шулай бит?

Ван безнең интернеттан алган «гыйлемебезне» елмаеп тыңлап тора һәм үзе белгәннәр белән уртаклаша.

АШ-СУ МӘДӘНИЯТЕ ҮЗӘГЕ

Кытайча белмәүчеләргә Аида аның бик матур, әмма бормалы-сырмалы һәм иероглифлар кебек үк аңлаешсыз сөйләмен тәрҗемә итеп тора:

– «Пекинча үрдәк» Юань династиясе чорында әзерләнә башлый. Бу – монголлар династиясе, ул яулап алынган Кытай белән 1271–1368 елларда хакимлек иткән. Ашчы Ху Сыхуэй императорны сыйлап кына калмаган, бәлки аны әзерләүне «Тукланунын иң мөһим серләре» дигән хезмәтендә тасвирлап та калдырган.

Соңрак хакимлек Мин династиясенә күчкән, һәм нәкъ менә шул вакытта Пекин Кытайның башкаласына һәм кулинария мәдәнияте үзәгенә әйләнгән. Ашчы Ху Сыхуэй үрдәге исә император табынының төп ризыгы саналган, аннары исә Цин династиясенә «мирас булып» күчкән.

Ике династия ашчылары да башта үрдәкне хәзерге барбекю миченә охшаган ачык утта кыздыра торган була. Соңрак кытайлар ябык мичтә (плитәдә) пешерә башлаган – анда ялкын һәм җылылык яхшырак саклана, нәтиҗәдә үрдәкнең тиресе тагын да кетерди торганга әйләнә – бу исә «Пекинча үрдәк»нең төп үзенчәлеге санала. Цин династиясе вакытында үрдәк император табыннан Пекин ресторннарына да күчә. Quanjude кебек атаклы рестораннар нәкъ менә Цин династиясе хакимлеге чорында ачыла һәм хәзергә кадәр бөтен дөньяда иң тәмле «Пекинча үрдәк» әзерләнә торган урын санала.

ХӘЗЕР ҮРДӘКНЕҢ ҮЗЕ ТУРЫНДА

Әгәр дә без үрдәкне Кытайда әзерләсәк, шул ризык өчен махсус чыгарылган Пекин токымы кошын сатып алыр идек. Бу бик зур һәм комсыз кош. Әмма Татарстан үрдәген дә, оста әзерләгәндә, Пекиннныкына әйләндереп була! Иң мөһиме, аны дөрес итеп юу һәм... йолку!

Әмма безнең каршыда инде юылган-йолкынган гына түгел, тиресе агарсын өчен шау кайнар су коелган үрдәк тора иде.

Императорлар сые бик гади, әмма озак – ике тәүлеккә якын әзерләнә: башта үрдәкнең эченә тәмләткечләр тутырырга һәм тоз белән яхшылап ышкырга кирәк. Аннары аны 12 сәгатькә шешәгә «утырталар». Шуннан соң, матур карамель төсенә керсен өчен, тиресенә серкә һәм шикәр кушылмасы сөртәләр һәм тагын берничә сәгатькә калдыралар.



Ван бик оста итеп үрдәкне юка кисәкләргә турый. Һәр кисәктә калган тире никадәр калынрак һәм кетердәвегрәк булса, үрдәк шулкадәр тәмлерәк санала.

ЧЖАННАН – «КОРЫ ЧҮЛМӘКТӘГЕ БӘРӘҢГЕ»

Үрдәк әзерләнгән арада без икенче ашчы Чжан белән танышабыз. Ванның квалификациясе «үрдәк» булса (бу коштан ул теләсә нәрсә әзерли ала, безне дә әллә ничә төрле үрдәк ите, аш һәм коймак белән сыйларга җыена), Чжан – коры чүлмәктәге бәрәңге пешерү остасы. Һәм гомумән, кытай ашчыларының һәркайсының үз белгечлеге: «үрдәк» ашчысы бәрәңге әзерләмәяәк һәм киресенчә.

Ашчы россиялеләрнең яраткан тамыразыгын әрчеп, юка телемнәргә тураган арада Чжанның да Кытайның төньягында – Хэйлунцзян провинциясендә туып-үсүен ачыклыйбыз.

Ул балачагыннан ук пешеренергә бик яраткан һәм үзенең әнисенең әнисенә (вайпо) бөтен гаиләгә төшке аш әзерләргә сәгатьләр буе рәхәтләнеп булышкан. Чжанның йөрәгендә бүгенгә кадәр әбисе парда пешергән бөккән – баоцзы тәме саклана, ул иртән мәктәпкә шуны ашап китә торган була. Малай бигрәк тә бәйрәм көннәрен яраткан, ул чакта бөтен зур гаилә бергә җыелган... Табын төрле ризыклардан сыгылып торган, әмма ул чакта һәм хәзергә кадәр иң яратканы гобажоу – әчкелтем-татлы соуста пешкән ит икән.

– Бу – Мао Цзедунның яраткан ризыгы, – дип өсти Аида. – Һәм минеке дә.

Мәктәпне тәмамлагач, Чжан үзен тулысынча кулинариягә багышларга була һәм Тели шәһәрендәге «ашчылык сәнгате» курсларына укырга керә. Аннары Хиндунфан шәһәрендәге кулинария мәктәбендә тагын бер курста укый. Яшь ашчыны диңгез ризыкларын әзерләүгә махсуслашкан «Санхе» рестораныңа эшкә чакыралар. Аннары ул «Сиху» ресторанында, аннан соң Пекинда эшли...

– Быелдан исә ул безнең кунакларны сыйлый, – дип өсти Аида.

КАЛПАК БАШКА

Казанда Чжанга үзенең калпагыннан башка бөтен нәрсә ошый икән.

– Кытайда калпаклар башка төрле, биегрәк, – дип телефонындагы фотосын күрсәтә ул безгә. Чыннан да, андый калпак ашчыбызга күбрәк килешә кебек.

– Әмма, – дип ышандыра безне Аида, – калпакның биеклеге бәрәңгенең тәменә бернинди дә зыян китермәячәк!

Һәм без калпагы турында инде оныткан Чжанның бәрәңге тамашасы күрсәтүен йотлыгып күзәтергә керешәбез.

– Кытай ашларының төп үзенчәлеге – ризыкның тәме аерып булмаслык булуда, – дип аңлата Аида.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- бәрәңге;
- башлы суган;
- борыч;
- лотос тамыры;
- тоз;
- сычуань борычы.

«Коры чүлмәк» – кытай халык ашларын табынга бирүнең популяр формасы. Ризык ут өстендәге махсус чүлмәктә сыеклыксыз әзерләнә.

– Кытайда калпаклар башка төрле, биегрәк, – дип телефонындагы фотосын күрсәтә ул безгә. Чыннан да, андый калпак ашчыбызга күбрәк килешә кебек.

БИШ МИНУТ ЭЧЕНДӘ!

Бәрәңге түгәрәкләп киселә. Аңа бишкә бер нисбәтеннән башлы суган, борыч һәм лотос тамыры да турала.

Иң кызыгы – эш процессын күзәтү: Чжан бәрәңгене майда кыздырганда, өскә чөеп җибәрә, түгәрәкләр очып, икенче ягына әйләнеп килеп төшә, бәрәңге янына әле суган, әле борыч, әле лотос тамыры, әле тәмләткечләр шулай ук очышта кушыла тора...

Биш минутта инде бөтенесе дә әзер диярлек! Бу юлы әйләндергәндә бәрәңгебез инде чүлмәккә салына, ул исә махсус плитәгә куела һәм шуның өстендә, чыжылдый-чыжылдый, пар бөркегән, искиткеч хуш исләр тараткан килеш, кунакларга бирелә.

Нәрсә әйтик инде? «Татарстан»ның бик күп төрле бәрәңгедән авыз иткәне бар, әмма мондыйны әле беренче тапкыр ашавы. Дөньяда моннан да тәмлерәк бәрәңге була алмый!

1 Кыздырабыз

4 Кыздырабыз

2 Алабыз

5 Кушабыз

3 Өстибез

5 Сибәбез



Чжан татарстанлыларга кытайлардан ялкынлы тәмле сәлам тапшыра.

ҮРДӘККӘ ӘЙЛӘНЕП КАЙТАБЫЗ

Бер тәүлектән соң, үрдәк ите хуш исле маринадны яхшылап сеңдергәч, аны пешерүгә керешәләр. Ван газ мичен 250 градуска җылыта. 40-45 минут шул температурада пешерә. Аннары кошны әйләндерә һәм 160 градуста тагын бер сәгать тота. Аннан соң ике ян ягына куеп та 15-20 шәр минут пешерергә кирәк әле.

Гомумән, бик җиңеллләрдән түгел бу эш...

ИМПЕРАТОРЛАР СЫЕ ШУЛ

«Пекинча үрдәк» инде күптән патшалар сые булудан туктаса да, аны хәзер дә табынга барыбер императорларча бирү саклана.

Ун минутлап суытканнан соң, Ван үрдәкне бик оста итеп юка телемнәргә турый. Һәр кисәктә калган тире никадәр калынрак һәм кетердәвегрәк булса, үрдәк шулкадәр тәмлерәк санала. (Кытайда Яңа елда түшкәне 108 кисәккә бүләләр! Әлеге сан бөтен эштә уңыш китерә, дип санала).

Үрдәк дөге коймагы, саламлап туралган кыяр, яшел суган һәм хойсин/тяньмянь соусы белән бирелә. Итне коймакка куясың һәм кыяр-суган-соус өстәп төрәсең – сыйлан рәхәтләнеп!

Җыю технологиясе шаурманыкына охшаса да, бу шаурма түгел! Бу – «Пекинча үрдәк», императорлар сые!

Түшкәнең калган өлешеннән Чжан шулпа пешерә – аны итле коймактан соң ашап куярга кирәк икән. Тиресез ит кисәкләрен сыек камырга манып ала да, кыздырып бирә – бусын да татып карау мәслихәт. Гадәттә «Пекинча үрдәк»не зур компания өчен пешертәләр, һәм бөтен кеше дә тук һәм канәгать кала. Иң мөһиме, ике көн алданрак заказ бирергә кирәк, чөнки аны әзерләүгә шулкадәр вакыт кирәк булачак.

КЫТАЙ АШ-СУЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Әллә ничә төрле үрдәк итен татып карагач, аның үзенчәлеге нидә булуын ачыкларга маташабыз.

Ярдәмгә Аида килә:

– Кытай ашларының төп үзенчәлеге – ризыкның тәме аерып булмаслык булуда, – дип аңлата ул.

– Ничек инде?

– Менә шулай! Итнең тәме – иткә, балыкныкы – балыкка охшамаска тиеш. Моның өчен кытайлар үз ризыкларына йөзләрчә төрле тәмләткеч, соус өсти. Аларны шуңа төрле кулинария мәктәпләрендә махсус өйрәтәләр. «Исне һәм тәмне яшерә белү» осталыгы буенча ашчының квалификациясе билгеләнә. Кытай ашларының төп үзенчәлеге нәкъ менә шунда.

КЫТАЙ АШЛАРЫНЫҢ СЕРЕ НИДӘ?

Үрдәкне ашап бетергәч, табынга чәй һәм җиләк-җимешләр китерелә – бу сыйлануның тәмамлануын аңлата.

– Кытай ашларының сере нидә? – дип кызыксынабыз бүгенге тылсымчы-ашчыларыбыздан.

– Мәхәббәттә! – ди Юй һәм печеньелы вазаны җәмәгате Аидага таба төртеп куя. – Кытай кухнясында десертлар юк, ә ул татлы ризыкларны бик ярата.

– Мәхәббәттә! – дип җөпли Аида да. – Мин чәйне берәр тәм-том белән эчәргә яратам, һәм мин генә дә түгел, шунлыктан кухнямда һәрвакыт нинди дә булса татлы тәгам табыла...

– Мәхәббәттә! – диләр Ван белән Чжан. Һәм безгә телефоннарындагы гаилә фотоларын күрсәтәләр...

– Мәхәббәттә, – дип тәрҗемә итә Аида. – Кытайлар озак вакытка чит илләргә акча эшләргә китә. Әлбәттә инде, алар үз гаиләләрен бик сагына.

ХОЙСИН СОУСЫ РЕЦЕПТЫ

Ингредиентлар:
- чили борычы – ярты кузак;
- консервланган кызыл фасоль – 100 г;
- сарымсак – 2 бүлем;
- соя соусы – 3 аш кашыгы;
- дөге серкәсе – 2 аш кашыгы;
- «Биш тәмләткеч» кушылмасы – ярты чәй кашыгы;
- күнҗәт мае – 1 аш кашыгы;
- бал – 1 аш кашыгы.

Чили борычының орлыгын алып, вак кына турыйлар. Сарымсакны издерәләр. Блендер савытына фасоль, чили борычы һәм сарымсакны салып, яхшылап ваклаталар. Аннары бал, соя соусы, дөге серкәсе һәм күнҗәт мае кушып, тагын бер тапкыр яхшылап болгаталар. Артык куе булса, консервланган фасоль суы белән сыекларга мөмкин. Хойсин соусын бер–ике сәгатьтән соң табынга бирергә була.

Итне коймакка куясың да, кыяр-суган-соус өстәп, төрәсең – сыйлан рәхәтләнеп! Җыю технологиясе шаурманыкына охшаса да, бу шаурма түгел! Бу – «Пекинча үрдәк», императорлар сые!

ТИЗДӘН!

КАЗАН КАРТАСЫНДА ЯҢА РЕСТОРАН!

Тиздән «Пекинча үрдәк» һәм башка популяр кытай ашлары белән яңа **«Кытай утары»** ресторанында сыйланып булачак.

Адресы: Бауман урамы, 49/10.

РЕКЛАМА



ЮЛБАШЧЫ БЕЛӘН БЕР ПАРТАДА

Сафа Гәрәев

Кытай Халык Республикасыннан килүчеләрне дөньядагы иң актив һәм кызыксынучан туристлар дип санаучылар, мөгаен, ялгышмыйдыр. Чин халкының оешкан төркемнәрен сез Перудагы атаклы Мачу-Пикчу янында да, Эйфель манарасы тирәсендә дә, Мәскәү Кремле диварлары буенда да очрата аласыз. ЮНЕСКО һәйкәлләре буларак, Казан Кремле, борынгы Болгарны да һәм Свияжскидагы Успение монастырен да алар игътибарсыз калдырмаячак. Ә КХР туристлары өчен Татарстан буйлап турларның мәҗбүри программасына тагын нәрсә керә яки киләчәктә өстәлә ала соң?

Фото: Әскәр Сабиров, pxhere.com, kpfu.ru

Газ лампалары. Яшел сукно ябылган инспектор өстәле. Саллы имән шкафлар, ә аларның пыялалы ишекләр каплаган киштәләрендә – Россия империясе законнарының тулы җыелмасы... Бу – Казан Император университетының 7 нче мемориаль аудиториясе. 17 яшьлек Владимир Ульянов профессор Загоскинның рус дәүләте хокукы тарихыннан лекцияләрен нәкъ менә шушында тыңлаган.

МОНДА ЛЕНИН УКЫГАН, Ә ТОЛСТОЙ МОҢСУЛАНЫП ЙӨРГӘН

Бу бүлмәдә һәрнәрсә шул вакыттагы, 1887 елгы рәвешендә. Хәтта обойларның рәсемнәре дә шундый ук (аларны үз вакытында 1896 елгы ядкәр – «Император университеты һәм аның кайбер учреждениеләре биналарының фотографик сурәтләре альбомы»на карап, яңадан ясаганнар, ә обойларның нинди төстә булганын Мәскәүдәге бер лаборатория ачыклаган). Башка чор рухы, борынгылык мохите урамда бөтенләй башка гасыр булуын онyттыра. Бәлки, шуңадыр да монда килгән һәркем, изге урынга, изге зат каршына элеккәндәй, бик нык дулкынлана.

Чин иленнән килгән туристлар төркемен, әлбәттә, икенче рәттә, тәрәзә ягындагы парта да җәлеп итә. Булачак юлбашчының нәкъ менә шул партада утырганын аның университет курсташы соңыннан, совет чорында, һич шикләнмичә күрсәтеп биргән, диләр.

Ленин утырган партага утырып карау – аның идеяләрен дәвам итүчеләр өчен, мөгаен, зур дәрәҗәдер. КХР парламенты башлыгы, 2015 елда Казанда булган Чжан Дэцзян мондый мөмкинлектән баш тартмый – хатыны белән шушы урында фотога да төшә. Дүрт ел соңрак исә җитәкче дилбегәсен аннан кабул итеп алган Ли Чжаньшу әфәнде дә 7 нче аудиториядә булып китә. Аңа Владимир Ульяновның университетка кабул итү турында гаризасының күчермәсен бүләк итәләр. «Характеристикасын алганчы кичектереп торырга» дигән кырыс резолюция куелган гариза инде ул.

«Бу бик кыйммәтле бүләк, – ди күңеле булган, бик тәэсирләнгән кунак. – Югары уку йортының Кытай университетлары белән активрак хезмәттәшлек итүен сорар идем».

Хәер, объективлык саклап, шуны да искәртик: мемориаль аудиториядәге соңгы парта да, икенче рәттәгесе кебек үк, чит ил кунакларының һәрчак игътибар үзәгендә. Халык сөйләвенчә, укырга килгән көннәрендә күңелсезлектән, эче пошудан интеккән аемсыз студент Лёвушка шул партада утырган. Булачак «Война и мир» романы авторы Толстойга ул вакытта әнә шулай эндәшкәннәр.



ДВОРЯН УТАРЫНДАГЫ «КАПИТАЛ»

Дворян Орловларның Казандагы борынгы утарында, хәзер инде Ленин музее буларак билгеле бина ишек төбендә кунакларны Ленин үзе каршы ала. Бернинди идеологик күпертү-арттыру да юк – буе төп-төгәл бер метр да алтмыш дүрт сантиметр. Узган гасырның егерменче елларында ук сынчы Николай Шильников ясаган бу Ильич – мөгаен, юлбашчыны бернинди арттырусыз, фотографик төгәллек белән күчереп алган бердәнбер һәйкәлдер. Барлык пропорцияләрне саклар өчен, автор Баш мие институтындагы материалны махсус өйрәнә.

Музейга килгән Кытай делегацияләренең Ленин янында истәлеккә фотога төшүе бер дә гаҗәп түгел. Гадәттә моны экскурсиядән соң эшлиләр. Шунысын да әйтми мөмкин түгел: туристлар төркеме зур булсынмы, берничә генә кешелекме – экскурсия вакытында ара-тирә фотоаппарат төймәсенә баскан аваздан кала чебен очкан тавыш та ишетелми – кунаклар экскурсоводның һәр сүзен игътибар белән тыңлый, әлбәттә, кыйммәтле ядкәрләрне истәлеккә фотога төшерергә дә онытмый.

Менә Володя Ульяновның әнисе Мария Александровнаның җыйнак кына бүлмәсе. Биредә бер гасыр ярым элек кулланылган көнкүреш әйберләре арасында чыннан да аныкы булган көзге-писише бар. Янәшәдә – Александр III гә һөҗүм итүдә катнашкан өчен җәзаланган улы Александрның фотосурәте. Агач шкатулка да Мария Александровнаның шәхси әйбере. Улын кичерү турында үтенечне кире каккан җавап хатын ана кеше бәлки нәкъ менә шунда саклагандыр...

Владимир Ульянов бүлмәсе дә бик тыйнак җиһазланган. Өстәл, солдат койкасын хәтерләткән тар гына карават. Бер артык әйбер дә юк. Биредә дә чын-чынлап Ульяновларныкы булган әйберләрне күрергә мөмкин. Әйтик, кара савыты, гаилә сервизыннан шикәр савыты, Владимирның туганнан туганы уеп-кырып ясаган агач шахмат. Өстәлдә Маркс «Капитал»ы ята. Большевикларның булачак юлбашчысы беренче сөргеннән кайткач укыган басма түгел анысы, ләкин шул чорныкы.

Йорт мохите, җиһазлар ул елларга абсолют төгәл туры килерлек итеп урнаштырылган. Моның өчен Ленин туганнарының истәлекләрен, XIX гасырның икенче яртысында урта керемле гаиләләрнең көнкүреш предметларын файдаланганнар. Әйе, биредә Ульяновлар гаиләсенең шәхси әйберләре күп түгел, ләкин моны аңлатырга була.
Бу очракта вакыт кына түгел, вазгыять тә үзенекен иткән. Уллары Александр җәзаланганнан соң Казанга күченгәндә, Ульяновлар үзләре белән китаплар һәм рояль генә алып килгән. Димәк, бу вакытлыча түләп торган фатирларында алар кулланган җиһазларның барысы да диярлек шушы йорт хуҗаларыныкы булган.

Сүз уңаеннан, музейда Wirth маркалы рояль да тора. Нәкъ Ульяновлар гаиләсенеке кебек. Шулай итеп, Ленинның энесе Дмитрий Ильич оныгының улы – Александр Игоревич Ульяновның хис-тойгылары аңлашыла булыр. «Бөтен гаиләбез исеменнән Ульяновлар гаиләсенең тарихын саклау эшендә башкарган хезмәтегез өчен рәхмәт белдерәсем килә... Шактый алдынгы ысуллар ярдәмендә сезнең музеегыз ул чорның көнкүрешен һәм традицияләрен өйрәнү, шулай ук Россия тарихын танып белү процессын саклап кына калмый, ә үстерә дә. Иң яхшы теләкләр һәм рәхмәт белән, Ульяновлар гаиләсе», – дип язган ул музей коллективына.

Ә менә КХРның Казандагы генераль консулы Сян Бо әфәнденең хатыннан өзек: «В.И. Ленин музее Татарстан Республикасының милли мәдәни мирасы булып тора һәм ул Кытай туристларының иң яраткан истәлекле урыннарыннан берсе... В.И.Ленин музей-йортының көннән-көн яхшыра баруын телим. Кытай-Россия дуслыгының мәңге дәвам итүен телим!»

ГОРЬКИЙ МОНДА КАМЫР БАСКАН

Беркайчан да көн яктысы күрми торган караңгы җир асты, тычкан утыдай тонык лампа, баш түбәсендә кирпеч гөмбәз...

Горький музееның төп үзенчәлеге дә әнә шулардыр, мөгаен. Бу подвал Андрей Деренков пекарнясы була да инде. Киләчәктә «революция хәбәрчесе» дип тә йөртеләчәк әдип, үзенең Казан «университетлары»нда укыганда, җиде кат тире чыкканчы менә шушында эшләгән. Җиһазлар нәкъ 1886-1887 еллардагы кебек. Пекарняда Алексей Пешков бер сменага 30 потка якын камыр баскан. Тормышта моннан да авыррак эш күрмәдем, дип яза ул соңыннан истәлекләрендә...

Ленин музее белән чагыштырганда, Кытай делегацияләре бирегә әле бик еш килми, бәлки, аның барлыгы турында хәбәрдар түгелләрдер. Шул ук вакытта, Горький әсәрләрен Чин илендә Россиядәге кебек үк беләләр һәм яраталар. Шанхайдагы Лу Синь (хәзерге кытай әдәби теленә нигез салучы) бакчасында кешелек дөньясы тарихындагы ун төп язучының сыннары куелган. Шуларның берсе – Максим Горький. Күпмедер белемгә ия һәр кытайлыга таныш рус әдипләренең берсе ул. Биш ел элек, язучының тууына 150 ел тулу уңаеннан, КХРда аның 20 томлык җыелма әсәрләре миллионнан артык тираж белән кабат басыла. «XX гасыр рус язучылары арасында ул беренче урында тора», – дип саный Пекин университеты профессоры Жэнь Гуансюань.

Димәк, Казандагы истәлекле коллекция ядкәрләре Горькийның «Клим Самгин» әсәрендәге фәлсәфи мәгънәләрне аңлый белгән югары зәвыклы белгечләрне генә түгел, аның «Давыл кошы турында җырлар» яки пролетар рухлы «Ана» романын сөючеләрне дә кызыксындыра ала. Әдип фотода киеп төшәргә яраткан түбәтәй, аның зәңгәр күлмәге, кәнәфие, күзлек савыты... – бу шәхси әйберләр бүген дә язучының күңел җылысын саклый кебек.

P.S. Әлбәттә, Кытайдан килгән туристлар өчен кызыклы булырлык истәлекле урыннарның барысы турында да сөйләп чыгыйк дисәк, тулы бер журнал да җитмәс. Кайберләрен генә санап китик. «Ленино-Кокушкино» музей-тыюлыгы*, андагы бабасының утарында Владимир Ульянов беренче сөргенен уздырган. Казан университетының тарихи аудиториясе – монда 1887 елда студентлары сходкасы үтә, шул җыеннан соң Ульянов университеттан куыла. Красновидово авылында А.М. Горький музее. Казанда социалистик көнкүреш музее.



* Әлегә реконструкциядә

ШӘХСИ БРЕНД ФАЙДАСЫНА 7:0

Сентябрьдә Казанда «РОСТКИ» Халыкара Россия–Кытай форумына илебез төбәкләре һәм Кытай провинцияләре вәкилләре җыелды, алай гына да түгел, бирегә Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләреннән иң эшлекле хатын-кызлар да килде. 7 сентябрьдә җиде спикер Татарстанның эшлекле хатын-кызлары 7 нче халыкара форумында чыгыш ясады.

«Московский» мәдәни үзәгендә форумның актив гүзәлләрен генә түгел, бәлки «Татарстан» тышлыгында – Татарстан хатын-кызлары» проектын – журналның 102 еллык тарихы дәвамында басма тышлыгында чыккан хатын-кызларны да күреп булачак.

ӘБИЛӘР ЧУАГЫ НИНДИ ТӨСТӘ?

Татарстанның иң эшлекле 400 хатын-кызы, шулай ук аларның Мәскәү, Санкт-Петербург, Ульяновск, Ростов-на Дону һәм башка шәһәрләрдән килгән коллегалары «әбиләр чуагы – сары көз ул» дигән фикерне кире кагарга җыена. Форумның дресс-коды – яшелнең барлык төсмерләрендәге киемнәр. Нигә яшел төс сайланган?

– Чөнки яшел төс – безнең искиткеч матур Татарстан Республикасы хатын-кызларының яраткан төсе, – дип аңлата «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» бизнес-клубы президенты һәм аны оештыручы Лиана Баһавиева. – Чөнки яшел – яңарышны, табигатьнең уянуын, яңа тормын башлануын белдергән төс, ә без форумда хатын-кызларыбызны яңа мөмкинлекләр эзләү, яңа бизнес-идеяләр үстерүгә рухландырырга омтылабыз.

Фото: Лиана Баһавиева архивыннан, Александр Ефремов. РЕКЛАМА

Яшел төс табигать һәм энергия белән бәйле. Ул без, хатын-кызларга, эш һәм ял арасындагы балансның мөһимлеге, планетабыз, әйләнә-тирә мохитебез турында кайгырту зарурлыгы турында исебезгә төшерә. Яшел төс экологиягә сакчыл мөнәсәбәт кирәклеген искәртә һәм нәкъ менә 7 сентябрьдә Халыкара зәңгәр күк өчен саф һава көне билгеләп үтелә, бу көн кеше сәламәтлегенең планетадагы экология белән бәйләнешенә игътибар юнәлтә.

ФОРУМНЫҢ БАР ТӨСМЕРЛӘРЕ

«Форум төсе» нинди генә булмасын, аның программасында һәрвакыт хатын-кыз рухы тоемлана. Шуңа күрә... программада нәрсәләр бар соң әле?

– Программа бик кызыклы. Форум темасы – «Шәхси бренд файдасына 7:0» дип атала. Монда спикерлар чыгышы да, партнёрларның күргәзмәләре дә, төбәкләр арасында килешүләргә кул кую да булачак.

Спикерларның берсе – Мәскәү вәкиле, Юлия Высоцкаяның лицензияләү агентлыгы генераль директоры, «Едим Дома!» һәм Julia Vysotskaya бренд-директоры Мария Козеева.

Мария Юлия Высоцкаяның гаилә кыйммәтләре, өйдә уңайлы, җылы мохит, дөрес туклану һәм заманча тормыш рәвешенә нигезләнгән шәхси брендларын үстерү тәҗрибәсе белән уртаклашачак. Аның чыгышының темасы – «Ашыйм, йөгерәм, яшим. Юлия Высоцкая брендының уңышка ирешү тарихы» дип атала.

Тагын бер Мәскәү кунагы – шәхси брендлар, pr-стратегияләр һәм маркетинг концепцияләре булдыру белгече, «Шәхес бренды» һәм «Я-концепт» китаплары авторы, бизнес-мәктәпләр укытучысы, шәхси брендинг агентлыгын оештыручы Полина Правда «Медиакырда мәгълүмати образны ничек формалаштырырга», интернет челтәрендә абруйны ничек сакларга кирәклеге турында сөйләячәк. Мәгълүмати образ булдыру һәм бу өлкәдәге төп хаталар турында фикерләрен уртаклашачак.

Казан спикеры Денис Супрунов шәхси брендны һәм бизнесны үстерү-популярлаштырудагы уйдырма фикерләр һәм хаталар турында сөйләячәк һәм, аерым алганда, 2023 елда шәхси брендны алга этәрүнең актуаль һәм нәтиҗәле чараларына тукталачак.

Халык алдында чыгыш ясарга өйрәтү тренеры Раяна Әхмәтҗанова үзең турында бер минут эчендә эчтәлек-

ле, үтемле итеп сөйләргә өйрәтәчәк һәм көндәшләр арасында аерылып тору өчен нишләргә кирәклеген аңлатачак.

Мин дә спикер буларак чыгыш ясаячакмын һәм шәхси бренд тирәсендә фикердәшләр бергәлеген туплау серләрен ачачакмын.

Гомумән алганда, форум – файдалы элемтәләрне һәм һөнәри абруйны ныгыту, шәхси бренд төзү эшендә практик күнекмәләрне яхшырту, башкаларның кызыклы һәм уңышлы эшмәкәрлек тарихларыннан илһам алу өчен менә дигән мөмкинлек.

НӘКЪ ХАТЫН-КЫЗЛАРЧА

Татарстанның эшлекле хатын-кызлары кемнәр ул?

– Алар бик төрлеләр һәм бик шәпләр, мин алар белән горурланам! – ди Лиана. – Алар эшмәкәрлек сәләтенә ия, аларның һәрвакыт бер кочак идеяләре бар. Һәм иң мөһиме – ул идеяләр, беренче карашка нинди генә юләрлек булып тоелмасын, тормышка ашырыла һәм уңышка ирешә. Сүз кибетләр һәм матурлык салоннары турында гына бармый, югыйсә күпләр хатын-кызлар бизнесы дигәндә, шуны гына күз алдына китерә. Әлеге эшлекле ханымнарның бизнеслары еш кына бөтенләй хатын-кызларча булып күренми. Кемдер металл эзләү җиһазлары ясый, кемдер мобиль элемтә вышкалары төзи, кемдер төзелеш материаллары белән шөгыльләнә, кемдер шәхси мәктәп ача... Шул ук вакытта алар барысы да диярлек әниләр һәм араларында хәтта күп балалылары да бар! Димәк, алар җилкәсенә әле гаилә, йорт, дәрес әзерләтү кебек мәшәкатьләр дә өелгән дигән сүз... Ничек өлгерәләр, диярсез. Менә шулай – хатын-кызларча!

СӨЙЛӘШЕП АЛЫРГА?

Ә сөйләшеп, эч серләрен бушатып алырга вакыт табыламы? Хатын-кызлар сөйләшергә бик ярата бит...

– Без очрашу һәм төрле чаралар вакытында сөйләшәбез, алар бездә һәр атна саен була – ким дигәндә, дүрт чара! Мәсәлән, сишәмбе көнне бездә онлайн-нетворкинг уза. Зум аша төркемдәге яңа кызлар белән танышабыз, бер-беребезнең яңалыкларын белешәбез, шушы мизгелдә бер-беребезгә ничек ярдәм итәргә мөмкин икәнен сөйлибез. Ягъни язылмаган кагыйдә бар – үзебезнекеләрнең хезмәтеннән генә файдаланабыз, үзебезнекеләрдән генә сатып алабыз. Әйтик, баланы бакчага бирергә кирәк, ә арабыздагы бер ханым балалар бакчасы ачып җибәргән чак. Чәч ясатырга кирәк икән, андый хезмәтне тәкъдим итүче ханым да бар. Туган көн билгеләп үтәргә җыенасыз икән, арабыздагы бер ханымның ресторанына рәхим итегез. Визит карточкасы ясатырга кирәкме – анысы да үзебезнекеләрдән. Бер-беребезгә шулай ярдәм итәбез.

Һәр чәршәмбе без төшке ашка җыелабыз. Эш бетми ул, ә ашамыйча торып булмый! Ә табын янында көнүзәк проблемалар турында янә сөйләшеп алырга җай чыга.

Айга бер тапкыр, һичшиксез, кызлар кичәсе ясыйбыз. Күңел ачабыз, тупланган киеренкелектән бушанабыз. Милли мәдәниятләр белән танышабыз. Безнең клубка төрле милләт вәкилләре җыелган бит: русы, татары, казахы, хәтта кытай хатыны да бар! Күпмилләтле Татарстанда яшибез!

ТУП-ТУЛЫ 11 ЕЛ!

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» әле яшь оешма – аңа 11 яшь кенә.

– Тук-тулы 11 ел ул! Мин артка борылып карыйм да ун елдан артык вакыт узганына ышана алмыйм. Бу вакыт эчендә күпме эшләр башкарылды, күпме тау күчерелде!

Чөнки элек, туризм белән шөгыльләнгәндә, эшкуарларга бик күп төрле дәүләт ярдәме программалары барлыгы турында уйлап та караганым юк иде. Баксаң, инфраструктура ярдәме дә, мөлкәти ярдәм дә бар, консультацияләр дә бирелә икән... 2011 елда дәүләт хезмәтенә, төгәлрәге, Инвестицион үсеш агентлыгына эшкә урнашканчы, күп кенә башка эшмәкәрләр кебек үк, мин дә үз казанымда кайнадым. Агентлыкта республиканың кече һәм урта бизнесына кагылышлы юнәлешне җитәкләдем. Һәм бу хезмәтемдә төп бурычым эшкуарларга әнә шул мөмкинлекләр турында мәгълүмат җиткерү, аларга ярдәм итүдән гыйбарәт иде. Ә моны ничек эшләргә? Кешеләрне кайдадыр, нәрсәдәдер берләштерергә, шул бергәлек аша ярдәм итәргә кирәк иде. Әнә шулай, 11 ел элек, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» оешмасы барлыкка килде.

Хәзер безнең хәрәкәт бөтен республиканы колачлый. Татарстаннан читтә дә үсеп барабыз. Һәм яңа территорияләрне үзләштерү, яңа кешеләрне җәлеп итү, яңа тәҗрибә алуга бәйле үз бизнес-миссиябез белән горурланабыз.

Узган елгы форумда Татарстанның эшлекле хатын-кызлары «Татарстан» журналының китапларны яратуга багышланган махсус проектында катнашты.

ПРЕЗИДЕНТНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

Форум ресторанда бәйрәм программасы белән тәгәлләнә. Бу да бер традиция. Ул «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» клубы президентының туган көненә туры китерелгән, диләр?

– Дөресен әйткәндә, мин туган көнемне бәйрәм итәргә яратмыйм, – ди Лиана Баһавиева. – Бу мәшәкатьләр шулкадәр күп вакытны ала, ә ул вакыт дигән нәрсә миңа һәрвакыт җитми. Кайвакыт мин ул туган көн турында шатлана-шатлана онытыр да идем. Ләкин бит якыннарыңа да, дусларыңа да алай дип булмый! Алар онытмаячак. Алар барыбер котлаячак, барыбер шалтыратачак, әзерләнәчәк, бүләкләр күтәреп киләчәк – шуңа да дуслар инде алар. Мин үзем дә һичкемнең туган көне турында онытмыйм – әзерләнәм, шалтыратам, бүләкләр сайлыйм. Шуңа күрә күңелле мәшәкатьне файдалы эш белән берләштереп, форумны да, туган көнне дә бергә уздырырга булдым. Бу көн минем өчен икеләтә бәйрәмгә әйләнде, ә андый бәйрәмгә әзерләнәсе дә килә, ул бик күп матур хатирәләр калдыра, һәм аның турында инде беркайчан да онытмыйсың!

«ТАТАРСТАННЫҢ ЭШЛЕКЛЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ» төбәк иҗтимагый оешмасы – Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен, хатын-кыз эшкуарларның әгъзалык нигезендә алып барыла торган берләшмәсе. Ул шулай ук хатын-кызларның иҗтимагый, мәдәни, сәяси эшчәнлеген һәм уку-укыту өлкәсендәге эшчәнлеген үстерү максатларын да күздә тота.

Оешмада Татарстанның төрле шәһәрләреннән, эшчәнлекнең төрле өлкәләреннән, төрле яшьтәге 342 эшмәкәр ханым әгъза булып тора, аларның барысын да үз бизнесларын үстерү һәм үзләрен камилләштерү теләге берләштерә.

Оешманың Түбән Кама, Яр Чаллы, Лениногорск, Менделеевск, Буа һәм Әлмәттә, Алабуга һәм Арча районнарында 8 рәсми вәкиллеге бар. Балык Бистәсе һәм Яшел Үзән районнарында да вәкиллекләр ачу планлаштырыла. Оешма активы ай саен Татарстан һәм Россия шәһәрләре буенча бизнес-миссияләргә юлга чыга, районның икътисадый потенциалы белән танышу, аның эшлекле хатын-кызлары белән хезмәттәшлек һәм үзара файдалы проектларны гамәлгә ашыру юллары турында фикер алышу максатында әһәмиятле эшкуарлык объектларына сәфәр кыла.

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» дәүләт хакимияте органнары, Татарстан һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге иҗтимагый һәм коммерция оешмалары белән актив хезмәттәшлек итә.

–НӘКЪ ТАРЗАНКА БЕЛӘН СИКЕРГӘН КЕБЕК...

«Бу тарзанка белән сикергән кебек, беренче ике секундта эчеңдәге бөтен нәрсә куырылып килә дә, аннары син кулларыңны җәеп җибәрәсең һәм очыш белән ләззәтләнәсең», – дип исенә төшерә үз бизнесын башлаган чорны «eTaSh» тимер-бетон эшләнмәләр компаниясе җитәкчесе Альмина Гаффарова. «Первая вице-миссис Россия – Вселенная 2022» һәм «Миссис Стиль Татарстана 2022» титулларына ия нәфис кыз ничек шундый чын ирләр бизнесы белән җитәкчелек итә икән соң?

– Үземә карата әйтелгән: «Ничек инде – сез һәм тимер-бетон... Башка сыймаслык бит бу», – дигән сүзләрне даими ишетәм мин. Әмма бер нюанс бар – без дилерлар. Ихтимал, якын арада без үз җитештерүебезне ачарбыз, мин әлегә бу юнәлешне өйрәнәм генә. Гомумән алганда исә, гаять зур тәҗрибәң һәм белемең, квалификацияле белгечләрең, фикердәшләр командасы, ышанычлы партнерларың бар икән һәм, иң мөһиме, якыннарың һәм остазларыңның ярдәмен тоясың икән, җитәкчелек итүе бик җиңел.

– Сезнеңчә, бүген «бизнес» дөньясына кемнәр хуҗа – ирләрме, әллә хатын-кызлармы?

– Анда кемнең күбрәк булуында минем эшем юк. Җирдә югары әхлаклы, акыллы, бәхетле, үз юлын тапкан кешеләр белән яшәве күпкә кызыграк. Бизнес тәвәккәл, җаваплы, нык ихтыярлы, үзсүзле, җиңүгә омтылучаннарны үз итә.

– Үз эшегезне ничек башладыгыз? Үзегезне тәүге тапкыр «бизнеста» тою ничегрәк булды? Нәрсәдән курыктыгыз?

– Мин холкым буенча командир, лидер, оештыручы, шунлыктан барысы да «телим» сүзеннән башланды – алга барырга телим. Үзем файдалы булырлык урынны тиз таптым. Тимер-бетон белән инде 6 елдан артыграк эшлим, аңа кадәр нефть чыгару тармагында күп еллык тәҗрибәм бар иде.

Эшчәнлегемнең икенче юнәлеше дә минем өчен шундый ук мөһим. Мин – ченнелер, аңның югары даирәләреннән мәгълүмат һәм энергияләр тапшыручы.

Балачагымда ук шуны аңладым: Ходай Тәгалә миңа үзенчәлекле сәләт биргән. Мин кешеләргә фаразлаган нәрсәләр тормышка аша иде. Моны әйләнә-тирәдәгеләр дә сизеп алды һәм фатиха бирүемне сорап мөрәҗәгать итә башлады.

Әкренләп сәләтем тагын да камилләште, мин кешенең энергетик кырын күрергә, андагы максатка ирешергә комачаулаган нечкә урыннарны табарга өйрәндем.

Хәзер миңа кешеләр бик күп төрле сораулар белән мөрәҗәгать итә: шәхси тормыш, финанс кыенлыклары, сәламәтлек белән проблемалар һәм башкалар.

Соңгы ике елда гына да мин ярдәмгә мохтаҗ илледән артык кешегә булыштым. Менә шундый мавыгуым да бар минем.

Куркуга килгәндә исә, бу тарзанка белән сикергән кебек, беренче ике секундта эчеңдәге бөтен нәрсә куырылып килә дә, аннары син кулларыңны җәеп җибәрәсең һәм очыш белән ләззәтләнәсең, ул әкренләп салмак кына батутта сикерүгә кайтып кала.

– Хатын-кыз бизнесын алып баруның үз кагыйдәләре бармы?

– Бернинди кагыйдәләре дә юк. Изге ниятең һәм нәрсәгәдер чын күңелдән инануың бар икән, эшчәнлекнең теләсә кайсы өлкәсендә уңышка ирешү мөмкинлеге бар. Хәтта аю да велосипедта йөрергә өйрәнә ала бит. (Көлә.)

– Сез беренче карашка бөтенләй ярашмаслык нәрсәләрне бик уңышлы яраштырасыз: җитәкче вазыйфасын һәм «Первая вице-миссис Россия – Вселенная 2022» белән «Миссис Стиль Татарстана 2022» кебек югары титулларны. Сезнең уңышның сере шундамы әллә?

– Сере – мәхәббәттә һәм шуны ачык аңлауда: бу дөнья – мизгел генә бит ул, күзеңне ачып та өлгермисең, инде кәфенгә төренеп бакыйлыкка да китеп барасың.

Ә конкурсларда катнашу исә – бөтен нәрсәдә җиңү, сәләтләреңне күрсәтү, гүзәллек, яңа танышлыклар, тәҗрибә уртаклашу, сәяхәтләр, аралашу күнекмәләре – гомумән, һәр хатын-кызга хас булган сыйфатларны тулысынча ачу ул.

– Сезнең хезмәткәрләрегезгә Галәмнең иң гүзәл ханымы кул астында эшләве бик рәхәттер инде...

Фотолар Альмина Гафарова архивыннан. Реклама

– Яңәшәмдә шундый фикердәшләр һәм үз эшенең патриотлары булу минем өчен бик яхшы. Мин хезмәткәрләремнән бик уңдым. Безнең һәркайсыбыз өчен иң мөһиме – клиентның проблемаларын тиз арада хәл итәрлек идеаль һәм уңайлы мохит тудыру.

Аларның бәхетле һәм рәхмәтле йөзләрен күргәч, безнең компаниянең яңа, гадәти булмаган форматларын үстерүгә омтылышыбыз тагын да активлаша башлый.

– Шундый тизлектә яшәгәндә ял итү өчен вакыт табыламы? Кайда һәм ничек көч туплыйсыз?

– Әлбәттә, табыла. Бизнеста башта оештыру, нигезен салу, төзү мөһим, аннары исә бары тик кешеләрне һәм үзең эшләгән эшне яратырга гына кирәк.

Кайда көч туплыйммы? Сулыш күнегүләре ясыйм. Төп эшчәнлектән тыш, Ходай Тәгалә белем һәм үземнең сәләтемнән файдалану осталыгын да биргән. Бездә бетмәс-төкәнмәс тормыш энергиясе тупланган, әмма безнең көчебезнең 90 %ы кирәкмәгән фикерләр аркасында юкка чыга (гомер ресурсы акыл аша сарыф ителә). Азрак уйлыйм, күбрәк тоям һәм эшлим.

– Хатын-кыз буларак һәм бизнес җитәкчесе буларак нинди өчәр әйберне сайлап алыр идегез?

– Хатын-кыз буларак мин хыялымның тормышка ашуын, иҗатны һәм бернинди шартлар белән чикләнмәгән мәхәббәтне, бизнесвумен буларак исә – гөрләп үсүне, бизнесны үстерүнең бетмәс-төкәнмәс ресурсы булуны, рәхмәтле кешеләрне сайлар идем.

– Сезнең һәр көн кабатлана торган сөенечләрегез нидән гыйбарәт?

– Хәерле иртә һәм татлы йокы, кочаклашу-үбешү, үзем яраткан һәм үземне яраткан кешеләрнең елмаюлары, догалар һәм илһам, рәхмәт уку һәм үземне камилләштерү эше, дөньяны күзәтү һәм танып белүне дәвам итү.

– Үз гомерегездәге иң файдалы киңәшне кемнән ишеттегез?

– «Иң яхшы түгел, бәлки башка төрле булырга тырыш» – Владимир Древс (эшкуар, спикер, блогер, үзеңне камилләштерү буенча китаплар авторы).

–Ниләр турында хыялланасыз?

– Кешеләр гомернең чиксезлеген һәм бихисап мөмкинлекләр булуны аңласын иде, дип хыялланам. Һәм, әлбәттә инде, дөнья тирәли сәяхәт һәм диңгез ярындагы йорт хакында хыялларым бар.

ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ФИКЕРЕ

Камилә, сату бүлеге җитәкчесе:
– Альмина Шамилевна беркайчан да бер урында гына тормый. Гел хәрәкәттә, шуңа бөтен уйлаганы гамәлгә аша да. Мондый җаваплы һәм акыллы кеше җитәкчелегендә эшләве рәхәт. Аңа ияреп барасың һәм төгәл беләсең – нәрсәгә генә тотынсак та, бу эш уңыш китерәчәк! Һәрвакыт барысы да бик төгәл, уйланылган һәм план буенча бара.

Олеся, сату буенча менеджер:
– Альмина Шамилевна бөтен нәрсәне бөтен вак-төягенә кадәр алдан уйлый, шуңа эше уңа да. Креатив идеяләр чыганагы да үзе. Ышанып әйтә алам: безнең җитәкчебез – безнең горурлыгыбыз ул.

ЭНЕРГОСИСТЕМА ФЛАГМАНЫ

Казанда 110 кВ лы «Азино» подстанциясе сафка басты. Яңа цифрлы энергетика объектына Форель Тинчурин исеме бирелде.

Подстанцияне ачу тантанасының «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы булган Казан электр челтәрләренең 80 еллык юбилее елында, нәкъ менә бу бәйрәмне билгеләп үткән көнне узуы да символик мәгънәгә ия. Чөнки яңа цифрлы объект шушы предприятие җаваплылыгына караган зонада урнашкан.
1943 елда, Казан электр челтәрләре оештырылганда, Казан энерготөенендә 153 трансформатор подстанциясе, 55 км га сузылган кабельле линияләр, 6–10 кВ көчәнешле 43 км һава линияләре һәм 168 км түбән вольтлы линияләр булган. Казан электр челтәрләре бүген исә 600 кв. км дан артык территориягә хезмәт күрсәтә, 35–500 кВ лы подстанцияләренең гомуми номиналь куәте 4214,3 МВА тәшкил итә. Энергиянең 65 %ын «Казан Оргсинтез», авиатөзелеш предприятиеләре һ.б. кебек сәнәгать предприятиеләре куллана.

– Бүген цифрлы трансформациядән башка икътисадның үсеше мөмкин түгел. Әлеге яңа подстанцияне кулланышка кертү микрорайонны электр белән тәэмин итү сыйфатын яхшыртачак, аның ышанычлылыгын арттырачак, республиканың энергия куркынычсызлыгын ныгытачак, – диде Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин 110 кВ лы «Азино» подстанциясен эшләтеп җибәрү тантанасында. – Әлеге вакыйганың чынга ашуы үзе үк куанычлы, чөнки мондый объект барлыкка килсен өчен, югары квалификация, техник мәсьәләләрне чишү генә түгел, билгеле бер кыюлык та кирәк.

Подстанциянең «йөрәге» – 40/60 МВА егәрлекле көчәйтелгән трансформатор. Бу җиһазның мондый егәрлеге берничә йөз күпфатирлы йортны, шулай ук социаль әһәмияткә ия дистәләгән объектны – инде кулланыштагыларын гына түгел, киләчәктә төзеләчәкләрен дә энергия белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Сервер, электр щиты бүлмәләре, реле залы, башка эш бүлмәләре – барысы да яхшылап уйлап ясалган, иң заманча техника белән җиһазландырылган.

Фотолар «Челтәр компаниясе» АҖ тарафыннан бирелде. Реклама

Подстанция территориясендә тагын бер уникаль корылма – 110 кВ көчәнешле бүлү пункты урнашкан. Ул Казанда Вознесение трактын төзү проекты кысаларында эшләнгән. Бүлү пункты ярдәмендә подстанциягә электр энергиясен «Киндери – Үзәк» кабельле һава линиясеннән кабельләр белән кертү мөмкинлеге тудырылган. Саклык зонасын киметү һәм шәһәр өчен мөһим яңа трассага коридор ачу максатында, энергетиклар әлеге югары вольтлы кабельнең 5 километрлык өлешен җир астына яшергән.

– Бу подстанция Татарстан энергетика системасының горурлыгы һәм флагманы булып тора, – ди «Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев. – Иң мөһиме: ул Татарстан белгечләре – проектлаучылар, җиһаз ясаучылар, төзүчеләр, электромонтажчылар тырышлыгы белән корылды, ягъни энергетика чын-чынлап Татарстанныкына әйләнде.

– Без бик канәгать: иҗат ияләре – рәссамнар картинаны ясап бетергәч, үз әсәрләренә сокланган кебек, без, энергетиклар да, инженерлык фикеренең әлеге могҗизасына, чын әсәренә сокланабыз, – диде Казан электр челтәрләре «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы директоры Илшат Галимҗанов, объектны файдалануга кабул иткәндә. – Бу бик күп белгечләрнең командалы эш нәтиҗәсе. Сүз технологик яктан катлаулы проект турында барыин да истә тотарга кирәк: гамәлдәге подстанция шартларында, ягъни кулланучыларны электр энергиясеннән аермыйча гына эшләү таләп ителә иде. Команда озак еллар кешеләргә хезмәт итәчәк иң кыю ниятләрне һәм алдынгы идеяләрне тормышка ашырды. Бу тантана Казан электр челтәрләренең 80 еллык юбилеен бәйрәм иткән көнгә туры килү аеруча күңелле.

110 кВ лы «Азино» подстанциясен сафка бастыру тантанасы алдыннан узган тагын бер вакыйга символик мәгънәле. Тантанада катнашучылар подстанция фасадында Форель Тинчурин хөрмәтенә истәлек тактасы ачты. Күренекле галим, республика энергетикасы үсешенә зур өлеш керткән педагог ун ел дәвамында Мәскәү энергетика институтының Казан филиалын (хәзерге Казан дәүләт энергетика университетын) җитәкли. Хәзер аның исемен яңа подстанция йөртәчәк.

– Форель Закир улының якты истәлеген мәңгеләштерү ниятебез барлык инстанцияләрдә бертавыштан хупланды, чөнки энергетикларның күбесе – аның укучылары, – дип билгеләп үтте Илшат Фәрдиев. – Күп кенә дәрәҗәле бүләкләр алган, илкүләм әһәмияткә ия бу шәхес һәрвакыт педагог, тәрбияче булып калды, студентларга ихтирам белән карый, аларның көнкүреш проблемаларын белә һәм аларны хәл итәргә булыша иде. Чын җитәкче нәкъ менә шундый булырга тиеш тә.

Казан электр челтәрләре «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы кул астындагы зонада цифрлы подстанция (ЦПС) төзү 2020 елда башлана, чөнки мораль һәм физик яктан искергән җиһазларны, биналарны һәм корылмаларны яңарту таләп ителә.

Проектны гамәлгә ашыруда «КЭР-Холдинг идарә компаниясе» ҖЧҖ генераль подрядчы вазыйфаларын башкара. Подстанция территориясендә төзелеш эшләре кысан, уңайсыз шартларда алып барыла, шуңа да карамастан Совет районындагы кулланучылар өчен мөмкин кадәр сизелмәслек рәвештә башкарыла, ягъни электр белән тәэмин итүдә өзеклекләр булмый. Цифрлы подстанцияне эшләтеп җибәрүгә бәйле төп процедуралар һәм җиһазларны комплекслы сынаулар ЦПС өчен җиһазлар җитештергән предприятиедә үткәрелә, бу исә объектта эшләр вакытын максималь дәрәҗәдә кыскартырга мөмкинлек ача.

Яңа подстанция бары тик Россия җиһазларын һәм технологияләрен кулланып җитештерелгән, өстәвенә, аларның күп өлеше Татарстанда эшләнгән, Җиһазлар һәм материалларны Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Чебоксардан сатып алынган.

Барлык җиһазлар тулысынча бина эчендә урнаштырылган мондый энергетика объектлары шәһәрләрнең торак кварталларына ярашып, туры килеп тора, әлеге типтагы проектлар төзелеш мәйданын да экономияләргә мөмкинлек бирә. Көч трансформаторлары тирә-юньне тавыштан саклау өчен ышанычлы система белән көйләнгән һәм алар халыкны борчымый, моннан тыш, алар тышкы мохит тәэсиреннән тулысынча сакланган, экологиягә зарарсыз һәм җиһазларны эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итә.

Сиринат Шаһиев, Казан электр челтәрләренең баш инженеры:

– Гомумән алганда, бу – Казанда икенче цифрлы объект, әмма цифрлы җиһазлар белән тәэмин ителеш һәм комплектлану дәрәҗәсе ягыннан – беренче! Бу подстанциядә хезмәт күрсәтүче персонал юк, ә барлык җиһазлар һәм коммутация аппаратлары белән эш Казан электр челтәрләренең моннан 15 чакрым ераклыкта урнашкан диспетчерлык пункты аша алып барыла. Шуңа күрә мондый югары көчәнешле җиһазларны ремонтка туктатып алу яки электр белән тәэмин ителешен кайтару кебек гамәлләрне хәзер ерактан торып башкарырга мөмкин.

Казан электр челтәрләре ветераны Хәтим Дәүләтшин:

– Бүген без бу нәрсәләргә шаккатып карадык: барысы да бик тиз үсештә, хәзер коллектив башкача фикер йөртә һәм белем дәрәҗәсе ягыннан бик алга киткән. Сезнең барыгызга да киләчәктә авариясез эш һәм хезмәт уңышлары телим!

«ҺӘРВАКЫТ ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ АТЛАРГА, Ә ИҢ ЯХШЫСЫ – БЕР АДЫМ АЛДА БАРЫРГА»

Әлмәт дәүләт нефть институты ректоры Александр Дьяконов «Татарстан» журналына интервьюсында фән һәм җитештерү өлкәсенең коллаборациясе, югары уку йортының өстенлекле бурычлары, дөнья стандартларына туры килгән кампус һәм бүгенге студентлар турында сөйләде.

ҖАВАПЛЫЛЫКНЫ ҮЗЕҢӘ АЛУ ТУРЫНДА

– Александр Анатольевич, СССРда нефть чыгару тармагы алдынгысы булган «Татнефть» берләшмәсе XX гасырның 50 нче елларында грамоталы инженерлар һәм белгечләргә бик зур ихтыяҗ кичерә. 1956 елда төзелгән Әлмәт дәүләт нефть институты белән бүгенгесенең аермасы нәрсәдә?

– Нәкъ менә белем бирү, фәнни эш мәсьәләсендә институтны бик тиз оештыру республиканың нефть-газ тармагын рекордлы дәрәҗәдә кыска вакыт эчендә кадрлар белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Аның феномены нәкъ менә шунда. Монысы бер яктан.

Икенче яктан, институт оештыру өчен, ул вакытта иң яхшы галимнәрне һәм илебез нефть ятмаларын өйрәнү һәм үзләштерүгә күп көч керткән белгечләрне җәлеп итәләр. Аларның фәнни карашлары, инанулары, мәдәниятләренең төрлелеге ул вакытта нефтьчеләрнең барлык ихтыяҗларын канәгатьләндерә алырлык югары уку йорты төзергә мөмкинлек биргән көчле синергия була. Эшне шулай үгезне мөгезеннән алып башлап җибәрү югары уку йортын озак елларга кадрлар белән тәэмин итә.

– Ләкин вакыт бара, һәрнәрсә үзгәрә... Аңлашыла ки, ятмаларны үзләштерү шартлары үзгәрү, нефть чыгару технологияләре үсеше инженерлык кадрларына да инде башка таләпләр куя...

– Әлбәттә, бүген безнең төп максат бөтенләй башка югарылыкка күтәрелүдән гыйбарәт. Илнең нефть тармагындагы иң яхшы югары уку йорты булу. Мондый колачлы, зур максат үзенчәлекле, гадәти булмаган алымнар таләп итә, без хәзер шул юнәлештә актив эш алып барабыз. Сүз уңаеннан, бик тиздән институтта ике зур проектлы-аналитик сессия үткәрү планлаштырыла. Шул вакытта без үзара хезмәттәшлек юллары турында фикер алышырга ниятлибез. Кая таба барырга, безгә ничек хәрәкәт итәргә икәнен аңлыйбыз, әмма без бу хәрәкәтнең җитәкчеләр, укытучылар, студентлар белән бергә алып барылуын телибез. Безнең бурыч – һәрвакыт заман белән бергә атлау, ә тагын да яхшысы – бер адым алда бару. Ә моның өчен инициативалар гына түгел, үз өстенә җаваплылык алырга әзер лидерлар да кирәк.

АКЫЛ ҺӘМ МӘДӘНИ КӨЧ ҮЗӘГЕ ТУРЫНДА

– Әлмәттә дөньякүләм дәрәҗәдәге архитектура объекты – нефть институтының студентлар кампусы төзелә. Аның уникальлеге нәрсәдә? Без кайчан аның тулысынча ачылышын күрә алачакбыз?

– Кампус шаккатыра! Ике тулай торак, спорт комплексы, лаборатория-тикшеренү корпусы, бөтен кампус астында 200 дән артык автомобиль сыйдыра ала торган җир асты парковкасы... Төп корпус төзелеше тәмамлану стадиясендә, укытучылар һәм хезмәткәрләр өчен квартал төзелә – бу якынча 1000 фатир дигән сүз. Хәзер тагын бер тулай торак һәм IT-корпус төзү мәсьәләсе карала. Болары суперзаманча ике комплекс булачак.

Фотолар Әлмәт дәүләт нефть институтыннан алынды. РЕКЛАМА

Студентлар кампусы – яшәү өчен уңайлы һәм матур шәһәрчек кенә түгел, ә студентларны, укытучыларны, галимнәрне һәм шәһәр халкын үзенә җәлеп итә торган акыл һәм мәдәният берләшкән үзәк тә.

Бу – Россия югары уку йортлары һәм ТатНИПИнефть корпоратив институты белән берлектә фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр алып барыла торган мәйданчык. Инде бүген үк безнең студентлар галимнәр җитәкчелегендә төрле фәннәрдән лаборатория эшләрен башкара.

2022 елда Әлмәт дәүләт нефть институты Edunews белем бирү платформасы карашы буенча **НЕФТЬ ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ РЕЙТИНГЫНДА 7 НЧЕ УРЫН АЛА** һәм иң динамик үсештәге югары уку йорты дип бәяләнә. Платформаның аналитиклары, бәя биргәндә, төрле күрсәткечләрне: инновацион активлык, фәнни казанышлар, инфраструктура, студентларның фикерләрен исәпкә ала.

БЕЛЕМ БЕЛӘН ФӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ ТУРЫНДА

– Югары уку йорты студентларын нинди яңа уку-укыту программалары көтә?

– Бакалавриатта техносфера куркынычсызлыгы, программалау инженериясе юнәлешләре ачылды.

Бүген Әлмәт дәүләт нефть институты белән ИТМО илкүләм тикшеренү университетының (Санкт-Петербург) Алдынгы инженерлык мәктәбе дип исемләнгән уртак проекты тормышка ашырыла. Әлеге проект кысаларында без бу уку елына табигый фәннәр, IT һәм үтәли цифрлы технологияләр өлкәсе студентлары өчен магистратурага алдынгы белем бирү программалары булдырдык. Планда – студентларны укыту гына түгел, ә аларның дөньякүләм танылган галимнәр җитәкчелегендә фәнни лабораторияләрдә продуктка алуга юнәлтелгән яки фәнни проектлар белән шөгыльләнүе. Белем бирү секторы һәм югары технологияле җитештерү өлкәсенең фәнгә һәм проектлы уку-укытуга йөз тоткан коллаборациясе бизнесның реаль секторына технологияләрнең тиз күчешен тәэмин итәргә тиеш.

Бәлки, быелдан ук, мәсәлән, нефть ятмаларын эшкәртү һәм эксплуатацияләү кафедрасы кысаларында параллель рәвештә сәнәгать биотехнологияләре белгечлеген кертеп булыр. Асылда, нефть эшенең әүвәлгечә күчле юнәлешләре базасына дисциплинаара предметлар, өстәмә белемнәр һәм күнекмәләр кертергә кирәк. Без шундый белем алган белгечнең көндәшлектә өстенлеккә ия булачагына инанып эшлибез.

– Әмма көндәшлеккә сәләтле белгеч укытып чыгару өчен белем ягыннан әзерлек җитәрлек түгел...

– Көндәшлеккә сәләтле белем бирүнең төп шарты – укытучы-тикшеренүчеләр тарафыннан студентларның фәнни-тикшеренү процессына җәлеп ителүе.

Әлмәт дәүләт нефть институтында уку һәм укыту өчен бик куәтле стимул иң яхшы материаль базада тикшеренүләр үткәрү мөмкинлегеннән гыйбарәт. Хәзер югары уку йортының инфраструктурасы без булдыра алганга караганда да күбрәк мөмкинлек бирә.

БАШКАЛАРДА БУЛМАГАННАР ТУРЫНДА

– Башка югары уку йортларыннан кайсы мөһим аермагыз белән сез чынлап та горурлана аласыз?

– Беренче һәм төп өстенлегебез шунда: без бүген башка институтлардан яңа коллективларны җәлеп итеп, көчле белем бирү трансформациясен гамәлгә ашырабыз. Төрле коллективларның синергиясе хисабына биредә, Татарстанда, илебездә иң яхшысы булачак һәм дөнья күләмендә билгеле бер дәрәҗә яулаячак югары нефть мәктәбе барлыкка килер, дип ышанабыз.

Без нәкъ Ромашкино ятмасында урнашканбыз. Яңа кампустан берничә йөз метр ераклыкта бораулау каланчасы эшли, тирә-якта нефть суыра торган насослар, «баш»ларын әле аска иеп, әле өскә күтәреп, кара алтын чыгарып тора. Без индустриаль партнерлар белән бик якын бәйләнештә торабыз. Әлеге мөһим өстенлек уңышлы хезмәт карьерасы корачак белгечләр әзерләп чыгарырга мөмкинлек тудыра.

Альметьевский государственный нефтяной институт
Высшая школа нефти

423450, Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 2
8 (8553) 31-00-21 кабул иту комиссиясе (abiturient@agni-rt.ru)
8 (8553) 31-00-04 ректорның кабул иту булмәсе (p.agni@agni-rt.ru)
www.agni-rt.ru 16+
t.me/agni asoi
vk.com/agni asoi


www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмияте
Игелекле
Мәңгелек
Татарстан авыллары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность
Реклама 16+

акыллы
гамәлләр
игелекле мәңгелек
кыйммәтләр
эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Хобби **ничек** тормыш мәгънәсенә әверелә

Бизнесны **ничек** төзергә

Миллион сумга балаларны **ничек** бөер авыруыннан коткарырга

Чабагач белән **нәрсә** эшләгәннәр



ТАТАРСТАН МИЛЛИОНЕРЛАРЫ





Һәр миллионның нигезендә миллионлык идея ята. Мондый идеяне каян алырга? Миллионны ничек табарга? Үз идеяң өчен миллионны ничек отарга? Миллионнарыгызны ничек дөрес тотарга? Миллионнар бетмәсен өчен ничек эшләргә? Миллионер булып, ничек миллиардерга йөз тотарга?

Бу сорауларга Татарстан миллионерлары җавап бирә.

НИЧЕК МИЛЛИОН СУМНЫ ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН «ПИОНЕР ЛАГЕРЕ» ТӨЗҮГӘ ТОТАРГА



Богдан Ткаченко

Ничек итеп учак янындагы «пионер» очрашулары, ял итү һәм туйлар үткәрү өчен иң яраткан урынга әйләнгән глэмпинг төзергә? Казандагы бер гаилә, үзенең беренче миллион сумын бик уңышлы файдаланып, әлеге сорауга җавап тапкан һәм миллионнарны чыгымнардан рәхәтлек алырлык итеп туздыру буенча киңәшләре белән уртаклашырга әзер.

Глеб Кузнецов белән Дарья Измайлова – ир белән хатын. Бераз вакыт кына элегрәк гаилә башы зур нефть эшкәртү компаниясендә юрист булып эшләгән, хәләленең исә матурлык салоны булган. Әмма менә ел ярым инде алар бергә эшли – Яшел Үзән районында төрле чаралар үткәрүгә тәгаенләнгән глэмпинг төзү һәм эшләтеп җибәрү белән мәшгульләр. Аларның локациясе бигрәк тә яңа өйләнешүчеләр күңеленә хуш килгән. Барлык җомга һәм шимбәләргә инде өч ай алдан заказ биреп куелган. Үз миллионнарын гына куркыныч астына куеп калмыйча, инвесторлар да җәлеп итәргә туры килгән. Проектның бәясе башта планлаштырылган 12 миллионнан 40 миллион сумга кадәр арткан. Дөрес,

Фотолар Глеб Кузнецов һәм Дарья Измайлованың шәхси архивыннан

яшь эшкуарлар әйтүенчә, алар әлеге сумманы дөрес сайланган концепция нәтиҗәсендә тиз арада кире кайтара алган.

– Әти-әниләребез дә, дусларыбызның күпчелеге дә безнең ниятнең барып чыгасына ышанмады, – ди гаилә башлыгы. – Мине исә бу хәл җилкендерде генә. Мин «Сибур»да, башка урыннарда эшләдем. Бу – күңелсез. Кемгәдер эшләп туйдым. Нәрсә ниятлисең, шуны эшлә, барып чыгамы-юкмы – күренер аннары. Мин әлеге проектка, нәтиҗәсе нинди булуга карамастан, барыбер алыныр идем. Чөнки мине нәкъ менә шул рухландыра. Әгәр эш синең мавыгуыңа әйләнә икән, димәк, гомереңбуена эшләмәячәксең – ул синең өчен хобби гына булачак.

УЧАК ЯНЫНДА ГИТАРА БЕЛӘН

– Чыннан да, төрле форматтагы чаралар үткәрү мәйданчыклары булган шәһәрдән читтәге объектларга базарда ихтыяҗ зур, – дип сөйли Дарья Измайлова. – Ә Казан янында алар юк диярлек. Шунлыктан без өлкәннәр өчен лагерь ясарга булдык. Кеше табигатькә хозурланып уңайлы йортта ял гына итеп калмый, бәлки аны балачактагы кебек сәгатьләп бүленгән программа көтә. Иртәнге 8 дә – физкультура, аннары иртәнге аш һ.б.

Глеб Кузнецов әйтүенчә, халык матур итеп кич утыруларны сагына, шунлыктан учак янында зона пәйда булган, анда гитара яратучылар җыела. Һәркемнең дә сыйфатлы ял итәсе килә. Мәсәлән, глэмпингта күптән түгел әниләр көне үткәрелгән. Махсус бала караучылар ялланган, әниләр исә кайнар чанда коена, рәхәтләнеп ял итә алган, ашарга пешерү турында да кайгыртасы булмаган...

УҢЫШЛЫ КЕРТЕМ

Глэмпинг урыны очраклы гына табылган. Бер туганнарының ниндидер хуҗалык корылмасы гына төзеп куелган ике кишәрлеге булган. Әгәр ул тиз арада капиталь бина төземәсә, утарларыннан колак кагу куркынычы янаган. Глеб һәм Дарья янәшәдәге кишәрлекләрне дә сатып алган, аларның бер өлешен күчемсез мөлкәткә әйләндергән һәм шул рәвешле туганнарын да коткарган.

– Без моның ял итү өчен бик шәп урын булуын аңладык, – ди Дарья Измайлова. – Безне калкулыклар әйләндереп алган, янәшәдәге инеш исә Зөягә коя – бик матур. Модульле йортларны исә алар инде әзер хәлдә килгән өчен куярга булдык, төрле подрядчыларга түләп азапланасы юк. Аларны тулысынча әзер килеш китерәләр, коммуникацияләрне генә тоташтырасы кала. Бәяләре дә кызыктыргыч, йортның тибына карап – 2–2,4 миллион сум.

ҖИҢГӘННӘР ҺӘМ ӨСТӘГӘННӘР

Эшкуарлар корылмаларның бер өлешен дәүләт акчасына да төзегән. Алар «Туристлык һәм кунакчыллык индустриясе» милли проекты кысаларындагы субсидияләр бирелү конкурсында 18 җиңүченең берсе булган. Әмма үзләренең дә күп акчасы кергән. Шунлыктан, шәхси миллионнары да өстәлсә булгач, төзелешкә бик җентекләп керешкәннәр.

– Төзелеш материаллары, җиһазлар сатучыларда бәя 10 тапкырга кадәр аерылырга мөмкин, – дип аңлата Глеб. – Күп эшкуар үзләренең глэмпинглары өчен сатып алынган нәрсәләрнең чын бәясен белми дә, төзүче һәм подрядчылар исә моннан файдаланып калырга ашыга.

Әгәр инде кирәкле агачны үзең табып, үзең буыйсың, каркасын үзең торгызасың икән, әлбәттә, күпкә арзанрак килеп чыга. Мин бер-ике елда боларны мөстәкыйль эшләүдә бик остардым. Скважинаның эчке төзелешен дә, кая нинди розетка куясын да хәзер бик яхшы беләм.

Әгәр мин кайдадыр тагын шундый ук объект төзесәм, нәрсә кирәген хәзер бик яхшы белер идем. Безгә еш кына белгечләр ялларга киңәш бирделәр. Тик без, барысын да тикшереп, көн саен үзебез шунда кайнап, укып-өйрәнеп, белгечләр белән киңәшеп, күпкә арзанрак итеп төзеп чыктык. Бу проектыбызга подрядчылар яллаган булсак, ул һичшиксез йөз миллион сумга төшәр иде.

МИЛЛИОНЕР ГЛЕБ КУЗНЕЦОВ КИҢӘШЕ:

НӘРСӘ НИЯТЛИСЕҢ, ШУНЫ ЭШЛӘ, БАРЫП ЧЫГАМЫ-ЮКМЫ – КҮРЕНЕР АННАРЫ. МИН ӘЛЕГЕ ПРОЕКТКА, НӘТИҖӘСЕ НИНДИ БУЛУГА КАРАМАСТАН, БАРЫБЕР АЛЫНЫР ИДЕМ. ЧӨНКИ МИНЕ НӘКЪ МЕНӘ ШУЛ РУХЛАНДЫРА. ӘГӘР ЭШ СИНЕҢ МАВЫГУЫҢА ӘЙЛӘНӘ ИКӘН, ДИМӘК, ГОМЕРЕҢ БУЕНА ЭШЛӘМӘЯЧӘКСЕҢ – УЛ СИНЕҢ ӨЧЕН ХОББИ ГЫНА БУЛАЧАК.

ЧИТ КЕШЕГӘ КАРАГАНДА, ГАИЛӘ БЕЛӘН ЯХШЫРАК

Мондый катлаулы бизнес белән шөгыльләнә башлавына гаилә әлегә бер дә үкенми. Клиентлар базасы киңәя, инвесторлар канәгать, глэмпинг белән идарә итү – мавыктыргыч процесс. Глеб еш кына яңа кертемнәр таләп иткән яңа идеяләр белән яна башлый, ә Дарья исә аны күктән җиргә төшерә – башта чыгымнарны капларга кирәк бит әле. Һәм мондый тартышлар даими күзәтелә. Мондый бизнес гаилә мөнәсәбәтләренә комачауламыймы соң, дигән соравыбызга Глеб Кузнецов:

– Киресенчә, катлаулы бурычлар берләштерә бит. Глэмпинг төзегән арада безнең сабыебыз туды – һәм бу безне чын-чынлап бик якынайтты. Сүз дә юк, бизнесны чит кешегә караганда җәмәгатең белән алып бару күпкә отышлырак... Әйләнә-тирәгә күз салыгыз әле. Кешеләр иҗат белән аз шөгыльләнә. Мин радио һәм телевидение мәктәбен тәмамладым. Яшь чагымда «Миллениум» радиосында эшләдем. Һәм минем эчемдә һәрвакыт ниндидер бер чикерткә утыра, ул һаман яңа эшләргә рухландыра. Бернәрсә эшләмәгәндә генә яшәве күңелсез ул, – дип җавап бирде.



Фәрит Заһидуллин гадәти миллионер түгел. Үзенең бар мөлкәтен чын мәгънәсендә үз куллары белән эшләп тапкан. Ул чүпрәсез икмәк пешерә һәм үз эше турында шундый яратып сөйли ки, аны сәгатьләр буе тыңлап була. Ул әле керемнәрен һәм чыгымнарын да, көненә күпме икмәк пешерүен дә санамый һәм үзенә ничә яшь булуын да әйтми. Ни өчен икәнен укыгач аңларсыз.

НИЧЕК **МИЛЛИОН** СУМЛЫК ИКМӘК ПЕШЕРЕРГӘ

Богдан Ткаченко

Казандагы агросәнәгать паркына килүчеләрнең күбесе бу кибет янында гаҗәпкә кала. Анда инде 6 ел буе үзеңә үзең хезмәт күрсәтәсең: икмәкне аласың, акчасын махсус янчыкка саласың да, китәсең.

– Мин ул чакта башкача өлгерә алмый идем, – ди Фәрит Заһидуллин. – Йә кибеттә көн үткәрергә, йә икмәк пешерергә кирәк. Һәм мин тәвәккәлләргә булдым: бәясен күрсәттем дә, икмәкне калдырып киттем. Кешеләр янчыкка салып калдырган акчаны иртән санап караган идем – берниндн алдашу да юк. Ул уйлаганча булып чыга: сатып алучылар да канәгать, икмәк пешерүченең дә вакыты сарыф ителми.

БАЛАЧАК ИСЕ

Фәрит Заһидуллин икмәкне үзе ясаган уникаль оеткы белән пешерә, аны әзерләүдә исә иң гади ингредиентлар – су, он һәм тоз гына куллана. Моннан берничә ел элек ул пешергән икмәк кибеттәгедән 4 тапкырга кыйбатрак булган. Әмма шул чактан бирле ул бәясен күтәрмәгән, инфляция хисабына аерма ике тапкырга кимегән.

– Мин бала вакытта әбекәем пешергән икмәкне хәтерлим, – дип исенә төшерә эшкуар. – Аның онга чумган зәңгәр алъяпкычы һәм яңа пешеп чыккан икмәкнең искиткеч хуш исе исемдә... Нәкъ менә шул чактагы тәм һәм исне табуга мин берничә ай сарыф иттем.

НИШЛӘРГӘ БЕЛМӘСӘҢ – БАШКАЛАРГА БУЛЫШ

Фәрит үзенең ничек икмәк пешерүче булып китүен үзе дә сизми калган. Армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, 1976 елда бизәүче-рәссамлыкка укырга кергән. Партия район комитетлары каршындагы сәнгать остаханәләрендә эшләгән. Әмма Советлар Союзы таркалгач, аның агитация плакатларына ихтыяҗ беткән.

Агачка уеп рәсем ясаучыга әйләнгән. Байларның йортларын бизәгән. Әмма озакламый бу да модадан чыккан...

– Алга таба нишләргә белми аптыраганда, мин хәйриячелек белән шөгыльләнә башлыйм. Бу эшләрне эшләгәндә яңа идеяләр пәйда була, – ди икмәк пешерүче. – Ул чакта без бер балалар

Фотолар Фәрит Заһидуллинның шәхси архивыннан

йорты өчен миллион сумлык зур проект эшләдек. Иганәче бөтен чыгымнарны каплады, минем бер тиенем дә юк иде. Әмма шуны яхшы аңладым: минем ике кулым бар, һәм мин алар белән кояш батканнан алып таң атканчыга кадәр эшли алам бит. Шунда уйлап куйдым да инде: бәлки, икмәк пешерергәдер?..

ИКЕЛӘТӘ АРТЫК ТҮЛӘГӘНДӘ, ДИНАСТИЯ ТУА

Башта Фәрит икмәген үзе туган Биектау районы Мәмдәл авылында пешереп тарата. Әмма 2013 елда Рөстәм Миңнехановның сүзенә колак сала һәм үз көчен Агросәнәгать паркында сынап карарга була – әлеге мәйданчык үз куллары белән нәрсәдер җитештерүчеләргә тәгаенләнә бит.

Заһидуллинның ун ел гомере бер үк төрле диярлек үтә: төнге сәгать бердә ул камырның кабарганмы-юкмы икәнен торып карый, аннары мичен кабызып пешерә, иртән икмәкне Казанга илтә, сата, кичен, өйгә кайтканда, чишмә суын ала кайта, он тарттыра, камыр куя... Көн саен шулай кабатлана. Шул рәвешле беренче миллион сум эшләп табыла...

Фәрит хәзер үз продукциясен күпме кеше алачагын төгәл белә. Шунлыктан бүген ничә икмәк пешерәсен, моңа күпме акча сарыф итүен һәм күпме керем алуын да санамый.

Әмма бервакыт Фәрит авырып китә. Базарда ике көн буе икмәк сатылмый. Бик күп кеше аны эзли. Шул вакытта Заһидуллин үзенә алмаш турында уйлана башлый.

– Улым машиналар ремонтлый, акчаны яхшы ала иде, – ди эшкуар. – Һәм мин хәйләләргә булдым. Аңа автосервистагыдан ике тапкыр артыграк эш хакы тәкъдим иттем. Мондыйдан кем баш тартсын инде? Әле этигә булышуыңны да аңлыйсың.

ИКМӘК БУЛ!

Бергә эшли башлыйлар, әмма әле улы үзе икмәккә әйләнгәнче, бер ел вакыт үтә. Ягъни, җитештерү процессына тулысынча кереп киткәнче. Хәзер исә, этисе әйтүенчә, гаилә эшен улы инде беркайчан да ташламаячак. Оньк та гаилә бизнесына җәлеп ителә.

– Мин инде хәзер җитәкчелек кенә итәм һәм ышанычлы тыл булып торам. Минем тәҗрибәм зуррак, матди яктан да аякта нык басып торам. Егетләр бернәрсәдән дә курыкмый, шунлыктан бик көйле эшли.

ИКМӘК КОЛЫ

– Кеше ипекәй белән бербөтенгә әйләнгәч кенә, үзе дә икмәккә әйләнә, – дип үз фәлсәфәсен аңлата Заһидуллин. – Ни өчен бу бизнеста күп кешенең эше уңмый? Чөнки алар икмәк ӨСТЕНДӘ тора, алар – аның хуҗасы. Катысы кетердәп торсын дип, бер порошок сибә. Кабарып торсын дип – икенче порошок. Әйе, ул билгеле бер вакыт эчендә кабара ала. Тәме төрле булса да, мичтән бер үк төрле күмәчләр чыга.

Ә мин икмәк өстендә түгел, аның АСТЫНДА. Мин – үз продуктымның колы. Әгәр син үзеңнең эшеңне яратасың һәм нәтиҗә булсын дип эшлисең икән, син – кол. Икмәк мине аңлый. Чөнки минем хөрмәтемне тоя. Бу хәтта кулга да бәйле. Баштарак минем кәефем начар чаклар бар иде, эшемнең уңасына ышанмый идем – шул чакта икмәк тә кабармый иде...

Бүген Заһидуллин 7 төрле икмәк пешерә, гәрчә чималның төрле сортлары белән әллә никадәр тәҗрибәләр үткәрергә мөмкин булыр иде. Әмма моның кирәге бармы соң?

– Җитештерүне арттыру өчен, кредитлар алырга, зуррак биналар арендаларга кирәк, продукциянең күләмен ишәйткәндә, барыбер сыйфатка да зыян килә, – дип саный икмәк пешерү остасы. – Мин исә гаиләмнең физик көче җиткән кадәр генә продукция җитештерәм. Бу бик авыр хезмәт. Күбрәк пешерер өчен, Заһидуллиннарның клонын ясарга кирәк, ә бу мөмкин түгел, – дип әллә шаярта, әллә җитди сөйләшә Фәрит.

МИЛЛИОНЕР ФӘРИТ ЗАҺИДУЛЛИН ФОРМУЛАСЫ:

– МИН – ҮЗ ПРОДУКТЫМНЫҢ КОЛЫ. ӘГӘР СИН ҮЗЕҢНЕҢ ЭШЕҢНЕ ЯРАТАСЫҢ ИКӘН, СИН – КОЛ. ИКМӘК МИНЕ АҢЛЫЙ. ЧӨНКИ МИНЕМ ХӨРМӘТЕМНЕ ТОЯ.

НИ ӨЧЕН ИКМӘК КЫЙБАТ?

Кайбер сатып алучылар икмәкнең кыйбат булуыннан зарлана – эшкуар моны аларның әлеге продуктка керткән хезмәт күләмен аңламаудан, дип саный. Яхшы товар кыйбат булырга тиеш. Ул үз кибетендә сынап караган. Бер тәүлектән артыграк яткан икмәкне 2–3 тапкырга арзанайтып саткан, гәрчә ул кимендә 3 тәүлек бик яхшы саклана әле. Шул мизгелдә үк кулдан пешерелгән ипине үзләренең... тавыкларына сатып алырга теләүче әбиләр пәйда була.

– Тагын шунысы да бар: әгәр мин икмәк бәясен арзанайтсам, ул бөтен алырга теләгән кешегә дә җитмәячәк бит...

ҮКЕНМӘ, УФТАНМА!

Заһидуллин элеккечә үк хәйриячелек белән шөгыльләнә. Мәсәлән, ул 1941 елда туган сугыш балаларын үз химаясенә алган.

– Мин бик яшь вакытта бу кешеләр минем башымнан сыйпыйлар иде, бу минем аларга рәхмәтем, – ди эшкуар.

Һәм тагын бер нәрсә: Фәрит Заһидуллин үзенә ничә яшь булуын әйтергә теләми.

– Мин үз яшьтәшләрем янына барсам, алар зарлана башлый: янәсе, картайганнар, яшьлекләрен сагыналар, әллә нинди җырлар тыңлыйлар... Бернәрсәгә дә үкенмә, бүгенге көн белән яшә! Син файда китердеңме? – Сөенеч бу. Йокыдан уяндыңмы, бер җирең дә авыртмыймы – бусы да сөенеч. Шулай яшә дә яшә!

НИЧЕК ИТЕП КҮПЕР САЛУГА МИЛЛИОН СУМ ТАБАРГА

Ульяна Макарчикова

КДАТУ аспиранты Дмитрий Ерохин безнең күперләрне ныграк һәм чыдамрак итү ысулын тапкан. Әмма ул шуны белә: дәүләт ярдәменнән башка аның ачышы һаман киштәдә ятар иде әле.

Дмитрий Ерохинның гадәти булмаган мавыгуы бар. Укудан һәм бизнестан буш вакытында ул экспертлар оешмасы белән күпер корылмаларын тикшереп йөри. Татарстандагы 300 гә якын һәм Россиядәге йөзләп күперне шулай әйләнеп чыккан инде. Ул моны күперләрдән файдалану процессында нинди проблемалар килеп чыгуын аңлар һәм әлеге белемне үзенең эшләнмәләрендә кулланыр өчен эшли.

БЕРЕНЧЕ КАРАШКА ГЫНА КАТЛАУЛЫ ҺӘМ АҢЛАЕШСЫЗ

Дмитрий Ерохин – КДАТУ аспиранты. Беренче миллионын ул «Студентлар стартабы» конкурсында катнашып алган. Егет күпернең тимер-бетон терәкләрендәге по-

Фото Дмитрий Ерохинның шәхси архивыннан

лимер-бетон кысалар әзерләүдә кулланыла торган сүс арматуралы полимер-бетон составын уйлап таба. Бу беренче карашка гына катлаулы һәм аңлаешсыз булып тоела. Әмма Дмитрий Ерохин ачышы төзелеш тармагы өчен чыннан да бик файдалы булырга мөмкин. Әлегә аның ачышы сынала гына.

ЧЫДАМРАК ҺӘМ НЫГРАК ИТҮ ЫСУЛЛАРЫ

– Төзүчеләр корыч, тимер-бетон, агачтан файдаланырга күнеккән. Әмма бу материалларның кимчелекләре бар. Билгеле ки, аларның химик һәм биологик ныклыгы төрле, әмма алар барысы да күгәрә һәм чери. Моңа бәйле рәвештә, полимер чималдан ясалган төзелеш материалларын куллануны арттыру максатка ярашлы булып тора. Бу төзелеш конструкцияләренең чыдамлыгын, химик һәм биологик ныклыгын арттыру мөмкинлеген бирә. Мин нәкъ менә шуларны күпер төзелешендә файдалану юлларын эзлим. Конструкцияләрдәге тимер-бетон һәм корыч әйләнә-тирә мохитнең көчле тәэсиренә бирешә, һәм терәкләрнең, башка элементларның хезмәт итү вакыты уртача 60 ел тәшкил итә. Ә полимер-композит материаллардан ясалган конструкцияләр кулланып салынган күперләр уртача 80-100 елга чыдар иде. Бу очракта ремонт эшләре интервалы да арта. 20 елга бер тапкыр гына тикшерергә һәм кимчелекләрне ачыкларга, алар табылса, төзәтергә мөмкин. Мондый төзелеш материалларын кулланудан файда корылманың 50 ел эшләү дәверендә бик зур булачак.

«УМНИК» БӘЙГЕСЕННӘН БЕРЕНЧЕ СТАРТАПКА КАДӘР

Үзенең тәүге «Умник» конкурсында ул магистратураның беренче курсында укыганда ук җиңгән. Бу студентка күперләрнең тимер-бетон терәкләрен көчәйтү эшләнмәләренә башыннан чуму мөмкинлеген биргән. Нәкъ менә шул вакытта аның башына күпер корылмаларының өрлекләрен әзерләү өчен бик чыдам полимер-композит материаллардан файдалану идеясе килгән.

– «Студентлар стартабы» миңа шундый төзелеш материалларын әзерләүгә керешү мөмкинлеген бирде дә инде, – ди Дмитрий Ерохин. – Мин габарит үлчәмнәре һәм чыдамлыгы буенча корыч конструкцияләргә тәңгәл, әмма шул ук вакытта үзләрен буяуга яки цинк белән каплауга мохтаҗ булмаган полимер-композит конструкцияләр уйлап табарга тырышам. Менә хәзер профильле эшләнмәләр кою өчен кирәкле җиһазларга заказ бирдем әле.

Яңа төзелеш материалларын ныклыкка сынауда һәм башка үзлекләрен билгеләүдә миңа КДАТУ лабораториясендә булышалар.

Быел Дмитрий полимер-бетон катнашма составына да, профильле эшләнмәләрне ясау технологиясенә дә патент алырга гариза бирергә җыена.

ИҢ МӨҺИМЕ – БЕРНӘРСӘДӘН ДӘ КУРЫКМАУ

– «Студентлар стартабы» ярдәменнән башка бөтен нәрсә күпкә катлаулырак булыр иде һәм мин, ихтимал, үз җитештерүемне башларга җөрьәт итмәс идем, – ди аспирант. – Үзең эшләп тапкан акча белән мондый эшкә тәвәккәлләү куркыта, бигрәк тә уңай нәтиҗә гарантияләнмәгән очракта. Ә инде синең идеяңне тәҗрибәле белгечләр хуплый һәм дәүләт, синең эшеңә инвестиция кертеп, сынауларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген бирә икән, үзеңнең фәнни проектларыңны үзеңә тормышка ашыру, технологик эшкуарлык тармагында уңышларга ирешү теләге туа.

МИЛЛИОНЕР ДМИТРИЙ ЕРОХИН ТЕЛӘГЕ:

– СИНЕҢ ИДЕЯҢНЕ ТӘҖРИБӘЛЕ БЕЛГЕЧЛӘР ХУПЛЫЙ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ, СИНЕҢ ЭШЕҢӘ ИНВЕСТИЦИЯ КЕРТЕП, СЫНАУЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МӨМКИНЛЕГЕН БИРӘ ИКӘН, **ҮЗЕҢНЕҢ ФӘННИ ПРОЕКТЛАРЫҢНЫ ҮЗЕҢӘ ТОРМЫШКА АШЫРУ, ТЕХНОЛОГИК ЭШКУАРЛЫК ТАРМАГЫНДА УҢЫШЛАРГА ИРЕШҮ ТЕЛӘГЕ ТУА**.

Дмитрий әйтүенчә, фәнни һәм эшкуарлык эшчәнлеген яраштыру җиңелләрдән түгел. Әмма бу кирәк.

– Фәнни проектка грант бирергәме-юкмы икәнен хәл итүче экспертлар һәрвакыт шуны әйтә: барыннан да элек үз эшләнмәңә ничек тә тизрәк патент алырга кирәк. Һәм шундук ахыр кулланучыга тәгаенләп эшли башлау зарур. Иң мөһиме – бернәрсәдән дә курыкмау. Мин бер үк вакытта аспирантурада да укыйм һәм, үз эшләнмәләремне әзерлек стадиясенә китереп җиткерү өчен, фәнни тикшеренүләр алып барам, чөнки грант алу шартларыннан берсе – эшкә сәләтле продукт булдыру.

Ерохинга үзе шөгыльләнгән тармак бик ошый.

– Күпер – тере организм кебек ул, – ди аспирант. – Хәтта бер үк типтагы проектныкы булып, ике күпер янәшә торса да, алар икесе ике төрле: һәркайсына үзенең агрессив мохите, үз йөкләнешләре тәэсир иткәнгә, алар бөтенләй икесе ике төрле халәттә була ала.

МИЛЛИОНГА БАЛАЛАРНЫ БӨЕР АВЫРУЛАРЫННАН НИЧЕК КОТКАРЫРГА

Ульяна Макарчикова

Лилия Дәүлиева Казан дәүләт медицина университетында аспирантураны тәмамлаган диярлек. Уку вакытында ук ул гемолитик-уремик синдром белән авырып алган балаларда хроник бөер авыруы (ХБП) үсеше мөмкинлеген диагностикалау ысулын уйлап таба. Әгәр дә мондый авыруның барлыкка килү мөмкинлеген танысак, дәвалауны да алдан башларга мөмкин.

Фото Лилия Дәүлиеваның шәхси архивыннан

– Балаларда эчәк эшчәнлеге бозылу һәрвакытта да эзсез үтми, – ди Лилия. – Кайбер штаммнар бөерләргә кискен зыян китерә. Мондый авырулар озак вакыт реанимация бүлегендә ята ала, ә аннары даими рәвештә диспансерда исәптә тора. 5-6 ел дәвамында аларда хроник бөер авыруы барлыкка килә. Шуның аркасында алар диализга утырырга мөмкин.

Дәвалану бик кыйммәт, моның өчен елына якынча бер миллион ярым сум акча китә. Гадәттә мондый авыру белән 3-5 яшьлек балалар авырый, һәм бала үскәнче, аны дәвалау өчен шактый зур сумма акча түләргә туры киләчәк.

«СТУДЕНТЛАР СТАРТАБЫ» НА ГАРИЗА

Барлык кирәкле тикшеренүләр үткәрү, канда серотонин дәрәҗәсен фаразлый торган сервис булдыру өчен, Лилиягә акча кирәк була. Ул «Студентлар стартабы» конкурсына гариза бирә һәм уйлап тапкан ачышы өчен миллион сум акча ала. Хәзер ул хроник бөер авыруы мөмкинлеген исәпләп чыгару формуласын һәм исәпләүләр алып барылачак ЭВМ өчен программаны патентлый.

ОЧРАКЛЫЛЫК ҖИМЕШЕ

– Чынлыкта, әлеге темага алынуым очраклы рәвештә килеп чыкты, – дип искә төшерә Лилия Дәүлиева. – Мин фән белән шөгыльләнергә, аспирантурага керергә теләдем. Шул вакытта фәнни җитәкчем Тамара Макарова миңа әлеге теманы тикшерү белән шөгыльләнергә тәкъдим итте, гәрчә Россиядә мондый фәнни тәҗрибәләр үткәрелмәсә дә.

Һәм өч ел дәвамында «каз бәбкәләре белән» (ул үзенең кечкенә пациентларын яратып шулай дип атый - авт.) тырышып эшли торгач, хезмәтнең җимешләре дә күренә.

УЙЛАП ТАБУНЫ НИЧЕК КОММЕРЦИЯЛӘШТЕРЕРГӘ

– Грант булмаса, мин үз темамны яклап, патент алсам да, барысы да шуның белән тәмамланыр иде. Ләкин «Студентлар стартабы» шартлары буенча үз уйлап табуыңны коммерцияләштерергә кирәк. Моны ничек эшләргә кирәклеге турында да уйларга туры килде.

БУ ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ КЕБЕК

Үз эшеңне ачаргамы? Ләкин бухгалтерлык эшен кыз бөтенләй белми. ХБП авыруы мөмкинлеген исәпләү өчен телефон кушымтасы ясарга? Ләкин бу бик кыйммәт булып чыга. Шуңа күрә программистлар белән бергә әлеге сервисны һәм сайтны эшлиләр.

– Бу ясалма интеллект кебек, – ди Лилия Дәүлиева. – Баланың серотонин дәрәҗәсе буенча мәгълүматны программага кертәсең, һәм ул минем формула буенча барлык мөмкин булган куркынычларны исәпләп чыгара. Әгәр авыру ихтималы зур булса, баланың сәламәтлеген контрольдә тоту көчәйтелә, алдан ук нефропротектив терапия үткәрергә дә мөмкин.

МИЛЛИОНЕР ЛИЛИЯ ДӘҮЛИЕВА ЮЛЫНДАГЫ ОЧРАКЛЫЛЫК:

– ӘЛЕГЕ ТЕМАГА АЛЫНУЫМ ОЧРАКЛЫ РӘВЕШТӘ КИЛЕП ЧЫКТЫ. МИН ФӘН БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ, АСПИРАНТУРАГА КЕРЕРГӘ ТЕЛӘДЕМ. ШУЛ ВАКЫТТА ФӘННИ ҖИТӘКЧЕМ ТАМАРА МАКАРОВА МИҢА ӘЛЕГЕ ТЕМАНЫ ТИКШЕРҮ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ ТӘКЪДИМ ИТТЕ, ГӘРЧӘ РОССИЯДӘ МОНДЫЙ ФӘННИ ТӘҖРИБӘЛӘР ҮТКӘРЕЛМӘСӘ ДӘ.

САЙТ БУШЛАЙ, ДӘВАЛАУ ТҮЛӘҮЛЕ

Гемолитик-уремик синдром белән нигездә яз һәм җәй көннәрендә күп авырыйлар. Татарстан әлеге йогышлы авыру тарала торган төбәк саналмый. Әмма соңгы вакытта Чаллы һәм Түбән Камадан күп балалар килә. Шуңа күрә сайт алар өчен бик файдалы булырга мөмкин.

– Сайтта авыру ихтималын исәпләү үзе бушлай булачак, – ди Лилия Дәүлиева. – Ләкин доктор консультациясе, онлайн күзәтү – барысы да, әлбәттә, түләүле. Бер яктан, Казаннан булмаган балаларның ата-аналарына бу вакытны янга калдырырга булыша, шул ук Чаллыдан табибка дип, чит шәһәргә барырга кирәк булмаячак. Икенче яктан, әгәр дә миңа акча бирелмәгән, грант шартларында үзем уйлап тапкан ачыш белән акча эшләргә тиеш дип язылмаган булса, бу сервис булмас иде.

МЕДИЦИНА ЛИЦЕНЗИЯСЕН КӨТЕП

Әмма әлегә аның фирмасы халыкка хезмәт күрсәтә алмый. Лилия яшь белгечләргә ярдәм итүнең башка программаларына да мөрәҗәгать итәргә планлаштыра, чөнки ул медицина лицензиясен алырга тели. Һәм шул вакытта аның проекты тулы куәтенә эшли башлаячак.



Наилә Әхмәдуллина – 2022 елгы «Студентлар стартабы» Бөтенроссия конкурсында җиңүче. Ул үзенең төркемдәше Зәйнәп Хәертдинова белән бергә «Җамалт – татар шамаиле сәнгате» бизнес-проектын үстерүгә миллион сум акча ота.

ХОББИ ӨЧЕН НИЧЕК МИЛЛИОН ОТАРГА

Елена Симакова

Шамаил – изге урыннар сурәтләнгән, шулай ук Коръәннән афоризмнар һәм гыйбарәләр язылган стена панносы. Традиция буенча текстны пыялага трафарет яки калька ярдәмендә буяу белән язганнар. Аның астына бөгәрләнгән нәзек фольга салалар, бу исә ялтырау эффекты тудыра. Әзер әйберне кысага урнаштыралар.

Проект авторлары бизәк ясау процессын гадиләштерергә тәкъдим итә. Шулай итеп, алар пыяланы үтә күренмәле пластик белән алыштыралар. Ә рәсем урынына CorelDRAW график редакторында сурәт ясыйлар. Мондый технология арзанрак һәм вакытны янга калдыра.

– Без күптән түгел генә эшли башладык, – ди Наилә. – Әлегә җиһазлар юк, эскизлар гына әзер. Әмма безнең продукция белән кызыксынучы кешеләр пәйда булды инде. Кайберәүләр панноны бүләк буларак сатып алырга, икенчеләре интерьерларын бизәргә теле. Вак заказлардан башлыйбыз. Ләкин без зур масштабларга ирешергә омтылабыз.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ЭЗЛӘҮ

– Әнием сөйләве буенча, өч яшемдә үк кайчыларны дөрес тотарга өйрәнгәнмен, төрле фигуралар кисеп уйнарга яраткан-мын, – дип искә ала Наилә. – Ул кәгазьдән уен комплектларын сатып ала иде, мин алардан сәгатьләр буе аерыла алмадым...

Бишенче сыйныфта әти-әнисе кызын балалар сәнгать мәктәбенә укырга кертергә теле. Ләкин ул вакытта гаилә Отар бистәсендә яши, һәм сәнгать мәктәбенең иң якын дигәне дә шактый ерак урнашкан була. Шуңа күрә җиденче сыйныфта – кыз үсеп җиткәч һәм үзе генә йөри ала башлагач кына, сәнгать мәктәбенә керергә туры килә.

– Дәресләр бик ошый иде. Яратып укыгач, уку да авыр бирелмәде. Нәкъ менә сәнгать мәктәбендә мин үз тормышымны бары тик иҗат белән генә бәйләячәгемне аңладым.

Наилә мәктәптән соң Казан дәүләт мәдәният институтына укырга керергә теле. Әмма баллары җитми, һәм Наилә халык сәнгать кәсепләре техникумы студенты була.

Фотолар Наилә Әхмәдуллинаның шәхси архивыннан.

– Андагы атмосфера кабатланмас, – дип искә ала ул үзенең тормышының иң матур елларын. – Иҗат илһамы хөкем сөргән зур остаханә. Бездә парлар, лекцияләр, коллоквиумнар юк иде. Көн саен без яраткан эшебез белән шөгыльләнергә йөрдек. Кулдан тукымага рәсем ясый, челтәр үрә, картина ясый идек. Монда укырга кергәнемә бер дә үкенмәдем. Биредә минем үз-үземә карата ышанычым артты һәм, әлбәттә, профессионал буларак үстем.

Бер елдан соң Наилә теләгән югары уку йортына халык сәнгать мәдәнияте инновацияләре һәм традицияләре факультетына укырга керә ала. Монда кыз чигәргә, тукырга, савыт-саба ясарга өйрәнә. Шул ук вакытта эшләргә дә өлгерә – Наилә деканатка лаборант булып урнаша.

– Дизайнер һөнәрен үзләштерү арзан түгел. Һәр дисциплина өчен үз эш кораллары һәм материаллары кирәк. Барысы да бик кыйммәт. Җитмәсә эни дә декрет ялына чыкты. Мөстәкыйль булырга – үз-үземне тәэмин итәргә өйрәнергә туры килде.

Кыз һөнәрен дөрес сайлауны раслый – вузны кызыл дипломга тәмамлый, үз эшең тормышка ашыру өчен грант ота.

ХЫЯЛ ҺӘМ ПЛАННАР

Наилә дипломын узган җәйдә алган. Хәзер 112 нче мәктәптә укытучы булып эшли, технология укыта. Аның кабинетында буяу һәм җилем катыш агач исе килеп тора.

– Мин укытучыга караганда күбрәк рәссамдыр. Балалар белән яхшы аралашабыз, үзем белгәннәрне аларга өйрәтергә, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләргә тырышам.

Наилә сүзләренчә, аны Казан мәдәният институты укытучысы Расыйх Фарук улы Сәлахов үз эшен ачарга рухландырган. Нәкъ менә ул кайчандыр бишенче курс студентларына «Шамаил» декоратив панносын ясарга кушкан була. Эш яхшы килеп чыга. Беренче паннодан соң – икенчесе, ә аннан соң өченчесе эшләнә. Һәм хоббины керем чыганагына әйләндерү яхшы булыр иде, дигән фикер үзеннән-үзе пәйда була.

– Бүген кешеләргә гади, уникаль һәм шул ук вакытта арзан нәрсә кирәк. Минемчә, без теләсә нинди, иң таләпчән зәвыкны да канәгатьләндерәчәкбез. Иң мөһиме – шәһәр һәм республикага безнең барлыгыбызны белдерү, без хезмәттәшлеккә һәрвакыт әзер. Шуңа күрә социаль челтәрләрдә актив теркәләбез, эшләребезне күрсәтерлек төркемнәр оештырабыз. Киләчәктә без картиналар гына түгел, ә җамалт техникасында җиһаз һәм бизәнү әйберләре дә ясаячакбыз, – ди Наилә.

Якын киләчәктә кыз үз сайтын булдырырга һәм юридик мәсьәләләрне хәл итәргә планлаштыра: компанияне теркәргә, бина табарга һәм арендага алырга, чыгым материаллары белән тәэмин итүче белән килешү төзергә.

Әлегә Наилә өендә эшли. Ул туй чакырулары, киемгә рәсем ясый, картиналар иҗат итә. Кыз үз хезмәтләрен арзанга тәкъдим итә. Мәсәлән, әйбергә рәсемгә төшерү, чакыру кәгазе дизайны кебек үк, 1-2 мең сум тора, ә 50*70 картинасы сатып алучыга биш мең сумга төшәчәк.

– Мин оялчанрак кеше, – ди кыз. – Клиентларымны югалтырга теләмим һәм үземне җитәрлек дәрәҗәдәге профессионал дип санамыйм. Башта исем өчен эшләргә кирәк, аннары ул сезнең өчен эшләячәк, дип уйлыйм.

Наиләгә илһам уңышларга ирешергә ярдәм итә. Ул аны бөтен җирдә – табигатьтә, китапларда, якын кешеләрендә таба. Аның уңышка ирешү өчен бөтен нәрсәсе дә бар, ләкин ул читеге булмаган читекчегә охшаган.

– Мин гади генә фатирда яшим – стандарт җиһазлар, минималь бизәкләр. Өемдә үзем ясаган бер генә картина эленеп тора. Киндергә майлы буяу белән ясалды. Әле ул пейзаж да обойдагы тишекләр аркасында гына пәйда булды. Табигатькә чыгып, урманны, зәңгәр күкне фотога төшердем. Аннан инде рәсем барлыкка килде. Ләкин җитдирәк итеп әйткәндә, үзем өчен вакыт бөтенләй калмый. Эшләремнең барысы да диярлек сатуга яки туганнарга бүләккә китә.

МИЛЛИОНЕР НАИЛӘ ӘХМӘДУЛЛИНА ХЫЯЛЛАРЫ:

– БҮГЕН КЕШЕЛӘРГӘ ГАДИ, УНИКАЛЬ ҺӘМ ШУЛ УК ВАКЫТТА АРЗАН НӘРСӘ КИРӘК. МИНЕМЧӘ, БЕЗ ТЕЛӘСӘ НИНДИ, ИҢ ТАЛӘПЧӘН ЗӘВЫКНЫ ДА КАНӘГАТЬЛӘНДЕРӘЧӘКБЕЗ. ШУҢА КҮРӘ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ АКТИВ ТЕРКӘЛӘБЕЗ, ЭШЛӘРЕБЕЗНЕ КҮРСӘТЕРЛЕК ТӨРКЕМНӘР ОЕШТЫРАБЫЗ. **КИЛӘЧӘКТӘ БЕЗ КАРТИНАЛАР ГЫНА ТҮГЕЛ, Ә ҖАМАЛТ ТЕХНИКАСЫНДА ҖИҺАЗ ҺӘМ БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕ ДӘ ЯСАЯЧАКБЫЗ.**

ГАИЛӘМ

Наилә ишле гаиләдә туып үсә, аның биш бертуганы бар. Ул – иң өлкәне.

– Элегрәк ялгыз үскәннәргә бераз көнләшеп карый идем. Тып-тыныч, сине беркем борчымый, комачауламый. Ә хәзер мин ялгыз тормышны күз алдына да китерә алмыйм. Үзеңне яратканнарын тою, кирәкле булу – бик рәхәт. Бер генә яшькә кечерәк энем белән фатир арендалыйбыз. Ләкин эти-әниемнән һәм бәләкәчләрдән башка бер атна да түзә алмыйм.

Наиләнең яраткан егете бар. Киләчәктә ныклы гаилә корырга, ким дигәндә, ике бала алып кайтырга уйлыйлар – кәләш гаиләсендәге кебек күңелле һәм дус яшәр өчен.



«МӘСКӘҮДӘГЕ БЕР ТАТАРНЫҢ ДА МИҢА РУСЧА ЭНДӘШКӘНЕ ЮК!»

Руфия Фазылова

Ул язучы. Фәлсәфәче. Сәясәтче. Оратор. Чын ир-ат. Ул... Килешерсез, мондый бәяләмәне күп кешегә биреп булмый, ә менә Ринат Мөхәммәдиевкә мөмкин. Дөньяның туксанга якын илендә булган, әсәрләре егерме биш телгә тәрҗемә ителгән язучының сөйләр сүзе, фикерләре бер әңгәмәгә генә сыеп бетмәс, әлбәттә. Шулай да, иң-иңнәрен чүпләп, укучыларыбыз игътибарына җиткерәбез.

– Ринат абый, балачакка кайтырга мөмкинлек булса, кайсы чорны сайлар идегез?

– Гаиләдә җиде бала үстек: алты малай, төпчегебез кыз. Иң беренче шуны әйтим: бүгенге көндә барыбыз да исән-сау, Аллаһка шөкер.

Сезнең сорауга килгәндә, гомеремнең бер елын да кисеп атасым килми. Һәм аерып та куясым килми. Иң бәхетле чор: апрельдән башлап сентябрь азагына кадәр яланаяк йөргән вакытлардыр. Өске якка кием дә кимичә, кап-кара булып йөргән вакытлар. Эшләп тә туймадык, уйнап та, ашап та... Шундый бәхетле чак булган.

Әйе, тормышлар җиңел булмады. Әти җиде елга якын сугышта йөреп, яраланып кайткан башы белән рәхәт көннән шахтага эшкә чыгып китмәгәндер. Балаларны аякка бастырыйм дип тырышкан инде ул. Әти белән әни барыбызга да югары белем бирде. Әни шулай ук сугыш вакытында авылда җаваплы эштә эшләгән кеше. Барлыгы тугыз бала тапкан, ике кыз туганыбыз кечкенә чагында ук вафат булган. Мәрхүм әнкәй, җиде бала үстереп, бер көн декрет ялында булмаган.

– Сез узган юл бер кеше гомеренә генә сыярлык түгел кебек. Шулай да сорыйм әле: гади авыл баласы Мәскәүне яуларлык дәрәҗәгә ничек иреште?

– Мәскәүне яуладым дип әйтә алмыйм. Шунысы бар: анда киткәнемә бер дә үкенмим, чөнки

Фото: Лилиана Вәлитова

ирекле язучы була алдым, бик күп сәяхәт кылдым.

Мәскәү миңа зур мөмкинлекләр ачты: сәясәтчеләр, язучылар, мәдәният әһелләре булсынмы - барысы белән дә бик җиңел аралаштым. Һәм алар мине хөрмәт итте. РФ халык депутаты, комитет рәисе, Россия Югары Советы Президиумы әгъзасы булып эшләгән вакытларда бик күп тәҗрибә тупладым. Россия Язучылар берлеге рәисе Сергей Михалковның беренче урынбасары булып җиде-сигез ел эшләдем. Шул еллар эчендә түшләренә герой билгесе таккан бик күп зур язучылар белән аралашырга туры килде. Алар кебек дуслыкны, яхшылыкны аңлаган, кадерле белгән шәхесләрне Казанда сирәк очраттым. Ул вакытларда монда астан сүз сөйләүчеләр, ыгы-зыгы тудыручылар байтак иде... Валентин Сорокин, Андрей Вознесенский, Роберт Рождественский, Евгений Евтушенко, Борис Монжаевлар белән күп сәяхәтләрдә бергә булырга туры килде. Алар чын кешеләр буларак истә калды. Юрий Васильевич Бондарев минем ахирәт дустым булды. Чын мәгънәсендә татарларга хөрмәт белән карый иде ул, чөнки татарлар арасында үскән егет. Татарчаны да аңлый, аерым сүзләр дә белә иде. Гомумән, намус белән эшләсәң, вак-төяк ыгы-зыгыларда катнашмасаң, Мәскәү ул сәламәт шәһәр. Интеллигенциясе сәламәт аның. Әлбәттә, аларның үз матавыклары бар, ләкин ул ваклыкларга кысылу минем эш түгел иде. Россиянең нинди ил икәнен Мәскәүгә килгәч кенә аңладым. Без Татарстанда үзебезнең хасталыкны, үз проблемаларыбызның барысын да Мәскәүгә сылтап яшәргә күнеккән. Тел бетүгә, мәгарифебез шушы хәлгә төшүгә дә алар гаепле, имеш. Ә чынлыкта барысына да үзебез гаепле. Бүген дә Россия минем җитәкчелектә әзерләнгән һәм кабул ителгән «РФ дәүләт теле турында», «РФ мәдәнияте турында» законнар буенча яши. Әлбәттә, аларга кайбер төзәтмәләр кертелде. Боларның берсендә дә милләтләрне, республикаларны кыерсыту, кимсетү турында, аларның телләрен тыю турында язылмаган. Ә инде бу тирәдә нindидер тавыш чыга икән, мәскәүләр белән сөйләшә белергә генә кирәк...

– Бүгенге татар әдәбиятына нинди бәяләмә бирәсез: тел ярлылану проблемасын сизәсезме?

– Татар әдәбиятында тел ярлыланды дип әйтә алмыйм, күп еллар Мәскәүдә яшәгәч, үземнең дә телем ярлылана башламадымы икән, дип уйлыйм. Телдән бигрәк масштаб кечерәйде. Әдәбиятның үз дөньясы барлыкка килде кебек: аерым темаларга язу гына модага кереп китте. Халыкны әйдәп барырлык фикерләр күренми.

Бездә берәр әсәр язып чыксаң, кимчелек эзли башлыйлар. Фикер ягыннан һаман бер эздән барабыз, аннан чыгарга ярамый кебек кабул ителә.

Без күнеккән интернациональ сүзләрдән котылабыз дип, нindидер яңа сүзләр уйлап табу да күзәтелә. Мин аны да бик аңлап бетермим.

– Авыллар бетүгә борчыласызмы?

– Бик борчылам. Ни кызганыч, без үскәндәге татар авыллары хәзер юк инде. Элек татар авылы ул бер әхлак, тел, иман университеты иде. Ул үз вакытында камил бер җәмгыять иде. Татар авылында шагыйрь булмаган, шигырь укымаган, аңламаган кеше юк иде.

– Язучының абруе турында сөйләшсәк... Бүген аңа элеккеге кебек кадер-хөрмәт бармы?

– Элек татар халкы әдәби әсәрләрне егылып укый иде. Мисал өчен, минем «Кенәри – читлек кошы» романым 50 000 тираж белән басылып чыкты һәм бер ай эчендә сатылып бетте. Аннан аны Татарстан китап нәшрияты тагын 20 000 тираж белән чыгарды. 100 000 тираж белән чыккан китаплар бар иде. Ә бүген 1000 тиражны да әйбәт дип сөйләшәбез.

Элек халык тулаем татар булып яши иде. Яше-карты бишектән китап белән тәрбияләнде. Язучыны йөзеннән таныйлар иде. ТР Язучылар берлеге җитәкчесе булганда мине танымаган татар юк иде шикелле. Хәзер һичкем белми, әдәбият белән яшәүчеләр бик аз калды.

– Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?

– Халыкның гайрәтен кайтара торган әсәрләр күбәйде.

Төркиягә баргач, бервакыт миннән: «Сездә күпме язучы бар?» – дип сорадылар. Өч йөз-өч йөз илле, дип әйттем. Алар ихластан гаҗәпләнеп: «Ул кадәр язар булырмы? Язар ике кул бармагыннан артык була алмас», – диделәр. Бүгенге көндә дә дүрт йөзгә якын язучыбыз бар дип йөрибез. Аларны бит иләктән уздырырга кирәк. Дөресен әйткәндә, таләп кимеде, ул юк. Бу язучыга гына түгел, җыр сәнгатенә, театр репертуарына да кагыла. Җәй башында бер спектакльдән кайткач, ике төн йоклый алмадым. Анда үлгән кешеләр җыелып митинг корды. «Коточкыч әйбер бит! Татар театры шушы көнгә калдымы?» – дип ихластан аптырап утырдым. Кайткач шул турыда мәкалә яза башлаган идем, бер танышым, тавыш чыгарма, тагын өстеңә ташланырлар, дип киңәш бирде. Мин генә төзәтә

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ – Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Төркиянең халыкара әдәби бүләге иясе, Азия-Африка илләренең халыкара «Лотос», М.А. Шолохов исемендәге халыкара, Андрей Платонов исемендәге әдәби премияләр лауреаты.

Язучылар йорты бакчасында. Сулдан уңга: Илдар Юзеев, Аяз Гыйлаҗев, Ринат Мөхәммәдиев, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев. 1997 ел.

Төркиянең Измир шәһәрендә. 2018 елның декабре.

алмыйм моны. Ә башкалар, күрәсең, шуңа риза. Шул театрга, шул әдәбиятка хезмәт итеп, зур шәхес буласылары килә. Халык язучылары булып китәләр, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары булалар. Тукай премиясенә тугызар, унар мәртәбә дәгъва кылалар. Элек андый хәл юк иде. Әйткәнемчә, элек әдәбиятка, сәнгатькә таләп зур иде.

– Сез рус язучылары белән нык аралашкан кеше. Алар татар язучыларыннан аерыламы? Кайсы ягы белән?

– Әле дә аралашып яшибез. Ваклану дигән әйбер рус әдәбиятында да күзәтелә. Ләкин без, Мәскәүдән читтәрәк торган укучылар, рус әдәбиятының чын асыл затларын гына күрәбез. Һәрхәлдә, алар дәүләтле халык, шуның өчен алар үзләрен башкача хис итә, башкача фикер йөртә.

Язучылар йорты бакчасына аксакалларыбыз Әмирхан Еники һәм Гомәр Бәширов әле генә имәннәр утырткан көн истәлеге. 1994 ел, сентябрь ае.

– Сез туксанга якын илдә булган кеше. Иң истә калган сәяхәтегез кайсы булды дип әйтә аласыз? Бәлки, «Кыргый утрауга сәяхәт» повестенда бәян ителгән Яңа Зеландиягә сәяхәттер?

– Әйе, бик күп дөнья гиздем. Шуңа сөенәм: кая барсам да хөрмәт белән каршы алдылар. Шул ук вакытта татар язучысы икәнемне беләләр иде. Мин алар белән һәрвакыт Татарстан вәкиле кебек сөйләштем. Мактану булмасын, минем кебек дөнья гизгән татар язучысы әлегә юк. Моны башкаларны кимсетер өчен әйтмим, бу бәхет тә, җаваплылык та.

Сәяхәтләрне аерып кына әйтә алмыйм, барысы да кызыклы. Беренче тапкыр барганда миңа АКШ та ошады, беренче тапкыр барганда Төркиягә дә гашыйк булдым, Австралия, Сингапур, Голландия дә нык тәэсирләндерде. Алар барысы да яңа дөнья...

Шулай да күңелдә бер истәлек яши: әле «Казан утлары» редакциясендә эшләгәндә мине Кубага баручы сәүдә хезмәткәрләре төркеменә җитәкче итеп билгеләделәр. Ул вакытта гади совет гражданнарына унике доллар, җитәкчегә унҗиде доллар алыштырып бирделәр. Заманына күрә бу бик зур акча. Эрнест Хемингуэйны бик ярата идем. Кубада әдәбият буенча Нобель премиясе алган бөек язучының эзләре буенча йөреп, зур тәэсирләр алып кайттым.

– Рабит абый Батулла, татар теленең гомере бик кыска, ди. Ә сез ничек уйлыйсыз? Балалар бакчаларында ана телендә сөйләшүче сабыйлар бик аз бит... Оныкларыгыз татарча беләме?

– Өч кызым белән дә татарча гына сөйләшәм, алты оныгым да татарча яхшы белә.

Туксанынчы еллар башында милли проблемалар турында Югары Советта, Мәскәү трибунасында ул вакытта ике республика депутатлары гына чәчрәп чыгып сүз әйтә ала иде – татарлар һәм чеченнар. Башка милләтләр яклап сүз әйтергә атлыгып тормады. Татар ул барыбер Россиядәге гади унҗиде-унсигез милләтнең берсе генә түгел. Башка милләтләр дигәндә, Россиядә рус бар, татар бар. Һәм соңгы бер утыз елда яһүдләр барлыкка килде. Шушы өч милләт барысын да хәл итә.

Шундый олы милләт ни өчен югалырга тиеш әле? Мәскәүдә җиденче, сигезенче буын яшәгән татар гаиләләре белән аралашырга туры килде. Оныклары белән рәхәтләнеп туган телләрендә сөйләшәләр. Мисал өчен, Россиянең атказанган артисты Наилә Фатыйхова бар, бабалары кайчандыр Түбән Новгородтан күченеп килгән. Оныгы тугызынчы буын була. Һәм алар үзара саф татарча сөйләшә. Мәскәүдәге бер татарның миңа русча эндәшкәне юк, бары Казаннан килгән татарлар гына эндәшә. Без еш кына: мишәр, себер татары дип бүләргә яратабыз. Казанда яшәгәндә үзем дә нәкъ шулай бүлә идем. Элегрәк читтән килгән бер татарны да Казан үз итмәде. Имеш,

без генә чын татар. Ә хәзер менә шул читтәгеләр татарлыкны ныграк саклый.

АКШта җиде-сигез тапкыр булдым. Анда татарлар җәмгыятенә баргач исем китте: рәхәтләнеп ана телләрендә сөйләшәләр. Балалары да татарча яхшы белә. Ә ни өчен Татарстанда тел проблемасы барлыкка килде соң? Гаеп үзебездә! Без шулкадәр руслашырга яратабыз. Безнең хәзер илле процент кызларыбыз башка милләткә чыга. Һәм ул балаларның барысы да шул милләтләрнең телен өйрәнә. Исемнәре дә татарча булмый. Егетләребез рус кызына өйләнсә нәрсә эшли? Йөз процент руслаша! Ә менә казах, төрек, үзбәк егет-кызлары гаилә корса, туган телләренә хыянәт итми! Югыйсә, без бер генә дә алардан ким-хур халык түгел.

– Туган ягыгыз – Мамадыш районы Кече Кирмәнгә еш кайтасызмы? Анда туган нигезегездә кеше бармы?

– Бу минем өчен авыр сорау. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, Мамадыш районының Кама урман хуҗалыгына күченеп киттек. Әти шулай теләде, чөнки печән, утын әзерләү проблемасы бик зур иде. Авылдагы хәерчелеккә түзә алмыйча эшләде ул аны. Һәм бүген безнең төп нигез Кече Кирмәндә түгел, ә Кама урман хуҗалыгында. Әти-әнине шунда җирләдек. Ә әби-бабайларның каберләре барысы да Кече Кирмәндә. Һәм йөрәгем дә шунда: туган авыл бер генә була. Аны бүгенгәчә сагынып яшим. Ел саен кайтырга тырышам. Кече Кирмәндә әби-бабайларның каберлекләрен төзекләндердем.

– Ринат абый, гаиләгез турында да сөйләшсәк иде: ике тапкыр өйләнгәнсез. Өч кызыгыз белән дә мөнәсәбәтләрегез әйбәт дип беләм. Узган гомергә күз салып, барысын да дөрес эшләдемме икән, дип уйлаган чаклар булмыймы?

– Кеше аерылам дип өйләнми бит, ләкин тормышта аерылышу дигән әйбер бар. Кызганыч, ул еш очрый. Чынлап та, илле яшемә җиткәндә икенче хатыным белән яңа тормыш башларга туры килде. Беренче никахтан – ике кызым, икенчесеннән бер кызым туды. Бу хәлләрдә иң сөендергәне – кызларым белән бик яхшы мөнәсәбәтне саклый алдым. Бүген олы кызым белән күршедә генә яшибез дияргә мөмкин. Гел күрешәбез. Төпчек кызым егерме алты яшендә, Мәскәүдә яши. Кызларымның барысы да бик яхшы укыды, бер дигән һөнәрләр үзләштерделәр. Бу яктан күңелем тыныч.

– Сезнең өчен мәхәббәт нәрсә ул?

– Кешене кеше итеп яшәтә торган, дөньяны алга таба әйдәп бара торган изге, игелекле, серле бер илаһи көч. Әйе, бүген мәхәббәт дигән сүзнең бәясе кимеп бара, ләкин шуны әйтәм – мәхәббәт ул иминлеккә илтә.

Булган мәхәббәт югалырга тиеш түгел дип саныйм. Ләкин кайвакыт кеше: «Бу мәхәббәт», – дип алданырга мөмкин. Менә аны саклап булмый.

– Сәламәтлегегезне кайгыртасызмы, Ринат абый? Тиздән сезгә җитмеш биш тула дип түгел, сезгә алтмыш яшьне дә биреп булмый...

– Гомеремдә сырхауханәләргә йөрергә яратмадым. Һәм дару-фәлән дә кулланмаска тырышам. Мәскәүдә, Кремль хастаханәсендә егерме биш ел дәвамында бер тапкыр да күренмәгәч, мине исемлектән сызып ташлаганнар. Белмим, дөрес фикерме икән инде: медицина кулына кеше бер барып эләксә, аннан котылу юк дип саныйм. Бер дару артыннан икенчесе, өченчесе китә... Әти-әнигә рәхмәт, нык нәсел булган. Икенчедән, Аллаһы Тәгаләмә мең рәхмәт.

Әле дә оныкларым белән футбол уйныйм. Махсус гимнастикалар ясаганым юк, әмма гомерем буе спорт белән шөгыльләндем. Казан дәүләт университетында укыганда йөгерү, волейбол, баскетбол буенча да җыелма командада идем. Бокс та уйнадым. Яшьрәк чакта Сабан туйларында көрәштә баш батыр булып калдым. Аннары, кечкенәдән эш белән ныгып үскән балалар да бит без.

– Бүген нинләр белән шөгыльләнәсез, нинди максатлар белән яшисез, Ринат абый?

– Бүген мин Мәскәү белән Казан арасында яшим. Монда зур йортым бар, шунда кайтып иҗат белән шөгыльләнәм. Мәскәүдә исә «Татар дөньясы» газетасын чыгарам. Тиражы унбиш мең. Россиянең бөтен төбәкләренә тарала. Газета сыйфатлы кәгазьдә бастырыла. Рус телендә чыга. Тик исеменнән үк күренгәнчә, ул татар дөньясына багышлана. Газетаның интернет вариантын Америка, Австралия, Япониядә яшәүче милләттәшләребез дә укый.

Шулай ук Россия Язучылар берлекләре белән дә актив элемтәдә торам. Төркиядә дә эшем бар: елга бер-ике тапкыр барып студентларга лекция укыйм. Төрекчәне үзлегемнән өйрәндем. Төрек телендә егермеләп китабым дөнья күрде.

Кеше хыял, максатлар белән яшәргә тиеш, шунсыз мөмкин түгел. Яңа роман язам. Һәм тизрәк дөньяда барган афәтнең төгәлләнүен көтәм. Бик зур фаҗига бу, йөрәк кан-яшь белән елый...

Мәскәүдә Г. Тукай һәйкәле ачылган көн. Сулдан уңга: рәссам Ильяс Айдаров, язучы Рауль Мирхәйдәров, академик, кардиохирург Ренат Акчурин, Ринат Мөхәммәдиев. Арткы планда - академик Роберт Нигъмәтуллин.

ЧАБАГАЧ: ХӘТЕР САНДЫГЫНДАГЫ ЭШ КОРАЛЫ

Руфия Фазылова

Елның иң тыгыз вакыты кайчан? Әлбәттә, көз: өлгергән уңышны җыеп алырга, урнаштырырга кирәк. Авыл кешесе өчен бу чор иң җаваплы вакыт булган. Әйе, бүген тормыш бик күпкә җиңелләште. Хәзер кырларда урып-җыю барганын белмибез дә: заманча комбайннар санаулы көн эчендә эшне төгәлли. Ә бит безнең әби-бабаларыбыз барысын да кул көче белән башкарган.

Бүген әнә шул шөгыльләрнең берсе – чабагач белән иген сугу турында сөйләшәбез.

«БЕЗНЕҢ ЧОРГА ТУРЫ КИЛМӘДЕ»

Чабагач ярдәмендә башак сугар өчен Апас районының Каратун бистәсенә юнәлдек. Әллә анда бүгенгәчә шулай чабагач белән эшлиләрме дигән сорау туарга мөмкин. Юк, әлбәттә. Биредә «Өммегөлсем» исемле фольклор ансамбле бар. Менә шунда йөрүче апалар бу шөгыльнең бөтен нечкәлекләрен белә булып чыкты. Без алар ярдәмендә басуга барып иген суктык. Аннан исә, ашъяулык җәеп, йомырка ашадык, сөт эчтек. Соңыннан җыр суздык. Кыскасы, чын мәгънәсендә шул елларга кайтып килдек.

Иң беренче шуны әйтим: кайчандыр чабагач белән эшләгән апаа, әбиләрне табып булмады. Ни өчен дигәндә, әлеге эш коралы күп җирләрдә колхозлашу чоры башлангач кулланылыштан төшеп калган. (Аерым хуҗалык басулары берләшкәч, игенчелек эшенә дә күп кенә үзгәрешләр керә, авылларга заманы өчен яхшы саналган техника кайта башлый).

Каратунда яшәүче Гөлбану апа Фәезова да балачагында да, үсмер елларында да чабагач белән эшләмәгән. Аның каравы, туксаннан узган апасы сөйләве буенча әлеге эш коралы турында белә икән.

– Әниләргә ияреп, басуга җиде яшьтә бара идек, – диде Гөлбану апа. – Алар нәрсә эшләсә, без шуны кабатладык. Тик менә чабагач безнең чорга туры килмәде. Ә менә безнең әти-әниләр башта җирне сука белән эшкәртеп, аннан кул белән чәчеп, урып-сугып, ашлыкны он итеп тартып, ипи пешереп ашаганнар. Һәм боларның берсен дә техника башкармаган. Гадәттә, уракка таң белән барганнар – эссе сукмасын өчен дип. Июль, август айлары бик эссе була бит. Төш вакытында өйләренә кайтып килгәннәр. Азрак сулу алып, тамак ялгап та алганнар. Уракчылар игеннәрне урып, башакларны көлтәләргә салып, аннан чүмәләгә өеп киптергәннәр. Аннан исә кулга чабагач алганнар. Менә шуның белән шап-шоп итеп игенне башакларыннан төшергәннәр.

Чабагач дигәне кызык кына эш коралы булып чыкты. Таякка (көрәк сабы дип күз алдына китерергә мөмкин) тагын бер юанрак кыска таяк беркетелгән. Анысы бәрмә өлеш дип атала. Шуның белән башакка сугасың икән.

– Чабагач карап торырга гади генә эш коралы кебек, – дип дәвам итте Гөлбану апа. – Ләкин аның хикмәте бар – әгәр сабына беркетелгән бәрмә өлеш дөрес ясалмаган булса, ул ашлыкны вата. Ә киңрәк агачтан ясасаң, авырлык тигез төшә, нәтиҗәдә иген бөртекләре имгәнми һәм башактан арыш, бодай бөртекләре дә күп коела.

КҮМӘК КӨЧ ТАУ КҮЧЕРӘ...

Берничә ел элек, Яшел Үзән районына баргач, йөзьяшәр бер әби белән танышкан идем. Менә алар чабагач белән эшләгән буын булган. «Безнең бәрәңге бакчасы уртасында бабайлардан калган ашлык суга торган урын бар иде. Басудагы ашлыкларны көзен көлтәләп алып кайтып, шунда кибәнгә өя идек. Кышын ашлык сугасы урынны чиләк-көянтә белән су ташып туңдырып, туган-тумача, күрше-тирә берләшеп, өмә ясап, чабагач белән иген суга идек. Ул урынны сугыштан соң сукалап, бәрәңге бакчасы иттек», – дип сөйләгән иде. Ягъни бу эшне күмәкләп башкарганнар. Аннан исә сугылган ашлыкны тегермән ташы ярдәмендә он итеп тарттырганнар. (Бу турыда журналның «Әбидә кунакта» проекты кысаларында сөйләгән идек).

Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, халык җиңел сулап куя. Җиңү шатлыгы белән бергә ил азмы-күпме хәл ала. Озакламый аның нәтиҗәсен авыл кешеләре дә күрә башлый – колхозларга заманына күрә яхшы техника кайта. Гөлбану апа Фәезова әнә шул чакларны яхшы хәтерли.

– Мин үзем Сарман районында туып-үстем, – диде әбекәй. – Каратунга килен булып төштем. Монда килгәч, басуга иген урырга чыкмадык. Ә менә чөгендер утадык, кул белән алдык. Безнең яклардан аермалы буларак, Апас районында гектар-гектар чөгендер бүлеп бирәләр иде. Кара көзгә кадәр кырда буласың. Ә Сарман ягындагы су те-

Язманың видеоварианты да бар.

гермәннәрен, кул белән әйләндерә торган ашлык чистарту машиналарын хәтерлим. Без алар белән эшләмәдек, кечкенә булганбыз, шулай да күз алдында тора. Вакыт белән бергә игенчелек кораллары да үзгәрә. Урган иген көлтәләрен басуда аерым урыннарга кибән итеп өеп, шунда суга башлыйлар. Катлаулы сугу машинасы дигән техника чыга. Ул машиналарны тәгәрмәчле тракторлар эшләткән. Әлеге машиналарны, чиратлап колхозларга биреп, көне-төне туктатмаганнар. Узган гасырның алтмышынчы елларында авылларга тагылмалы ашлык суктыру комбайннары кайта: «Коммунар», «Сталинец», «РСМ-8». «Коммунар» комбайнының ашлык җыя торган бункеры булмый, аерым кешеләр, ашлыкны капчыкка тутырып, басуга ташлап барганнар. Аннан үзйөрешле, бензин белән эшли торган «С-4» комбайны чыга...

Иң сөенечлесе шул: бу техника гел камиллә шә барып, халыкны кул көче белән эшләүдән азат иткән. Бүгенге компьютерлаштырылган комбайн, тракторлар белән чагыштырганда, әлбәттә, алар бик күпкә уңайсыз булган. Тик... гомер буе кул көче белән җир сукалаган, иген иккән авыл кешесе өчен ул гаҗәеп дәрәҗәдә җиңеллек саналган.

...Каратунда ике меңнән артык кеше яши, Апас районының иң зур бистәсе ул. Тимер юл станциясе буларак 1942 елда оешкан Каратун санаулы еллар эчендә тирә-як авылларның бик күп кешеләрен үзенә җыйган. Биредә мәдәни чаралар да зурлап үткәрелә. Әйткәнемчә, «Өммегөлсем» исемле фольклор ансамбльләре бар. Нинди чара үткәрсәләр дә, тиз генә җыелып алалар икән. Безнең өчен дә шулай күмәкләшеп кырга чыктылар. Җор телле, сөйкемле бу апаларга рәхмәтебезне җиткерәбез. Ансамбльгә иҗат уңышлары, тагын яңа үрләр яуларга насыйп булсын, дип телибез.

Искәндәр Минһаҗев,
Апас районы Борнаш авылы музее җитәкчесе:
– Безнең музейда йөз ел элек ясалган чын чабагач бар. Аңа бик сак карыйбыз. Катырак суксаң, өзелергә мөмкин, чөнки ике таякны хайван тиресе – күн ярдәмендә тоташтырганнар. Белгәнебезчә, ул вакытта хәзерге кебек каешлар булмаган. Әлеге чабагач безнең өчен кадерле экспонат. Балалар бик кызыксынгач, чабагачны үзем ясадым. Аның белән рәхәтләнеп иген сугарга мөмкин. Музейга килгән өлкәннәр дә эшләп карый. Чабагачны шулай ук төрле чараларга дип, райондашлар да алып китә.

игелекле эшләр
мәңгелек
кыйммәтләр
акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Татарстан» фотохәбәрчесе бу җәйдә **кайларда** булды

Шамил Усманов татар тарихында **нинди** эз калдырган

Нинди кызыклы фильмнар карарга була

Бүген Нарат-Елга авылы **ничек** яши

Җәйне **ничек** озатабыз

МИН ҖӘЙНЕ НИЧЕК ҮТКӘРДЕМ

/Фотограф Александр Ефремов иншасы/

Фотоларсыз журнал яфраксыз яз кебек, агачсыз урман һәм чәчәксез болын кебек... һәм «Мин җәйне ничек үткәрдем» темасына иншасыз сентябрь ае кебек!

Шуңа күрә ел саен сентябрь санында без узган җәйгә фотойомгак ясыйбыз – җете, кояшлы һәм уникаль фотосурәтләр ярдәмендә. Мондый фоторәсемнәр «Татарстан» журналы фотохәбәрчесе Александр Ефремовта быел аеруча күп булды.
Бүген ул басмабыз укучыларына 2023 елның җәендә булган иң кызыклы вакыйгаларның фотосурәтләрен тәкъдим итә.

«Татарстан» журналы фотохәбәрчесе Александр Ефремов – «Фотограф-репортер» компетенциясендә һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» милли чемпионатында күп тапкырлар җиңүче:

– Халыкның тулы бер катламнары социаль тормышта катнаша алмый. Алар биргәнгә караганда, күбрәк алалар. Аларның якыннарына бигрәк тә авыр...

«Абилимпикс» мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата бу мөнәсәбәтне кире кагарга булыша. Бу хәрәкәт ярдәмендә мөмкинлекләре чикле кешеләр, сау-сәламәтләргә караганда, яхшырак, уңышлырак һәм җаваплырак профессионалларга әверелә. Безнең арада флористлар, төзүчеләр, җырчылар, балта осталары, массаж ясаучылар бар – алар барысы да яхшы һөнәрмәндләр. Аларга кояш астында урын өчен көрәшү авыррак, һөнәрне үзләштерү катлаулырак, тырышлыкны да күбрәк куярга туры килә – әмма яхшырак нәтиҗәләргә дә ирешәләр.

«Абилимпикс» һөнәр алу гына түгел, ул – башка тормыш, ул – бердәмлек үрнәге. Ул мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә тар дөньядан чыгарга һәм алда караңгылык кына түгеллеген күрергә, аңларга булыша. Алда бик кызыклы, тулыканлы, җәйнең үзе кебек якты тормыш – аның кайбер мизгелләрен мин «Абилимпикс» чемпионатында җиңү ярдәмендә күрә алдым.

ҖИРДӘ ТҮГЕЛСЕҢ КЕБЕК!

ЛЕНА КЫЯЛАРЫ

Якутск шәһәре, Саха Республикасы

– Субайларга утыртылган биналар шаккатырды – мәңгелек туңлык шартларында йортлар шулай төзелә. Искиткеч гүзәл Лена кыялары – син җирдә түгелсеңдер кебек тоела! Ә ак төннәр – һәр фотографның хыялыдыр. Иртә таңнан төнгә кадәр һәм төннән иртәнгә кадәр рәхәтләнеп төшер генә! Якутлар – бик кунакчыл, аралашучан, юмор хисенә бай халык икән! Бер-берсен мәзәкләргә яраталар – карап-тыңлап торуы бик күңелле! Анда инде кулланучылар җәмгыяте түгел, алар кыйммәтле машиналар һәм цивилизациянең башка байлыклары артыннан кумый. Анда башка кыйммәтләр – алар үзләренең матур милли традицияләрен, телләрен, бәйрәмнәрен саклый. Алар бердәм гаилә кебек яши, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер – мәңгелек туңлык патшалыгында башкача була алмый. Хәер, биредә җәе дә ай-һай эссе! Температураның шундый экстремаль үзгәрүчән шартларында яши халык.

ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘРНЕ ТАШЛАМЫЙЛАР!

ЯНГЫННАН СОҢ

Йолдыз авылы. Курган өлкәсе

– Без Йолдыз авылына берничә минут эчендә бөтен авылны диярлек юкка чыгарган коточкыч янгыннан соң бардык.

Миңа татарстанлыларның позициясе бик ошады, алар шунда ук янгыннан зыян күрүчеләргә ярдәм итә башлаган. «Бу башка төбәк!» дип әйтергә дә мөмкиннәр бит югыйсә. Юк, 1000 км ераклыктагы авылга барып, мораль яктан да, матди яктан дә ярдәм итә якташларыбыз. Алар белән горурланам мин. Дөньяда бер-береңә каршы тору бүген бик югары дәрәҗәдә, ә бу ярдәм үрнәге, татар халкының әлеге сыйфатын массакүләм пропагандаларга, таратырга кирәк. Татарлар – тату милләт, үзенекеләрен ташламаячаклар. Санкцияләргә дә, авырлыкларга да каршы торалар. Татар халкына хас әлеге сыйфатлар миңа бик ошый. Менә хәтта туй да үткәрделәр – яшь татар гаиләсенә шулай булыштылар. Бөтен авыл бәйрәм итте.

Конгресста авылны торгызырга карар кылганнар. Төзелеш материалларына бәяләр көн саен арта тора. Янгыннан зыян күрүчеләргә торакны торгызу өчен федераль акчалар гына җитми. Татарстан кешеләргә авылда калырга этәргеч булсын өчен өстәмә түләүләр дә билгеләгән.

БАЙКАЛ КҮЛЕНДӘГЕ НЕРПАЛАР

БҮЛӘК СӘФӘР

Байкал күле. Бурятия

– Нерпаларны күрсәтергә дип, безне утрауга алып киттеләр. Анда барысы да махсус рәвештә нерпаларны борчымаслык итеп эшләнгән: кешеләр утрауның каршы ягыннан киләләр, тездән мүккә батып, Кызыл китапка кертелгән чәчәкләргә соклана-соклана аның аша үтәләр. Сөйләшергә ярамый. Ә нерпаларга махсус «бойницалар» аша гына карарга мөмкин, бу хайваннар сизмәсен өчен шулай эшләнә. Ләкин, минемчә, алар барыбер безнең соклап каравыбызны тоялар, игътибар гына итмиләр.

Нерпалар йөзә торган гаҗәеп сөйкемле этләргә охшаган, йөзләренә карасаң, елмаялар кебек тоела. Бер-берсенә массаж ясагандай, кыска аяклары белән бик кызык итеп сугышып та алалар. Аларны караганнан соң яшәреп-савыгып киткәндәй буласың!



БАЙКЕРЛАРДАН – ИҢ ЮГАРЫ ОСТАЛЫК

«МИН КҮКНЕ САЙЛЫЙМ!» БӘЙРӘМЕ

Казан шәһәре

– Бу юлы бәйрәм «күксез» генә үтте, әмма күңелсез булмады. Башка кызыклы нәрсәләр күп булды. Шуларның берсе – корал: бауларга эленгән пистолетлар белән карты да, яше дә бик кызыксынды.

Икенчесе – ватанпәрварлык. Гимн яңгырый башлау белән, барысы да торып басты, кушылып җырлады.

Өченчесе – байкерлар чыгышы. Байкерлар ролендә – дүрт яшьтән зуррак балалар! Шлемнар, мөгезләр, экипировка – барысы да өлкәннәрнеке кебек! Әле йөри башлаганнарына күпме генә кебек, ә байкларда шундый итеп элдерәләр! Әллә нинди катлаулы фигуралар ясыйлар. Күр, нинди җитди байкер дип уйларга өлгермисең, ә ул озын чәчле кыз булып чыга! Ә сез хәзер балалар туугач телефонда утыра, дисез! Юк, алар байкларга утыра икән бит!

МАШИНАЛАР ХАЛЫКЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

«ЕФӘК ЮЛЫ»

Казан шәһәре

– Һәр малай һәм һәр ир-ат өчен мондый ярышлар бәйрәм кебек! Үзем барам – үзем уйлыйм: төшерәчәкмен, бик матур сурәтләр булачак. Тик әле җанатар да булырга туры килде! Кешеләр бу чарага «КАМАЗ-мастер» командасы өчен җан атарга килгән. Күпчелек «КАМАЗ»ны яклады. Мин дә үзебезнекеләргә кушылдым. Белоруссия егетләре белән таныштым, алар үзләренең «МАЗ» командасы өчен җан атты. Мин дә аларга кушылдым. Чыннан да машиналар халыкларны берләштерә! Фаразлары чынга ашкан җанатарлар арасында бүләкләр дә уйнатылды. Ләкин җанатарлар кемнәрне генә якламасын, Кытай машинасы әйләнеп каплангач, барысы да кытайлар өчен борчылды. Татарстанга нәкъ менә «Ефәк юлы»на дип килгән кешеләр чараның үзенә дә, Казанга да сокландылар. Илең белән горурлану хисләре шундый мизгелләрдә уяна да!

КЫЗЫЛ КОМИССАР ШАМИЛ УСМАНОВ

Илдус Заһидуллин

18 яшендә большевиклар партиясенә кергән, махсус хәрби белеме һәм әзерлеге булмаса да, зур хәрби дәрәҗәгә ирешкән җитәкче, күпчелек әсәрләрен Гражданнар сугышына багышлаган үткен каләмле язучы, яшь Татар республикасы тормышында якты эз калдырган сәясәтче һәм идарәче, совет хакимияте тарафыннан 39 яшендә юк ителгән Шамил Усмановның тууына быел 125 ел була.

Бүген Шамил Усманов безнең өчен – кем ул?

ҮСМЕРЛЕК ЧОРЫ

Шамил Усманов (мулла әтисе кушкан исеме – Габдулла) 1898 елның 26 декабрендә Саратов губернасы Кузнецк өязе Пәндәлгә авылында (хәзерге Пенза өлкәсе Кузнецк районы) мөгаллим Хәйрулла Гыйззәт улы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Гаиләдә 6 ир бала үсә. Әтисе Хәйрулла ерак туганнары фабрикант Акчуриннардан берсенең гозерен үтәп, аның урынына хаҗга бара, юл уңаеннан өч ел Мисыр уку йортларында гарәп телен һәм дин гыйлемен тирәнтен үзләштерә.

Хаҗ сәфәреннән кайткач, Пәндәлгәдәге туку фабрикасы мәктәбендә укыта һәм укытучы Миндән кызы Гайшәгә өйләнә. 6 яше тулгач, улы Габдулла (Шамил) да әтисе мәктәбенә йөри башлый. Мәктәп ябылгач, мөгаллим Әстерханга күченә, үзе – ирләр мәктәбендә, хатыны кызлар мәктәбендә эшли. Бу уку йортлары ябылгач, аны Оренбургка – дөньяви «Хөсәения» мәдрәсәсенә дәшәләр, Хәйрулла хаҗи биредә геометрия, арифметика, тарих һәм кыйраәт (Коръәнне дөрес итеп уку) фәннәреннән дәресләр бирә. Өлкән уллары имтихан биреп, интернат группасына кабул ителәләр, биредә рус телен дә үзләштерәләр.

Хәйрулла, улларында мөстәкыйльлек тәрбияләргә омтылып, җәй көннәрендә гаиләсе белән Урал елгасы буенда палаткалар куеп яшәгәндә, аларны чиратлап төнгә кизүгә куя, револьверыннан атарга өйрәтә һ.б.

Әти кеше, зур ышаныч күрсәтеп, 13 яшьлек Габдуллага энисен Илецк шәһәренә озатып куюны йөкли, тагын бер елдан энесе Габдрахманны Сембер коммерция училищесына имтихан бирдертергә һәм тулай торакка урнаштырырга җибәрә. Күрәбез, Хәйрулла хаҗиның бу улы аралашучан, актив, хәрәкәтчән, зиһенле, тәвәккәл, ут малай булуы белән аерылып торган.

1910 елны Хәйрулланың өлкән уллары, рөшди (урта) мәдрәсәне тәмамлап, сәүдәгәр Хөсәеневләр стипендиясе хисабына 4 сыйныфлы Оренбург һөнәр училищесында укыйлар. Аннары, стипендия алу шартларын үтәп, Габдулла (Шамил) сәүдәгәр Хөсәеневләрнең Тургай өлкәсендәге өяз шәһәре Актүбәдә урнашкан он тегермәнендә слесарь булып эшли, кышкы чорда аларның телефон станциясендә хезмәт куя. Бер елдан абыйсы Гали янына – Акчуриннарның Сембер губернасы Зөябаш (Гурьевка) авылында урнашкан, 2 мең татар эшчесен туплаган туку фабрикасына күчә. Буш вакытында матур әдәбият белән кызыксына. Яраткан язучысы Лев Толстойның «Хаҗи Морат» повестен укудан тәэсирләнеп, әтисе кушкан Габдулла атын (гарәпчәдән «Аллаһ колы» дип тәрҗемә ителә) үзенең рухына һәм күңел халәтенә туры килгән шәхес, әсәрнең баш герое, Кавказ халкы азатлыгы өчен көрәшүче батыр Шамил исеменә алыштыра.

Шул рәвешле, Шамил яхшы дини тәрбия ала, дөньяви мәдрәсә һәм рус һөнәр училищесын тәмамлый, хезмәт юлын квалификацияле эшче булып башлый.

Фотолар автордан алынды

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ КОМИССАРЫ

Егет Зөябашта эшләгәндә Февраль инкыйлабы хакында ишетә. Фабрикадагы революционерлар йогынтысында 1917 елның 10 мартында большевиклар партиясенә керә. Партия аны Сызрань тимер юлына җибәрә: хәрби хезмәткә алынып, июль аенда Сызрань шәһәре запас полкында теркәлә. Актив, җор телле татар егетен иптәшләре Сызрань солдат советына сайлыйлар. Шушы вакыттан Шамилнең актив сәяси эшчәнлеге башлана.

Большевиклар төркеме шәһәрдәге 45 меңлек гарнизон солдатын октябрь аенда советлар ягына чыгарга күндерә. Ноябрь аенда Шамил Казан хәрби округы советлары II съездының гадәттән тыш утырышында катнаша, хәрби округ белән идарә итү өчен оештырылган вакытлы коллегиягә сайлана, хәрби җитәкчегә әверелә. Кайтып, ул 80 гаскәридән Беренче Сызрань партизан пулемет отрядын оештыра. Күрше Кузнецк шәһәрендә эшчеләр советының офицерлар тарафыннан таркатылуын ишеткәч, Шамил, 150 хәрбидән торган отряд белән анда барып, агитация аша 3 көндә 2 мең солдатны коралсызландыруда катнаша. Аннары тимер юл белән хәрәкәт итүче ак чехларны коралсызландырып тора.

Оренбург төбәгендә атаман Дутов җитәкчелегендәге казаклар активлашкач, 1918 елның маенда Шамил Усманов отряды Көнчыгыш фронтка җибәрелә. Биредә Кәриб Хәйруллин оештырган Оренбург мөселман батальонына кушыла, аның комиссары була. Батальон август аенда кызылларга Оренбургтан чигенергә мөмкинлек бирү өчен сугыша, Сакмар күперен шартлатып, поездда Актүбәгә китә. Биредә 20 яшьлек Усманов мөселман батальоны нигезендә 1200 хәрбидән торган III Интернационал исемендәге легион төзи. Легион 1919 елның гыйнварында Дутовның казакларын Оренбургтан куып чыгара.

Революция шартларында шәһәрләрдә эрерәк хәрби берләшмәләр – мөселман полклары – барлыкка килә. Алар белән җитәкчелек итү өчен Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариаты каршында Үзәк мөселман хәрби коллегиясе булдырыла.

Усманов та Оренбургта мөселман полкы оештырырга тырышып карый, ләкин җирле хәрби җитәкчелек бу идеягә аяк чала. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе Мирсәет Солтангалиевнең Уфада икәнен ишетеп, Шамил аның белән очрашуга бара, киңәшләрен тотып, Оренбургта мөселман дивизиясе яки бригадасы оештырырга рөхсәт алу өчен Мәскәүгә юнәлә. Ахыр чиктә, Казанда мөселман бригадасы төзү турында 1919 елның мартында рөхсәт алуга ирешә, комиссары итеп үзе раслана. Яңа хәрби берләшмәнең исеме «Аерым Идел укчы татар бригадасы» итеп тәгаенләнә һәм аны төзү эше нигездә комиссар җилкәсендә була. Тиздән бригада командиры итеп Йосыф Ибраһимов, штаб командиры итеп Искәндәр Тальковский билгеләнә. Бригаданың беренче полкы сугышка май аенда җибәрелә. Бик кыска вакытта төзелгән бригаданың калган полклары август башында сугышка китә.

Һәрчак елмаеп торган дәртле, кыю, ораторлык талантына ия яшь комиссар мобилизацияләнгән русча юньләп белмәгән татар агайларына һәм яшьтәшләренә гаделлек һәм ирекле тормыш хакында ышандырырлык итеп сөйләп, агитация алып бара, киләчәктәге шул бәхетле тормышны корал белән якларга кирәк дип аңлата, солдатларның хәрби әзерлегенә зур игътибар бирә.

Тәртипләре һәм батырлыклары белән башкаларга үрнәк булып торган татар бригадасы данлы юлын командарм Михаил Фрунзе җитәкчелегендә дәвам итә, ә 1919 елның сентябрендә булган бәрелешләрнең берсендә көчле контузия алган Усманов дәваланырга Ташкентка китә, аннан Казанга кайта. Кыска гына вакытта да ул тик тора алмый: хәрбиләрдән мәдәни-агарту хезмәткәрләре әзерләүче кыска сроклы курслар оештыра.

Хәрби революцион совет 1920 елны элекке кызыл комиссарны татар бригадасын оештырган өчен алтын сәгать белән бүләкли.

Усманов 1919 елның 8 октябрендә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы итеп билгеләнә, аның сәяси бүлеген җитәкли. Бу вазифада 1920 елның октябренә кадәр, коллегия таркатылганчы эшли. Казанда Кәрим Тинчурин җитәкчелегендә татар артистлары труппасын оештыра. Бакый Урманчега өстәл календаре

Кызы Айсылу белән. Казан. 1937 ел.

Дивизия комиссары Шамил Усманов. 1925 ел.

ясарга мөмкинлек тудыра. Шунда басылган ТАССР гербы киләчәктә рәсми герб ясау өчен нигез була.

Ул агитацияләүдә вакытлы матбугатны да киң файдаланырга тырыша. Коллегиянең матбагасы булган «Кызыл армия» газетасында күпсанлы мәкаләләр бастыра. Әйтик, 1919 елның 17 ноябрь санында дөнья күргән «Омск безнеке!!!» исемле язмасын мондый образлы җөмлә башлый: «Гайрәтле арыслан кебек һөҗүм итеп, Колчак гаскәрләренең сафларын ерып алга баручы Кызыл гаскәр Себер контрреволюциясенең йөрәге булган Омск шәһәренә керде...» Оештырылачак дип игълан ителгән Татар-Башкорт республикасын булдырырга өндәп, ялкынлы мәкаләләр яза, соңрак Татарстан АССРны яклап язмалар урнаштыра.

Шамил большевикларда гаделлек өчен көрәшүче һәм төзеләчәк социалистик җәмгыятьтә нигездә игенчеләрдән һәм эшчеләрдән торган туган халкын алдынгы итәрлек сәяси көч күрә. Шуңа тәмам ышанып һәм рухланып, милли гаскәрләр төзеп, аларның кызыл комиссарына әверелә. Инкыйлаб һәм сугыш шартларында аеруча мөһим булган кыюлыгы һәм тәвәккәллеге, русча белүе һәм дини белеме егеткә милли кадрларга кытлык заманында бик яшьли совет хәрби җитәкчесе булуга юл ача.

ТЫНЫЧ ТОРМЫШ КОМИССАРЫ

1920 елны Шамил Усманов ТАССР Советларының оештыру съездын әзерләү өчен булдырылган республика революцион комитеты сәркатибе итеп билгеләнә. Съездда кимендә 50% татар делегатлары булырга тиеш дигән фикер уздырганы өчен милләтчелектә гаепләнә һәм Төркестан фронтына җибәрелә. Төркестан хәрби революцион советында һәм Бохара хәрби комиссариатында җаваплы вазифалар башкара.

Кызыл комиссар 1922–1925 елларда Казанда 16 нчы пехота командирлары әзерләү курсының сәяси бүлеге мөдире, аннары берләштерелгән Татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары булып тора. Курсантларның уку һәм көнкүреш шартларын яхшырту өлкәсендә нәтиҗәле эш башкара, зур абруйга ия була.

Дивизия комиссары дәрәҗәсе ала, 1925 елны Мәскәүдә Кызыл армиянең милли хәрби уку йортлары инспекторы булып эшли һәм Михаил Фрунзе исемендәге хәрби академиянең берьеллык курсларын тәмамлый.

1926–1927 елларда Ташкентта Көнчыгышны өйрәнү институты хәрби курсының сәяси бүлеге башлыгы вазифасын башкара.

Хәрби хезмәттән киткәч, Усманов Казанда өч елга якын ТАССР тамаша предприятиеләре идарәсе рәисе һәм радиостанция төзү буенча республика хөкүмәтенең махсус вәкиле булып тора.

Техник әвәслеге булган тыныч тормыш комиссары 1927 елның җәендә республика җитәкчелегенә радиолаштыруны арзан бәягә тормышка ашырып булачагын дәлилләп һәм, Мәскәүнең «Радиопередача» оешмасы белән килешү төзеп, Октябрь инкыйлабының 10 еллыгы көнне – 1927 елның 7 ноябрендә – Шамил Усманов эфирга аваз сала: «Тыңлагыз! Тыңлагыз! Казан сөйли!»

Радио штатында журналист Шамил Усманов, диктор Гадел Кутуй, артистлар Камал Икенче, В. Егорова була. Музыка бүлеген Салих Сәйдәшев җитәкли. Оештырыла торган концертларда Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләйманова, Асия Измайлова, Галия Кайбицкая, Газиз Әлмөхәммәтов һ.б. артистлар башкаруында татар җырлары яңгырый. Усманов, бер яктан, радиотапшыруларның идеологик эчтәлегенә зур игътибар бирсә, икенче яктан, төрле конкурслар оештырып, күбрәк тыңлаучы җәлеп итәргә тырыша.

Алфавит алмаштыру буенча татар зыялылары арасында 1924–1927 елларда барган бәхәстә латин графикасын кертүне яклаучылар арасында иң актив татар җәмәгать эшлеклесе була. СССРда эсперанто белән кызыксыну арткач, ТАССРда ясалма халыкара телне өйрәнү хәрәкәтен Шамил Усманов башлап йөри.

«Гаилә турысында» исемле мәкаләсендә «Хәзерге яшь буын өчен иреклә семья кирәк. Үзен пролетариатка хезмәткә багышлаган егет, баласы булгач, чүпрәк, кибет, жалованье артыннан йөреп ваклана, бәйләнә, әрәм була», дип язган Усманов Газизә Алимбәк кызы белән гаилә кора һәм, озак та үтми, 1922 елда аерылыша. 1924 елда җырчы Асия Измайловага өйләнә һәм 1925 елда, Коканд шәһәренә барып, беренче никахтан туган кызы Айсылуны Мәскәүгә, яңа гаиләсенә алып кайта.

1929 елны кабат Мәскәүгә китү сәбәпләренең берсе хатыны Асия Измайлованың талантыннан көнләшеп һәм нахакка гаепләп эшеннән алдыртулары була. Шулай ук тормышында кайбер башка күңелсез вакыйгалар да шул вакытка туры килә. Измайлова Мәскәү консерваториясенең татар студиясендә укый, Усманов Язучылар берлегендә эшли. Ләкин гаилә тормышы барып чыкмый, алар 1935 елда аерылыша. 1936 елда Шамил кызы Айсылу белән кире Казанга әйләнеп кайта.

РЕАЛИСТИК ӘДӘБИЯТ ТАРАФДАРЫ

Мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеген җитәкләгәндә үк басма һәм әдәби сүзнең тәэсире мөһим идеология коралы икәнен аңлап алып, Шамил Усманов вакытлы матбугатны һәм әдәбиятны сәяси-агарту һәм пропаганда эшенең аерылгысыз өлешенә әверелдерә. Аерым алганда, яңа драмалар язу өчен иҗади шәхесләр һәм аларны сәхнәләштерү өчен татар артистларыннан төркемнәр оештырыла. Үзе дә 1919 елда Кызыл армиядә зур ихтыяҗ булган яңа тормышка өндәүче «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» исемле пьесаларын яза. Сюжетлары автор үзе күргән вакыйгалар-

га нигезләнгән булуы белән көчле әсәрләр меңнәрчә тапкыр сәхнәдә куела. «Беренче адым»да туку фабрикасында 1917 елгы Февраль инкыйлабы алды вакыйгаларын һәм эшчеләр тормышын тасвирлый.

«Бай кызы» (1922) драмасында сугыштан кайткан элекке комиссар Хәлил һәм аның хатыны Зөһрә арасындагы тормышка карашлары туры килмәү, көрәш романтикасы белән мәхәббәт романтикасы каршылыгы сурәтләнә. Нәтиҗәдә хатын ирен ташлый, Хәлил фронтка китеп бара.

Усманов 1925 елда Бөтенсоюз пролетар язучыларының беренче съездында катнаша һәм аның Ассоциациясенә әгъза итеп сайлана, ә 1934 елдан СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

Шамил Усманов 1918–1919 еллардагы вакыйгаларга – Оренбург мөселман батальоны һәм III Интернационал исемендәге легион тарихына мөрәҗәгать итеп, 1923 елдан 1935 елга кадәр күп тапкырлар төзәтеп, үзенең иң күләмле әсәрен – «Кызыл байрак астында» һәм «Легион юлы» дигән ике кисәктән торган «Легион юлы» дилогиясен яза.

«Памирдан радио» (1925) романында кызыл командир Җаббарның, яла ягудан качып, гаделлек тапмыйча, совет иленнән Мароккога китүе, гарәп кабиләләренең юлбашчысы булып колонизаторларга каршы сугышып йөрүе, туган иленә әйләнеп кайткач, хыянәтчеләрне фаш итеп, намуслы исемен кире кайтаруы хыялый сюжетка салып яктыртыла. Кешеләрнең, вак көнләшү аркасында, зур эшләргә юл куймавы иҗатында гел күренеп бара.

Ул Гражданнар сугышының төрле вакыйгаларын яктырткан хикәяләр сериясен иҗат итә: «Ил кызы», «Бирегез тупны кире!», «Идел буйлап», «Көчле мандат», «Өч снаряд белән» һ.б. Туку фабрикасында эшләгән елларын искә төшергән «Фабрика анасы», «Тиң түгелләр», «Эшче кызы Нина» һ.б. хикәяләре эшчеләр тормышын сурәтли.

Иң уңышлы драма әсәре саналган «Кичеккән фәрман» драмасын автор үзе 1933 елны русчага тәрҗемә итеп, Мәскәүгә иң яхшы пьесаларга үткәрелгән конкурска җибәрә һәм меңнән артык әсәр арасында 3 нче урынны ала. Әсәр 1935 елда Мәскәүдә «Страна родная» исеме белән китап итеп бастырыла. Пьесада Зәки Вәлиди җитәкчелегендә милли-буржуаз башкорт хөкүмәтенең совет хакимияте ягына чыгуы сурәтләнә. Үзәк герой Харис Садыйковның (прототибы – Зәки Вәлиди) большевиклар ягына авышуы төрле социаль катлау вәкилләренең үзара мөнәсәбәтләре һәм конфликтлары аша тасвирлана.

Әтисе Хәйрулла хаҗи, васыятендә улына мөрәҗәгать итеп, болай дип язган була: «Иманым камил: син, газиз угылым, хаиннәр казыган базга егылып төшкәнче, юлыңны дәвам итмәктә булачаксың. [...] Көчләп тагылган әҗәлең, гавамда яңгырарлык соңгы чараң нәтиҗәсендә, җәлладларга карата

Шамил Усманов хатыны Газизә белән.

соңгы ләгънәтең булсын! Амин!» Аның сүзләре рас килә.

Усманов, нахакка гаепләнеп, 1937 елның 8 апрелендә кулга алына. 1917 елдан большевик милләтчелектә, Солтангалиев оешмасында катнашуда гаепләнә, 3 декабрьдә ТАССР эчке эшләр халык комиссары бүлмәсендә 39 яшьлек язучының кыйналудан йөрәге туктый. Исеме 1955 елда аклана.

Шамил Усмановның хезмәт юлы – үз халкының бәхетле киләчәге социалистик җәмгыять төзүдә дип ышанган, шуның өчен башта кызыл комиссар булып кулына корал тотып сугышкан, тынычлык урнашкач, ил мәнфәгатьләрен алгы планга куеп, гаскәри, җитәкче һәм язучы сыйфатында тырышып эшләгән актив тормыш позициясенә ия һәм шул җәмгыятьнең корбаны булган шәхес биографиясе ул. Аның хәрәкәтчән, ташып торган энергияле көрәшче холкы һәм шуларга тәңгәл кыю эш-гамәлләре татар халкына, мәдәниятенә хезмәт итә.

Шамил Усмановның данлы исемен җәмәгатьчелеккә кире кайтаруда кызы Айсылу Сагайдак-Усманова зур хезмәт куйды. Әтисе турында замандашлары истәлекләрен туплап һәм язучының шәхси архивын өйрәнеп язган «Глазами памяти» китабы (1982, 1988) һәм «Перебитые крылья» (2014) тарихи романы Шамил Усманов шәхесен эш-гамәлләре һәм уй-омтылышлары үремтәсендә мәңгеләштерә.

ҮТКӘН ЧОРНЫҢ ЯКТЫ БАЛКЫШЫ

Риза Ишморат – киң җәмәгатьчелеккә драматург, гомерен татар театрын үстерүгә багышлаган шәхес буларак билгеле, әмма аның эшчәнлеге моның белән генә чикләнмәгән. Төрле елларда ул үзен режиссёр, тәрҗемәче, публицист, мемуарлар, хәтта җырлар авторы буларак та таныткан. Риза Ишморатның «матур да, күңелле дә, шатлыклы да, хәсрәтле дә, газаплы да» хәятенә, тормышына күз салыйк.

Ихтыяр Кыямов

ТИРӘН ТАМЫРЛАР

Драматург хәзерге Башкортостан Республикасының Яңавыл районы Бәдрәш авылында туган. «Гомер сукмаклары» дип исемләнгән истәлекләр җыентыгында әдип үзенең милләте, туган җире хакында болай яза: «Милләтем татар, телем дә татар теле. Революциягә кадәр, дөресрәге, Татар республикасы игълан ителгәнгә кадәр, башкорт булып исәпләнә идек. Бу рәсми документлар буенча да шулай. Үземне мин бер үк дәрәҗәдә шушы ике милләтнең улы дип исәплим. Татар язучысы булуыма шатланам. Ләкин татарны да, башкортны да бертигез яратам. Татар моңы да, башкорт моңы да минем үз моңым».

Риза Ишморат үзенең нәсел тамырларын ачыклар өчен шактый күп көч куйган, этисе ягыннан 19 буын, әнисе ягыннан исә 16 буын бабаларын эзләп тапкан.

Ризаның этисе Фәхретдин чыгышы белән крестьян гаиләсеннән була. Минһаҗетдин бабасы игенчелек һәм балыкчылык белән көн күргән. Фәхретдин үзе заманасы өчен гаять укымышлы кеше санала, үз тырышлыгы белән мәдрәсәдә укый. Соңрак авыл мулласының тол хатынына өйләнә, күпмедер вакыт авылда имам булып тора, гаиләдә биш бала туа. Татар иҗтимагый дөньясында пәйда булган җәдитчелек хәрәкәтенә кушыла, муллалыкны ташлый. Бөтен игътибарын укытуга, балаларына аң-белем бирүгә багышлый. Аларның өйләрендә китаплар, журналлар күп була. «Баштарак – «Тәрҗеман», соңрак «Вакыт», «Йолдыз», «Сибирия», «Тормыш» газеталары; «Шура», «Мәгълүмат», «Аң», «Икътисад» журналлары килә иде. Балаларга дигән «Ак юл», Шиһаб Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һ.б. әдипләрнең китаплары бар иде өйдә», – дип искә ала Риза Ишморат үзе.

ТЕАТР НУРЫ

Риза Ишморат беренче тапкыр Уфада «Нур» труппасының «Хөкемдә хаталык» исемле спектаклен карый. «Театрның нәрсә икәнен чамалыйм. Пьесалар да укыганым бар. «Нур» исемен йөрткән, халык күңелен яктырту нияте

Фотолар «Ватанны саклаучы» китабыннан алынды

белән оешкан профессиональ театр. Артистларны ишеткәнем дә, күргәнем дә юк. Ә менә Сәхибҗамал Гыйззәтуллина исемен ишеткәнем бар. Ул – атаклы кеше. Аның турында Габдулла Тукайның язган шигырен дә хәтерлим», – дип язган Риза Ишморат. Бөек актрисаның осталыгы яшь Ризаны илһамландыра, театрга карата мәхәббәт уята. Еллар үткәч, дан казангач, драматург Сәхибҗамал Гыйззәтуллинага үз рәхмәтен белдерергә өлгерә.

«ЯҢАЛЫК – УЛ ТЕАТРНЫҢ ТӨП ТАЛӘПЛӘРЕННӘН БЕРСЕ»

XX гасырның 20–30 нчы еллары... Илдә, җәмгыятьтә – революция, түнтәрешләр чоры. Бу гарасат сәнгатьне дә читләтеп үтми. Яшь сәнгать әһелләре, рус шагыйрьләре Мейерхольд һәм Маяковскийга ияреп, заманча – яңа ысулда иҗат итәргә керешә. Революцион эчтәлек революцион форма да таләп итә, шул рәвешле сулфчылар («сул фронт») төркеме оеша. Әлеге төркемгә Гадел Кутуй, Хәсән Туфан, Әсгать Мәҗит, Риза Ишморат кушыла. Өлкән буын әдипләре тарафыннан бу күренеш хупланмаса да, яшьләр үзләренчә иҗат итәргә омтыла. Фатих Әмирхан театрда лекцияләр укыганда студент Ишморат белән әңгәмә кора:

– Риза туган, сез бу футуристлар арасына ничек килеп эләктегез? Хәер, сез бу футуристлар йогынтысыннан тиз котылырсыз, дип уйлыйм.

– Фатих абый, без футуристлар түгел, без сулфчылар.

– Барыбер. Сулфчылар да реализмнан шактый ерак тора. Хәер, киләчәккә аек акыл белән карап яшәгән барлык язучылар һәм театр әһелләре кайчан да булса бер реализм юлына басачаклар.

Фатих Әмирханның фаразы дөрес булып чыга. 1930 нчы еллар башында сулфчылар да, имажинистлар һәм символистлар да бер исем – совет язучылары дип атала башлый. Әсәрләрен бер ысул – социалистик реализм методына таянып язалар...

Әмма шомлы 1937 еллар шаукымы Риза Ишморатны да урап узмый. Театрда барган яман хәлләр – Мөхтәр Мутинны, Гали Ильясов, аның хатыны Гөлсем Камскаяны кулга алулар, соңрак иҗатташы Кәрим Тинчуринны, нахакка гаепләп, 50 яшьлек юбилее үткән төнне үк алып китүләр канатланып иҗат итеп йөргән драматург язмышын да үзгәртеп куя. Җыелыш җыеп, Риза Ишморатны да театрдагы эшеннән азат итәләр, партиядән чыгаралар. Репрессияләр дулкыны бераз чигенгәч кенә аны кабат эшкә алалар. 1941 елда театр коллективы Мәскәүдә узарга тиешле татар сәнгате декадасына әзерләнә. Татарстан делегациясен әзерләү эшенә җаваплыларның берсе Риза Ишморат була.

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ СОЛДАТЫ

Әмма хыялларны чәлпәрәмә китереп, Бөек Ватан сугышы башлана. Ризаның өч бертуганы – Зыя, Һади, Нәҗип тә фронтка китә. Риза Ишморат фронтка 1942 ел башында чакыру ала, Казан янындагы запас полкта хезмәт итә. 1943 ел башында исә Беренче Украина фронтының «Ватан намусы өчен» газетасында эшли башлый. Беренче июльдә инде җаваплы редактор вазыйфасына билгеләнә. Газета биш телдә: рус, украин, татар, казах, үзбәк телләрендә басыла. «Сугыш юллары, авыр көрәш юллары халкыбызга җиңел булмаган кебек, минем өчен дә җиңел булмады. Бер ел танк батальонында рядовой солдат, бераздан сержант, фронтка килгәч, өлкән лейтенант, капитан, майор... Озын һәм авыр сугыш юлы үтеп, Острогожск шәһәреннән Берлинга кадәр барып җиттем. Урам сугышлары барганда яраландым. Берлин урамнарында маҗаралы һәм куркыныч хәлләр бик күп булды». Шундый хәлләрнең берсе турында Риза Ишморатның улы Рөстәм үзенең «Мәхәббәт мизгелләре» дигән китабында сөйли: «Бүлмәләрнең берсенә кергәч, Ризага нәрсәдер селкенеп киткән кебек тоела. Мизгел эчендә автоматын шул якка төби һәм почмакка сыенып утырган чал чәчле картны күреп ала. Кычкырганга карт, кулларын күтәреп, торып баса. Карашлар очраша. Тынлык мизгелләре.

– Утырыгыз, утырыгыз, – ди Риза һәм бүлмәдән чыгып китәргә дип борыла. Шул вакытта карт аңа, кулын сузып, болай ди:

– Герр офицер, алыгыз, – немец карты учына кысып тоткан әйберне Ризага суза. – Ихтимал, бу сезгә хәзер миңа караганда күбрәк кирәк булыр.

Сугыш еллары эчендә немец телен яхшы үзләштергән Риза аны аңлый. Сүзсез генә картның учыннан медальгә яисә тәңкәгә охшаган кечкенә генә әйберне ала да бүлмәдән чыга».

Риза Ишморат (Ризаэтдин Фәхретдин улы Ишморатов)
1903 елның 1 ноябрендә хәзерге Башкортостан Республикасының Яңавыл районы Бәдрәш авылында туа. Алты яшендә мәктәпкә укырга керә. Янбарыс авылы мәдрәсәсе һәм Сараш авылының русча-татарча земство мәктәбендә башлангыч белем ала. «Госмания» мәдрәсәсендә укып чыга. 1921 елда Уфада педагогика курсларын тәмамлый. 1923 елда Казан театр техникумына укырга керә. 1926 елдан Татар дәүләт академия театрында - режиссёр. 1927–1930 елларда Ленинград сәнгать тарихы институты каршындагы Югары театр сәнгате курсларында укый. ТАССР Мәгариф халык комиссариатында сәнгать эшләре буенча инспектор булып эшли. 1931–1940 елларда – ТДАТ режиссёрлар коллегиясе җитәкчесе. Сугыштан соң тулысынча әдәби иҗат эшенә күчә.
40 пьеса иҗат итә, 41 нчесен («Якты йолдызлар») тәмамларга өлгерми. «Гомер сукмаклары», «Дусларым, остазларым» дип аталган истәлек китаплары, «Сайрасын тургайлар» дип аталган документаль повесть та яза. II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет Билгесе» орденнары кавалеры; РСФСР һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе.
1995 елның 29 октябрендә вафат була.

Сулдан уңга: Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри, Риза Ишморат.

ӘТИЕМ ТУРЫНДА

Рафаил Ишморатов, улы:

– Әтинең сугышка киткән һәм кайткан чакларын хәтерлим. Бигрәк тә әтинең 1947 елның җәендә сугыштан кайткан вакытын. Аның кайтуын көтеп, без көн саен диярлек вокзалга бара идек. Ниһаять, ул кайтып җитте. Әти поезддан чыкты, без йөгереп барып кочаклап алдык. Өйгә җәяүләп кайттык. Әйберләреннән алты күн букча бар иде, аларны олаучыда алып кайттылар. Беренче көнне үк әти мине Гадел Кутуй гаиләсе янына алып барды әле. Дустының үлемен авыр кичергән булса кирәк...

Әнием Рәшидә Җиһаншина белән уртак тормышлары барып чыкмады. Алар аерым яшәргә карар кылдылар. Сугыш азагында әти үз гомерен журналист Фатыйма Галиева белән бәйләгән була. Ә 1946 елда уллары Фәрит туган.

Кем белә, бәлки, Бөек Ватан сугышы аермаган булса, ике театр кешесе бик бәхетле тормыш кичерерләр иде, чөнки әни белән бик яратышып кавышалар бит. Энем Рөстәм әни белән яшәргә калды, ә мин әти белән Качалов театры артистлары тулай торагына күчтем... Берникадәр вакыттан соң әти Рәйсә ханымга өйләнде. Сугыштан соң ул режиссерлык эшеннән китте, бер-бер артлы драма әсәрләре яза башлады. Ул чорда театрларга бик еш йөри идек...



СҮЗ БАШЫ

«Советская культура» газетасы редакциясе, ә аннары Татарстан радиоинформация бүлеге миннән «Нәрсә ул бәхет?» дигән темага чыгыш ясавымны сорадылар. Миңа бу турыда үземнең фикеремне укучылар һәм радио тыңлаучылар белән уртаклашырга – бәхет турында сөйләшергә туры килде. Беренче чыгышымнан соң күп хатлар алдым. Соңыннан аларга җаваплар да яздым. Укучыларга тәкъдим ителә торган бу кечкенә китап әнә шулай туды.

Риза Ишморат.



Урамга чыккач, пулемет утына эләгеп, каты яралана. Катлаулы операцияләр кичерә, әмма исән кала. Немец карты биргән тәңкәне исенә төшереп, аны җентекләп карый. Тәңкәнең бер ягына сабыен кочаклаган мадонна сурәтләнгән була. Шул вакытта гына Риза моның икона булуын һәм аны үлем тырнагыннан нәкъ менә шул – немец картының бүләге генә саклап калуын аңлый. Кырык елдан соң шул истәлекле тәңкәне Риза Ишморат үзенең улы Рөстәмгә тапшыра.

Бертуганнар арасында ул сугыштан берүзе генә әйләнеп кайта.

ФАШИЗМГА – ҮЛЕМ

Сугыш чорында драматург өч пьеса иҗат итә: «Дошман лагеренда» (1941), «Ватан кызлары» (1941), «Кайту» (1942). Соңгы әсәр аеруча зур танылу ала. «Кайту» драмасының язылу тарихы да игътибарга лаек. Ул вакытта Риза инде мобилизацияләнгән, Казан янындагы танк батальонында хезмәт итә. Шулвакыт Таҗи Гыйззәт белән Әхмәт Фәйзи үтенече буенча политбүлек җитәкчесе Риза Ишморатовка, хәрби хезмәттән аерылмыйча гына, пьесаны язарга рөхсәт бирә. Ун көн эчендә драматург пьесаны тәмамлый. Риза Ишморат хәрәкәттәге армиягә киткәч, спектакль күчмә колхоз-совхоз театры тарафыннан сәхнәләштерелә, режиссеры Вәлиев-Сульва була. Премьерасы 2 ноябрь көнне Олы Шырдан авылында гөрләп үтә. «Кайту» пьесасы сугыштан соң да берничә мәртәбә төрле җыентыкларда басыла.

Калган ике пьеса басылмый. Дөресрәге, «Ватан кызлары» дип исемләнгән өч күренештәге драма «Үлем фашизмга» (1943) китабында басыла, ләкин соңрак аннан ертып алына. Китапның титул битенә «ПРОВЕРЕНО 1946» мөһере сугылган. Өстәмә буларак шуны да әйтергә кирәк: гәрчә «Әдәбият баскычлары» исемле татар совет әдәбияты елъязмасында 1943 елда басылып чыккан китаплар исемлегенә кертелсә дә, ул әдипнең библиографиясендә теркәлмәгән.

«БӘХЕТ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ»

Киң җәмәгатьчелеккә бигүк мәгълүм булмаган бу китапны Риза Ишморат үзенең иң мөһим әсәре дип атый. Китап 1957 елда басыла. Әлеге әсәрендә әдип укучыга бәхет хакындагы уйларын җиткерә. 1950 нче еллардагы Советлар Союзы гражданины өчен бәхет түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: булганына шөкер итү, көрәш, Советлар Союзы гражданины булу, ирек, кыюлык, хезмәт, мәхәббәт, дуслык. Автор үзенең фикерләрен дәлилләү нияте белән шул чор шагыйрьләренең әсәрләреннән өзекләр дә китерә. Бу китапны укып чыгу – илебезнең 50 нче еллардагы тормышына күз салуга тиң ул.

ГАИЛӘ ХӘЛЕ

Риза Ишморат яшәгән чор ил өчен дә, аның кешеләре өчен дә шактый катлаулы дәвер була. Илдә барган вакыйгалар драматургның шәхси тормышында да чагылмый калмый. Җир төзелеше техникумыннан үзе яраткан театр техникумына укырга күчкән егет иҗат казанында кайный башлый. Такташ, Кутуй, Сәйдәш белән бик тиз танышып, аралашып китә. Барысы да яшь, талантлы, тапкыр, кискен фикерлеләр. Яңа милли сәнгать бөреләнгән чак. Тирә-юньдә яңа тормыш язы чәчәк ата! Талантлы яшьләр, рабфакта укыган туташлар белән очрашып, гаилә корып җибәрә. Дусты Кутуй өйләнә. Бервакыт май аенда, шомырт чәчәк аткан мәлдә Риза Сәгадәт атлы чибәр туташ – укытучы кыз белән таныша. Егет техникумны тәмамлаганнан соң, яшьләр өйләнешә. Аларның бу никахтан кызлары Гөлнар туа.

Ишморатның театр техникумында укыткан чагы. Шул вакытта Казан кызы Рәшидә дә техникумга укырга керә. Гаиләсен бозмаска дип никадәр генә тырышмасын, мәхәббәт барысын да хәл итә. Киләчәктә татар театрының йөзек кашы булачак Рәшидә Җиһаншина белән никахыннан ике уллары – Рафаил белән Рөстәм туа. Ләкин сугыш афәте бу гаиләгә дә аерылышу алып килә. Фронт редакциясенә командировкага җибәрелгән Фатыйма исемле туташ белән мөнәсәбәтләреннән Риза Ишморатның Фәрит исемле улы дөньяга килә. Сугыштан соң инде Риза да, Рәшидә дә бергә була алмаячакларын аңлыйлар. Рафаил – әтисе белән, Рөстәм әнисе белән кала. Соңрак Риза Ишморат Рәйсә ханымга өйләнә. Уртак балалары Равил туа.

«ИҢ СОҢГЫ СҮЗ»

Атеистик дәүләттә яшәү Риза Ишморатның тормышына гаять көчле йогынты ясый. Мулла баласы булу совет чорында язучыга никадәр авырлык тудырганын ул бары үзе генә белгәндер, мөгаен. Риза Ишморат башка бик күп кешеләр кебек үк диннән читләшә. Ата-бабаларыннан мирас булып килгән хәзинәгә яңадан якынаю аңа ил таркалгач кына насыйп була. 1992 елда ул «Иң соңгы сүз» дигән мәкаләсен яза. Анда Риза татар шигъриятенә үз карашын белдерә һәм биш иң яхшы татар шагыйрен күрсәтә. Дөньяда иң камил шигырьне дә атый: шигъри икеюллык – Коръәннең 112 нче «әл-Ихлас» сүрәсе ул. Кайчандыр, бала чакларында, этиләре Фәхретдин уллары Риза һәм Зыя белән әлеге шигырьнең мәгънәсен тикшергән була. «Иң соңгы сүз»ендә язучы әлеге сүрәне тирән эхлакый, фәлсәфи һәм фәнни фикерне эченә алган, кешеләрне уйландыра торган бөек әсәр дип атый.

ЗЫЯЛЫЛАР СҮЗЕ

Әлфәт Закирҗанов, филология фәннәре докторы:
– XX гасырның 1920–1960 нчы еллары арасында драматургия түрендә Нәкый Исәнбәт, Таҗи Гыйззәт, Мөхәммәт Әблиев, Риза Ишморат, Гамир Насрый, Сәет Шәкүров, Абдулла Әхмәт, Әнәс Камал һ.б. актив эшли. Әлеге чор сәхнә әдәбияты бүген аеруча зур бәхәсләр уята. Бер яктан, 1920–1930 нчы елларда уңышлы эшләгән Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Ибраһимов кебек әдипләр «шәхес культы» репрессияләренә эләгә. Икенче яктан, язучылар гаять көчле идеологик басым астында калып, шул шартларга яраклашырга мәҗбүр була. Шуңа да бу елларда язылган пьесаларның зур күпчелеге совет хөкүмәте тудырган мифларга йөз тотып иҗат ителгән. Нәтиҗәдә, 1917 елга кадәрге тормышны тәнкыйтьләгән, совет чорын мактаган күпсанлы әсәрләр языла. Әмма ул чорда да халык тормышын, аның үткәне белән бәйләнештә, еш кына халык авыз иҗаты, тарихи шәхесләр аша сурәтләгән пьесалар языла, сәхнәгә менә. Әдипнең сугыш чорында язылган «Кайту» (1942) драмасы шул чорның иң уңышлы әсәреннән булып, сугыш елларында сәхнәләрдән төшми уйнала, тамашачы күңелендә фашизмга нәфрәт, җиңүгә ышаныч хисләре тәрбияли. Риза Ишморатның 1950 нче елларда язылган «Үлмәс җыр» драмасы Муса Җәлил батырлыгын сурәтләгән, шагыйрьнең әдәби образын торгызган беренче әсәрләрдән була. Ул берничә телгә тәрҗемә ителеп, рус, мари, үзбәк театрларында куела. «Алар дүртәү иде» («Океан батырлары») пьесасы да татар кешесенең героик образын сурәтләве белән үз вакытында яңгыраш ала. Шул рәвешле, Риза Ишморат иҗаты татар драматургиясендә Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнашлар буынын 1960 нчы еллардагы Хәй Вахит, Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин кебек драматургларга тоташтыруда, традицияләрне яклауда һәм саклауда, үз чоры татар тамашачысын театр залларына китереп, аның рухи ихтыяҗына җавап бирүдә билгеле бер урын алып тора.

МИФ ҺӘМ ИЛЛЮЗИЯЛӘР, ЯКИ КЕМНЕҢ ДӨРЕСЛЕГЕ ДӨРЕСРӘК?

Луиза Янсуар

2023 елда прокатка чыккан сериаллар арасында, җитди темаларны күтәреп тә, аны шактый җиңел, мавыктыргыч итеп, динамик рухта тәкъдим итүчеләр бар. Сәясәтнең караңгы ягын чагылдырган, бүгенге корпорацияләр тарафыннан «сатып алынган» дөнья сурәте булсынмы ул, без асылын белеп бетермәгән дини күзаллауларның аргы ягындагы җан өшеткеч вакыйгалармы – боларны 6–7 эпизодка сыйдырып, интрига калдыру – стриминглар нәкъ менә шуңа омтыла.

Фотолар: kinopoisk.ru, goodfon.ru, film.ru

«СУЛЫШЫМДА КУРКУНЫҢ ЭЗЕ ДӘ ЮК...»

Исеме: Связь

Елы: 2022

Сезоны һәм эпизодлары: 1 сезон, 6 эпизод

Платформасы: Apple TV+

Иле: Бөекбритания, Франция

Жанры: триллер, боевик, драма, детектив

Сценарий авторлары: Виржини Брак, Оливер Батчер

Режиссеры: Стивен Хопкинс

Дөньякүләм премьерасы: 24 февраль 2023 ел

Төп рольләрдә: Венсан Кассель, Ева Грин, Жерар Ланвен, Питер Муллан, Дэниел Фрэнсис, Ирен Жакоб һ.б.

Бу сериал нигездә детектив белән драма арасында тирбәлә, дөрес, триллер белән боевикка хас элементлар да урыны-урыны белән калкып чыга һәм экшн тәмен тоярга мөмкинлек бирә. Сюжет линиясе әллә ни катлаулылыкка омтылмый, режиссер да аны артык тирәнәйтүне кирәк тапмый, әмма эстетика белән динамикага шактый зур игътибар юнәлтә. Халыкара террористик куркыныч турында без бүген көн дә диярлек ишетеп торабыз. Сериал акцентны Европа кризисына һәм Бөекбритания белән Франция арасындагы каршылыкка багышлый. Мифмы бу, түгелме, анысын һәркем үзе хәл итәр, ләкин «Связь» чынбарлыгында моны хәтта төп каһарманнарны уйнаучы актерлар да билгели – Венсан Кассель (Франция) белән Ева Грин (Бөекбритания).

Вакыйгалар Сүриядә, Дәмәшкъ шәһәрендәге ташландык, җимерек корылмада һәм төп геройларның берсе Габриэль Делаж фатирында башланып китә. Президент Башар Асадка һөҗүм ясаган ике хакер, әллә ни уйлап тормыйча, яшерен корал сату операцияләре белән бәйле куәтле корпорациягә – «Антропа»га килеп юлыга, алар турындагы мәгълүматны флешкаларына йөкләтеп ала. Бу мәгълүматларны үз файдасына кулланып, кыйммәткә сатарга теләгән ике дәһинең язмышы шул мизгелдән пыран-заран килә – аларга Бөекбритания белән Франция хакимиятләре ау башлый.

Кассель герое – махсус хезмәтләрдә гомере буена эшләгән, күп яшерен операцияләрдә чыныккан һәм аларны уңышлы ерып чыккан агент, хәзерге вакытта хакимияттәге түрәләр мөрәҗәгать итә торган шәхси контора хезмәт күрсәтә. Әлеге дә баягы хакерларны яшерен юл белән Сүриядән чыгарып Франциягә китереп тапшыруны аңа юкка гына йөкләмиләр. Әмма бар яктан уйланган операциягә кинәт рус хезмәтләре килеп комачаулый, ә ике хакер, берәү дә фаразламаганча, Бөекбританиягә барып чыга. Һәм менә борынгыдан килгән ныклы затлы дөньяның нигезе булган Лондонда бер-бер артлы терактлар сериясе башлана: башта, компьютерлар «котырынып», дамба сафтан чыга һәм Темза ярларыннан ташый, ул да булмый, тимер юл поездлары бер үк юлдан кара-каршы килеп шартлый, аэропортка төшәргә тиешле 250 пассажир утырган самолёт кинәт кенә идарәсен җуя. Дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү министрлыгы хафага кала: Бөекбританиягә киберһөҗүмнәр ясап, ниндидер хәйлә корыла, моның артында кем торуын ачыкларга керешәләр. Бөекбритания һәм Франция разведкасы үзара кисешсә, нәрсә булачак, алга таба вакыйгалар әнә шул юнәлештә үстерелә. Һәм, әлбәттә инде, Брекситтан соңгы Европа эчендә нинди махинацияләр кайнавы, аларның кемнәргә барып тоташуы – төп интрига.

СЕРИАЛ ИКЕ ТЕЛДӘ ТӨШЕРЕЛЕП, ИКЕСЕНДӘ ДӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ. МОННАН ТЫШ, ВЕНСАН КАССЕЛЬ ГЕРОЕ, РУС ТЕЛЕНДӘ ҺӘМ ГАРӘПЧӘ ДӘ ШАКТЫЙ КАМИЛ СӨЙЛӘШӘ.

Сериалның буеннан-буена без ялланган агент Габриэль Делаж белән Бөекбританиянең Дәүләт

куркынычсызлыгын тәэмин итүче министр ярдәмчесе Элисон Роуди арасындагы каршылык катыш мәхәббәт чаткыларын... чынлыкта давылын (!) күзәтәбез. Кайчандыр алар арасында булган хәлләрнең төйнәлешен безгә сюжет иң киеренке мизгелләренә җиткәч ачып салалар: яшьлегендә бу икәүне бәйләгән пацифистик агымнар кайтавазы һәм фаҗигале үлем тарихы хәзергә кадәр төзәлмәс яра булып кала бирә икән... «Егерме ел буе син минем күз алдымда тордың, һәр чатта, һәр борылышта чалындың, мин бүтән болай яши алмыйм!» – ди Элисон, ачырганалып. Хисләр ташкыны ничек кенә күмеп китмәсен, онытмыйк: алар икесе дә – чын профессионаллар. Һәм бу юлы кем кемне сатар да, кем кемнән үчен алыр икән дигән сорау соңгы серия азагына кадәр гел баш миен бораулап тора. Пастораль һәм идиллик мәхәббәт тарихы була алмый бит инде...

«БЕЗ ХЫЯЛЛАРЫБЫЗГА ДА, МАКСАТЫБЫЗГА ДА ХЫЯНӘТ ИТМӘДЕК!» – ДИ ЭЛИСОНГА ЯШЬЛЕК ДУСЛАРЫ. «Ә СИН?» – ДИМИЛӘР. ҺӘМ АНЫ БЕРКАЙЧАН ДА КИЧЕРӘ АЛМАЯЧАКЛАРЫ ДА – АЕРМАЧЫК.

Әйтергә кирәк, сериалның азагына кадәр бу икәүнең бер-берсенә тартылу көче, экрандагы химиясе платоник рәвештә генә булып кала бирә. Әмма без һаваның никадәр тыгызланганын һәм фаҗига буласын физик дәрәҗәдә сизәбез. Элизабет Фрейзер вокалы белән тексты «Связь» вакыйгалары җирлеген каһарманнарның дуамал яшьлегенә кайтарып, хәзер аларның кемнәргә әйләнгәнен күрсәткәндә – бигрәк тә.

Тормыш һәркайсын үз урынына утырткан, статусын, ролен билгеләгән. Читлекләргә без үзебезне үзебез утыртып куеп яшәтәбез түгелмени?

Сумы бу? – күзләрем минем
Иң дөрес күрсәтүче көзгеләр, әйтерсең.
Сулышымда куркуның эзе дә юк.
Күз яшьләрем тәүбә уты бөрки.
Сулышымда куркуның эзе дә юк...

Озакламый без Кассель белән Гринны «Өч мушкетёр»ның яңа экранизациясендә күрәчәкбез – Атос белән Миледи образларында. «Связь» сериалын салкын кабул иткән тәнкыйтьчеләр шаярта: «Бу сериал актёрлар өчен генераль репетиция булгандыр...»

Ничек кенә булмасын, бүгенге чынбарлык яссылыгында барысы да «укыла». Мин безне күптән үзенә буйсындырган корпорацияләр ятьмәсеннән ничек ирекле калу мөмкинлеге турында да түгел, ә ничек киләчәк буыннарга – балаларыбызга иминлек бүләк итәргә мөмкин булуы турында уйландым...

КОЛАГЫҢА КЕМ ПЫШЫЛДЫЙ?..

Исеме: Под знаменем небес
Елы: 2022
Сезоны һәм эпизодлары: 1 сезон, 7 эпизод
Платформасы: Hulu
Иле: АКШ
Жанры: триллер, детектив, криминал, драма
Сценарий авторлары: Брэндон Бойс, Джина Уэлш, Дастин Лэнс Блэк
Режиссерлары: Кортни Хант, Дэвид Маккензи, Дастин Лэнс Блэк
Дөньякүләм премьерасы: 28 апрель 2022 ел
Төп рольләрдә: Эндрю Гарфилд, Сэм Уортингтон, Дэйзи Эдгар-Джонс, Дениз Гоф, Уайатт Рассел, Билли Хоул, Хлоя Пирри, Сет Нумрик һ.б.
Бүләкләре: «Алтын глобус», «Эмми» (2023)

Сериал 1984 елда мормоннар җәмгыятендә булган чын җинаятькә нигезләнгән. Корбаннар – 24 яшьлек Бренда Лафферти һәм аның яшь ярымлык кызы. True crime («чын җинаять») жанры соңгы арада бик популяр. «Под знаменем небес» Джон Кракауэр 2003 елда язган «Под знаменем Рая. Шокирующая история жестокой веры мормонов» документаль әсәренә нигезләнгән.

Лафферти тарихы турыдан-туры мормоннар ианауының беренче көннәренә алып барып тоташтыра, чөнки бу гаиләне әле аңа нигез салучы Джозеф Смит белән үк туганлык җепләре бәйли.

АМЕРИКА КУШМА ШТАТЛАРЫНДА ЯҢА СИОН ТӨЗЕРГӘ ХЫЯЛЛАНГАН МИССИОНЕР ЯЗМЫШЫ ҺӘМ АНЫҢ КҮРӘЗӘЛӘРЕ XX ГАСЫР АЗАГЫНДА ДА НИ ДӘРӘҖӘДӘ ТӘЭСИР ИТҮ КӨЧЕНӘ ИЯ ҺӘМ МАНИПУЛЯЦИЯЛӘРГӘ КУЛАЙ ИКӘНЕН РЕЖИССЕР БИК АНЫК КҮРСӘТӘ.

Бигрәк тә – иң мәртәбәле, үрнәк гаиләнең фаҗигасе мисалында. Бренда героинясы: «Лаффертиларга кияүгә чыгу – патша гаиләсе белән туганлашуга тиң!» – дип юкка гына әйтми.

Дейзи Эдгар-Джонс әле күптән түгел генә экраннарга чыккан «Там, где раки поют» фильмында соклангыч иде, биредә, Бренда Лафферти ролендә дә – искиткеч. Система таккан кануннарга һәм сөрсеп беткән кагыйдәләргә каршы торучы героинялар – нәкъ менә аныкы, шул ук вакытта, аңардан искиткеч бөтенлек, гармония, хатын-кыз җылылыгы, нуры да бөркелә. Гарфилд каһарманы үзенең эчке кичерешләр гаммасы, бәргәләнүләре белән кызыклы. Мормоннар арасында тәрбияләнеп үскән, эчке бер рухи иминлек белән аерылып торган бу кешегә, детектив буларак, болай да җиңел түгелдер, ә биредә, ерткычларча, үз конфессиясе эчендә мәсхәрәләп ташланган яшь ана белән бала гәүдәсенә юлыккач, җинаять эзеннән бару – бигрәк тә. Аның дин һәм рух буенча туганнарына ышанычы көннән-көн кими, иманы көчле сынау астында кала. Янәшәсендәге икенче бер детектив – Гил Бирмингем каһарманы Гарфилд кичергән кризиска капма-каршы яссылыкта: бу олыгаеп барган һәм үз башыннан күпне кичергән индеец инде иллюзияләрдән күптән арынган. Һәм Юта территориясендәге кечкенә генә «Оҗмах»ның ни бәя торганын яхшы белә, шуңа да Лаффертиларның ярты сүзенә дә ышанмый. Гәрчә кимсетелгән вә азчылыкны тәшкил иткән кешеләр бер-берсен якларга тиеш, дигән позиция яклы булса да.

Сериал ашыктырмый, Лафферти гаиләсенең барлык вәкилләрен дә берәмтекләп өйрәнеп чыгарга, аларның версияләрен һәм «дөреслекләрен» барларга, тикшереп карарга мөмкинлек бирә. Мормонлык тарихының чишмә башына кайту флешбеклар аша тәэмин ителә, нигездә без бер гасырлык кысрыклау, җәзалау һәм юкка чыгарулар чылбыры белән очрашабыз. Безнең көннәргә кадәр килгән канлы эзләр һәм рәнҗүләр чылбыры бу.

Детектив Джеб белән бергә без каһарманнарның өйләренә дә, күңел почмакларына да керә-чыга йөрибез. «Хаклы» һәм «хаксыз» булуның, «дөреслек» һәм «нахакның» ни икәнлеген берничә вариациядә ишетәбез, күрәбез, аңлыйбыз... Ахыр чиктә, иман белән саташуның ни дәрәҗәдә якын торганына шаккатабыз. Бигрәк тә «Күктәге Ата» улларына «чистарыну» өчен якыннары белән туганнарына кул күтәрергә, хәтта ки җинаятькә барырга хокук биргәннән соң...

1980 нче еллардагы икътисади кризис шартларында Лафферти гаиләсе бизнесын югалтыр дәрәҗәгә җитә. Еллар буена дәүләт белән мөнәсәбәтләре тыныч булган өлкән Лафферти улларының берсенә гаилә белән идарә итү йөгенен тапшыргач, пәйгамбәрлеккә дәгъва иткән уллар арасында, беренчедән, көндәшлек башлана, икенчедән, алар мормонлык чорының башына кайтырга һәм кабаттан үз хокукларын дауларга карар кыла. Конфликтны көчәйтүче, катализатор ролен үтәүче нәкъ менә Бренда була – Лаффертилар гаиләсенә килеп кергән бу күз явын алырдай матур тулаш баштарак матурлыгы белән барысының да күзен кыздыра, соңыннан акылы, белеме, сыгылмас холкы белән ачуларын кайната башлый. «Хатын-кыз үз урынын белергә тиеш!» дигән девиз Бренда өчен киртә түгел, идарә дилбегәсен яңа кулларына алган Лафферти уллары, ни кызганыч, моны кичерә алмый.

Җинаятькә һәм коррупциягә батып беткән дәүләткә буйсынырга теләмәгән һәм үзләрен хакыйкатьне яклап көрәшкә күтәрелгән «Яктылык яугирләре» санаган Лаффертилар, ахыр чиктә, кулларын канга батыра. Әмма алар ахыргача үзләрен

– МИҢА ИНАНУ КИЛДЕ. МИН КҮКТӘГЕ АТАБЫЗНЫҢ ТАВЫШЫН ИШЕТТЕМ. УЛ МИҢА: «СИН САЙЛАП АЛЫНГАН ОЛАН, СИН – ПӘЙГАМБӘР», – ДИДЕ.

– ЮК, ТУГАН. БУ – ЯЛГЫШ ИНАНУ. ЧӨНКИ КҮКТӘГЕ АТАБЫЗ МИНЕ САЙЛАДЫ, ЧЫН ПӘЙГАМБӘР УЛ – СИН, ДИП МИҢА ӘЙТТЕ.

«Күктәге Аталары» өндәде дип исәпләвен дәвам итә.

Биредә без мормоннарны начар яктан күрсәтә, гаепли торган позиция белән очрашмыйбыз, ә ситуацияне анализларга, аңларга омтылыш күрәбез. Кракауэр китабына шикаятьләр күп булса да, сериалда режиссер һәм сценарий авторлары, кискенлекне алып, психологик яктан якын килергә тырышкан.

Безгә бу тарих әллә кайдагы мормоннар һәм аларның сәер инанулары турында булып тоелырга мөмкин, әлбәттә. Юк, тирәннәнрәк уйлап карасак, ул безгә бик якын. Колагыңа кем пышылдавын анык аера алмасаң... Иртәгә ни кылганыңны абайламый да калырга мөмкинсең. Нинди генә чор булмасын...

Татарстан авыллары

НАРАТ-ЕЛГА – ТЫРЫШКАН ХУР БУЛМАС!

НАРАТ-ЕЛГА



Фото: Александр Ефремов

Җәйнең соңгы көннәрендә Чистай районының Нарат-Елга авылында булдык. Колхозлар җимерелгәннән соң, халык аптырап калмаган: күбесе пай җирләрен алып үзләре эшкәртә башлаган. Нәтиҗәдә, авылда сыер асраучылар күп, күбесе берничә баш тота.

Нарат-Елгада тагын ниләр гаҗәпләндерде һәм ни өчен борчуга калдык?

Руфия Фазылова

«БАЛАЛАР ЮК...»

Нарат-Елгада 232 кеше яши, 93 хуҗалык исәпләнә. Социаль объектлардан мәдәният йорты, башлангыч мәктәп, ФАП, мәчет, кибет бар. Әйткәнемчә, күп итеп мал асрыйлар. Шәхси ярдәмчел хуҗалыкларның саны кырыкка якын. Тагын авыл хуҗалыгы тармагы белән шөгыльләнүче дүрт эшмәкәр бар. Аларның берсе фермер, калган өчесе үз транспортларында йөк ташый.

Үз эшләрен башлаган шул тәвәккәл егетләрнең берсе, яшь фермер Рифат Хәмитов белән танышып чыктык. Өч йөз гектар җире бар икән. Авылдашларының пай җирен арендага да, сатып та алган.

– КАИның Чистай филиалын тәмамладым, – диде Рифат. – Кулга диплом алгач, кайда гына эшләмәдем. Ләкин күңелдә һаман ниндидер ризасызлык бар иде, чөнки үземә эшлисем килде. Шуның өчен 2021 елда тәвәккәлләдем, шәхси эшмәкәр булып теркәлдем. Башта егерме гектар җир чәчтем, аннары кырык, илле... Җирләрне тагын арттырырга исәп бар. Ел саен берәр техника алдым. Дөресен генә әйткәндә, әле гел фермерлык эшен үстерү өчен эшлим, керем дип зурлап сөйли торган түгел. Техникаларда күбрәк үзем йөрим. Сезон вакытында, эш бик тыгыз чакта кешеләр чакырам.

1 Яшь фермер Рифат Хәмитовның өч йөз гектар җире бар.

2 1969 елда төзелгән бина бер тапкыр да капиталь төзекләндерү күрмәгән.

Яшь фермердан быелгы уңыш турында сорашам: былтыргысының нәкъ яртысы булган! Узган ел гектарыннан кырык центнердан артык иген алса, быел егермедән артык икән. Ләкин аңа карап игеннең сату бәясе барыбер артмаган. Ә менә печән бәясе бермә-бер арткан.

– Быел печән дә юк. Шуның өчен бер төргәк печәнне ике мең ярымнан саталар, – диде Рифат. – Яңгыр яумагач, үлән үсмәде. Нишлисең, ел белән ел бер булмый.

Яшь фермер дәүләттән бер ярдәм дә алмаган. Андый нияте булган, ләкин күпме документ җыясын күргәч, кул селтәгән. Бүген инде аякта шактый нык торучы фермерга әйләнеп бара. Максат, планнары зурдан.

– Авылда синең кебек яшьләр тагын бармы? – дим яшь фермерга.

– Юк шул. Эх, минем шикелле авылны яратучы тагын берничә яшь кеше булса иде, яшьләр сала тормышын үз итми шул.

– Өйләнмәгәнсең дә икән әле, – дим.

– Юк әле. (Көлеп җибәрә. – Авт.) Авылга кайтырга кызлар курка бит...

Рифат бик ачык егет, ихлас. Чынлап та, авылда аның кебек тагын берничә яшь егет калса, гаилә корса, Нарат-Елганың киләчәге өметле булыр иде, ә әлегә...

МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ – АВЫЛ КҮРКЕ, ӘММА...

Әлегә авылда хәлләр бик мактанырлык түгел: балалар бакчасы 2007 елда ябылган, башлангыч мәктәптә дә биш кенә бала укый. Соңгы ике елда мәктәпкә бала кермәгәнен исәпкә алсак, белем йортының киләчәге аяныч хәлдә икәнен чамаларга була.

Аннан бигрәк мәдәният йорты игътибарны җәлеп итте: 1969 елда төзелгән бина бер тапкыр да капиталь төзекләндерү күрмәгән. Ярык стеналардан урам ук күренмәсә дә, җил уйный. Әллә ничә кат буялган агач идәннәр, ярты гасырдан артык яшәвен аңлаган кебек, баскан саен авыр итеп шыгырдап куя...

Мәдәният йорты хезмәткәрләре белән якыннан танышкач, күңелгә тагын да авыр булды. Үз эшләренең чын осталары булган әлеге гүзәл затларга яхшы шартлар да тудырсаң, тагын әллә ниләр эшләрләр иде.

Мәдәният йортының зур булмаган бер бүлмәсе музей да, күргәзмә залы да, остаханә дә икән! Балчыктан ясалган төрле сыннар, чигүле калфак, изүләр – ни генә юк. Һәм аларның барысын да биредә эшләүчеләр үзләре ясый, тегә.

– 1989 елны Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлагач та Ләйсирә белән Нарат-Елгага эшкә кайттык, – диде биредә утыз елдан артык мәдәният йорты җитәкчесе булып эшләүче Сәгыйдә Сибгатуллина. – Беребез директор, икенчебез сәнгать җитәкчесе булдык. Бер ел дигәндә Нарат-Елга авылы егетләренә кияүгә дә чыктык. Бөтен гомеребез биредә үтте. Шуның кадәр күңелле эшләдек. Үзем гармунда, курайда да уйныйм, училищеның оркестр бүлеген тәмамладым бит. Ләйсирә исә вокал бүлегендә укыды, бик матур җырлый. Дистә еллар эчендә күп балалар курайда уйнарга өйрәнде, гармунчылар да байтак булды. 2015 елда тугызъеллык мәктәпне ябып, кырыктан артык баланы Чистайга укырга җибәрделәр. Ул вакытлар бик авыр булды. Ата-аналар да нык борчылды – көн саен унсигез чакрым тегендә-монда балаларны йөртергә кирәк бит. Хәзер дә шулай йөриләр, инде ияләндек. Хәер, бүген аның балалары да күп түгел.

Мәктәп башлангычка гына калгач, мәдәният хезмәткәрләре күбрәк олылар белән эшли башлаган. Өлкәннәр өчен «Умырзая» фольклор ансамбле оештырганнар, төрле түгәрәкләр ачканнар.

– Тугызъеллык мәктәп булганда, эшләве күңеллерәк иде, – диде Нарат-Елга мәдәният

йортының режиссеры Лэйсирә Җамалетдинова. – Укучылар өйләренә кайтканчы төрле түгәрәкләрдә шөгыльләнде. Район үзәгенә йөреп укыгач, алай эшли алмыйлар. Укырга бик иртә китәләр, соң кайталар...

Балчыктан сыннар ясыйлар дигән идем: 2013 елда, РФ Мәдәният министрлыгы конкурсында катнашып, грант отканнар. Шул акчага мәдәният йортына балчык киптерә торган электр миче һәм бер гармун алганнар. Хәзер төрле сыннар ясап, күргәзмәләрдә катнашалар. Балаларга, өлкәннәргә дә осталык дәресләре үткәрәләр. Ә гармун исә кулдан кулга йөри.

– Бу кызларга медаль бирергә була, – дип сүзгә кушылды Нарат-Елга авыл җирлеге башлыгы Альфред Хәмитов. – Районның бер генә мәдәни чарасы да алардан башка узмый: җырлыйлар да, музыка уен коралларында да уйныйлар, биилләр, кул эшләре күргәзмәсе дә оештыралар. Әле мин дә гел эш кушып торам: авыл территориясен тәртиптә тотарга кирәк бит. Бер каршы килмиләр, рәхмәт яусын.

– Мәдәният йортына капиталь ремонт кайчан була? – дим авыл җирлеге башлыгына.

– Быел тиеш иде, төрле сәбәпләр аркасында булмый калды. Районда бер безнең авыл гына түгел бит. Көтәбез, өметләнәбез инде...

АЛТМЫШ ҖИДЕ ЯШЕНДӘ АТТА ЧАБА!

Нарат-Елгада сыер фермалары юк. Кайчандыр йөзәр баш мал яшәгән биналар бүген моңсу гына утыра. Алай да ферма биналарының берсенең җаны бар – биредә «Русская рысистая» токымлы йөзгә якын ат яши.

Валерий Максимовны «атлар хуҗасы» дип таныштырдылар. (Керәшен татары икән). Юк, аның шәхси фермасы түгел бу, ул биредә эшли генә. Ә ферма дәүләт карамагын-

3

4

3

– 2013 елда, РФ Мәдәният министрлыгы конкурсында катнашып, грант оттык, – диде мәдәният йорты җитәкчесе Сәгыйдә Сибгатуллина.

4

Балчыктан ясалган төрле сыннар, чигүле калфак, изүләр – ни генә юк.

5

Үз эшләренең чын осталары булган әлеге гүзәл затларга яхшы шартлар да тудырсаң, тагын әллә ниләр эшләрләр иде...

5

да. Валерий дәдәй атсыз яши алмый торган кешеләрнең берсе. Үзен белгәннән бирле ат янында мәш килә. Соңгы утыз елда исә атта чаба! Сүз профессиональ ярышлар турында бара. Россия күләмендә, Татарстан буенча үткәрелгән чабышларда даими катнаша, Сабан туйларын инде әйткән дә юк.

– Алтмыш җиде яшендә җайдак булган тагын башка кешеләрне беләсезме? – дидем Валерий дәдәйгә.

– Казан ипподромында бар. Ләкин ул атларны өйрәтми, йөгерә генә. Мин бит барысын да эшлим: ашатам, аннан көн саен атларны берәр сәгать йөгертергә алып чыгып китәм. Профессиональ ипподромнар белән авыл фермасы ярыша алмый, әлбәттә. Шулай да сер бирмибез: ярышларда призлы урыннарны бик еш алабыз.

Нарат-Елга фермасында нәселле чабышкылар да тоталар. Шуның өчен дә аларга тәрбия зур: ашау да балансланган. Һәр колынның паспорты бар. Яшь тайларны Россиянең төрле шәһәрләреннән килеп алалар икән.

– Нарат-Елгада ат фермасы 2015 елда ачылган иде, шуннан бирле эшлим, – диде Валерий дәдәй. – Бүгенгесе көндә нәселле утыз бия асрыйбыз. Колын алты айга җиткәч, анасыннан аерабыз. Тайларны бер яшькә кадәр үстереп сатабыз. Берничәсе үзебезнең фермада кала. Бөтен колын да яхшы чабышкы ат була алмый бит, кайсы иткә дә китә.

– Яхшы нәселдән туса да, чабышкы ат булмаска мөмкинме? – дим.

– Әлбәттә, әйтәләр бит: «Аттан ала да туа, кола да», – дип. Дөрес инде ул: бер яшендә тайның чын чабышкы булачакмы-юкмы икәнлеге күренә...

Валерий дәдәйнең бүген дүрт чабышкы аты бар. Ул аларны аерым япкан, башка атлар белән көтүгә дә кумый икән. Көн саен шуларны чиратлап берәр сәгать йөгертеп керә. Буранмы, яңгырмы – ел әйләнәсе әнә шулай урман буйларын дүрт тапкыр әйләнеп кайта.

6

Валерий Максимовны «атлар хуҗасы» дип таныштырдылар.

– Чабышкы атларны көн саен җиде-сигез чакрым йөгертергә кирәк, шунсыз алар осталыкларын югалта, – дип дәвам итте Валерий дәдәй. – Әле менә быел ике яңа тайны өйрәттем. Гадәттә, ярышларга йөрер өчен ике ат тотам. Мин гел бияләрне генә өйрәтәм. Айгырлар көчлерәк чаба, әлбәттә. Ләкин бияләр сабыррак, тынычрак була. Ә ярышларда шунысы да мөһим.

– Ә сезнең монда дүрт чабышкы ат бит? – дим.

– Икесе аның яшь әле, зур ярышларда катнашканнары юк. Алла боерса, берсен алып барырга исәп бар.

– Ярышларда атлар ничә яшькә кадәр катнаша? – дим.

– Мин биш яшькә кадәр чаптырам, аннары башка бияләр белән бергә ябам. Биш яшьтән соң атның көче барыбер үзгәрә. Шуның өчен дә яшьләрен өйрәтәм.

Әйткәнемчә, фермада яшь тайларны саталар. Аның бәясе йөз мең сумнан башлана. Нәселле атларның хакы әти-әнисенең ярышларда җиңүләренә карый икән.

Саубуллашканда Валерий дәдәйгә: «Ә сез тагын ничә яшькә кадәр атта чабарга телисез?» – дидем. Ул исә ихластан көлде. Баксаң, бу сорауны аңа бер тапкыр гына бирмәгәннәр:

– Сәламәтлек булганда, – диде ул. – Мин бит атлардан башка яши алмыйм. Гомер буе ат асрадым. Фермага эшкә кергәч кенә үз атымны саттым, чөнки аңа вакыт калмый башлады. Атлар алар кайбер кешеләрдән дә акыллы, рәхмәтле, әйтеп бетергесез көч-куәт бирәләр. Әнә шулар янында йөргәнгә сәламәтлек тә яхшыдыр...

«КӘҖӘ СӨТЕ ЯШӘРТӘ!»

Авылның кибетчесе Чулпан Гатауллина белән таныштык. Бу сөйкемле ханым игътибарны ни өчен җәлеп итте – кәҗәләр асрый икән. Кәҗә сөтеннән бик тәмле сыр, эремчек ясый, сораган кешегә сата да. Чулпан апа безне өенә чакырды: сиксән ике яшьлек энисе Венера апа белән яши икән.

– Гомер буе Чистайда яшәдем, эти вафат булгач, эни янына кайттым, – диде ул.

Әниле-кызлы гомер итүче бу ике гүзәл затка сокландык без: бөтен эшне бергәләп башкаралар, аңлашып яшиләр. Бакчаларында ни генә үсми: кавын-карбыздан башлап, төнбоек чәчәкләренә кадәр бар.

– Кибеттә өченче елымны эшлим, – диде Чулпан апа. – Көне буе өйдә тормыйм, шуның өчен дә бакча күбрәк эни өстендә. Чәчәкләр бик яратабыз, ясалма сулыкка кадәр ясап куйдык. Елларга оныкбелән кызым кайта. Менә шушы матурлыкка сокланып, кайнар чәйләр эчеп, кич утырабыз.

Кәҗәләрне Чулпан апа авылга яшәргә кайткач алган. Бүген ике кәҗәсе бар. Көненә алты литр сөт сава икән. Кәҗә сөтенең файдасы

турында укып кына белгән ханым хәзер моның чынлап та шулай икәнлегенә үз мисалында инанган.

– Көн саен бер стакан яңа савылган сөт эчәм, – диде хуҗабикә. – Сәламәтлегем күзгә күренеп яхшырды: организмда бер җиңеллек барлыкка килде. Ә сырның тәмлелеге! Рецепты да бик гади: сөтне кайнатам да, сыр ясый торган махсус порошок өстим. Ул эремчекләнеп килә дә, дуршлагка салам. Мондый сырга төрле чикләвекләр, яшелчәләр, тәмләткечләр дә кушарга мөмкин. Сырны ашап караган кешеләр янә заказ бирә.

– Элек кәҗә асрадыгызмы? – дип сүз каттым кызының сөйләгәнен елмаеп кына тыңлап торучы Венера апага.

– Юк, асрамадык. Гомер буе сыер асрадык без. Картайгач малларны бетердек. Кәҗә алыйк дигәч, кызымның теләгенә каршы килмәдем. Мин кәҗә сөте эчмим, ә менә эремчеген яратып ашыйм. Чулпан кыстый-кыстый ашата, озак яшәрсең, ди.

Икенче урамда яшәүче Мәймүнә апа Исхакова, кәҗә сөте эчмәсә дә, туксан өч яшькә кадәр җиткән. Нарат-Елгада туган, биредә гаилә корган, балалар үстергән...

– Мәктәптә өч кенә ел укып калдым, – диде Мәймүнә апа. – Сугыш башлангач, уку кайгысы булмады – өлкәннәргә ияреп кырга чыктык, болында көтү көттек. Уналты яшемнән сыер сава башладым. Мәрхүм ирем башта шофер булды, аннан фермада эшләде. Безнең чорда колхозлар гөрләп эшләде: куян фермасына кадәр бар иде. Алдынгы колхоз саналды. Заманында мәктәбен, бакчасын, мәчетне дә колхоз салды. Бүген менә шуларны уйлап ятам. Бабай булмагач күңелсез, кызым. Ул һич уйламаган җирдән 2011 елда вафат булды. Әле ярый кызларым бар, берсе авылда калды. Төпчек кызым кияү белән атна саен кайта. Балаларга рәхмәттән башка сүз юк.

Мәймүнә апа яман чирне җиңгән кеше. Эчке әгъзаларына ике тапкыр катлаулы операция ясаганнар. Бүгенге көндә сәламәтлегеннән зарланмый, дарулар белән дә мавыкмый. Күкләр могҗизасы шушыдыр ул...

...Нарат-Елга зур булмаса да, биредә яшәүчеләрнең йөрәге олы. Ул кешеләр белән аралашканда сизелә. Ә тырышлыклары турында бер генә сан сөйли: 93 хуҗалыкка дүрт йөзгә якын мөгезле эре терлек бар. Гасырлар кичкән бу авылга ихластан озын гомер телим. Ул һич кенә дә картаерга, сүнәргә тиеш түгел...

7

– Көн саен бер стакан яңа савылган сөт эчәм, – ди Чулпан Гатауллина.

8

– Кәҗә алыйк дигәч, кызымның теләгенә каршы килмәдем, – диде Венера апа.

9

Яман чирне җиңгән Рәшидә апа Исхакова.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Нарат-Елганың кайчан барлыкка килүе төгәл билгеле түгел.

Авыл уртасыннан ага торган елгада бик күп нарат агачы үскән. Шуңа да авылга Нарат-Елга дигән исем биргәннәр дип сөйлиләр.

Авылга башлап бер сунарчы килеп утырган, диләр. Чистайга бара торган юлның уң ягында, тау башында куш нарат үскән. Сунарчы шуның эчендәге куышта яши башлаган. Соңрак исә аның янына башка кешеләр дә килеп урнашкан.

(Гаяз Әминов, «Нарат-Елга авылының кыскача гына тарихы» китабыннан.)

КОСТЮМНАР КҮРГӘЗМӘСЕ (0+)

Танылган фильм геройлары кигән костюмнарны, шулай ук төшерү барышында кулланылган аксессуар һәм бутафорияне «Закройщики иллюзий» дип аталган күргәзмәдә күрергә мөмкин. Бу – Мәскәү кино музее белән илебез кинематографының әйдәп баручы рәссамнарының берсе Дмитрий Андреевның уртак проекты. Күргәзмә Пушкин, Лермонтов, Лев Толстой һәм Достоевскийның классик әсәрләрен экранлаштырудан алып Алексей Ивановның «Тубыл» романына, Александр Дюманың «Королева Марго» романына һәм Оскар Уайльдның «Идеаль ир» пьесасына кадәр дистәләгән картиналар төшерү өчен эшләнгән материалны тәкъдим итә. Экспозициягә 42 костюм комплексы, аксессуар һәм бутафория, шулай ук костюмнар буенча рәссамнарның фильмнарга ясалган эскизлары кертелгән. Күргәзмәне «Эпоха – Модельер» уникаль фотофильмы тулыландыра.

Кабул итү урыннарының Күргәзмә, залы «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

афиша

«ТУГАН БАТЫР» УКЛАРЫ (6+)

Шәһәр диварларын дошманнан саклаучы борынгы сугышчы булып карыйсыгыз килмиме? Яисә берничә дистә елга кире кайтып, ун адымнан ук белән алмага тидерә алырлык малайга әвереләсегез? Алабугада узачак традицион җәядән ату буенча «Туган Батыр» Бөтенроссия турнирында катнашсаң, барысы да чынбарлыкка әйләнергә мөмкин. Ярышлар Болгар чорының борынгы шәһәрлеге территориясендә узачак, килешәсездер, вакыт буенча сәяхәт өчен моннан да яхшы урын булуы да мөмкин түгелдер. Ә турнирда җенесенә, яшенә (ун яшьтән өлкәнрәк), әзерлек дәрәҗәсенә карамастан, Россия Федерациясе һәм дус илләр гражданнары катнаша ала икән, димәк, көтелмәгән нәтиҗәләр, гаҗәеп ачышлар гарантияләнә. Катнашучылар да, тамашачылар да борынгы Болгар цивилизациясенең чыганакларына кагыла, кубызның тылсымлы яңгырашын тыңлый, утта әзерләнгән ризыклардан авыз итә, мастер-класслар һәм һөнәрчелек ярминкәсендә катнаша алачак.

16 сентябрь

Алабуга шәһәрлеге

Алабуга дәүләт тарихи-архитектураю музей-тыюлыгы

Фото: kazan-kremlin.ru, elabuga-rt.ru, tatar-inform.ru, izo-museum.ru, n-teatr.ru/kullervo, russdramteatr.ru

БИТЛӘР ЧӘЧЕЛГӘНДӘ (6+)

Күргәзмәне «Николай Фешин. Когда рассыпались страницы» дип атау идеясе аны оештыручыларда очраклы гына тумый. Остаыныц картиналары һәм скульптураларыннан тыш, экспозициягә аның хатлары һәм автобиографиясеннән өзекләр, аның турында дуслары һәм рәссамнары истәлекләре урнаштырылган. Бөтен мәгълүматны берләштереп, күргәзмәгә килүче кеше бөек рәссам – якташыбыз Николай Фешинның тормышын тирәнрәк күзаллый ала. Экспозициянең бер өлешен Павел Беньков әсәрләре биләп тора. Ике рәссам да Казанда туган, яшьтәшләр, яхшы дуслар һәм башта – Казан сәнгать мәктәбендә, аннары Петербургта, Император сәнгать академиясендә бергә укыган.

30 сентябрьгә кадәр

«Хәзинә» Милли сәнгать галереясы. Казан, Кремль, 3 нче подъезд

РӘСЕМ ОСТАЛАРЫ ДАНЫ (10+)

Петр Кончаловский, Аристарх Лентулов, Роберт Фальк һәм башка танылган рәссамнар – рус «сезанизмы» һәм примитивизмы осталарының ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее коллекциясендә тупланган эшләрен «Бубновый валет» күргәзмәсендә күрергә мөмкин. Революциягә кадәрге Россиянең иң эре күргәзмә сәнгать берләшмәсе вәкилләренең картиналары бүген дә фикер кыюлыгы, форманың оригинальлеге һәм традицион кануннарын кире кагуы белән шаккатыра. Узган гасыр башында күпчелек эшләр шактый тәнкыйтьләнә: аларны тәмамланмаган дип атыйлар, ә рәссамнарны рәсем сәнгате законнарын белмәүдә гаеплиләр. Бу сәнгать белгечләре һәм рәсем сәнгатен яратучылар бүген сокланып караган эшләр.

Сишәмбе – якшәмбе, 11:00 дән 20:00 сәгатькә кадәр

ТР ДССМның Заманча сәнгать галереясы. Казан ш., К. Маркс ур., 57

БОРЫНГЫЛЫКНЫҢ ХУШ ИСЕ (6+)

«Эрмитаж-Казан» үзәге үткәрә торган «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсе буенча арома-экскурсия борынгы заманның иң бөек гаскәр башлыгының хыялына илткән юл турында белү мөмкинлеге генә түгел. Хуш исләр белән өретелгән интерактив экскурсия асылда тарихны кабул итү чикләрен киңәйтергә мөмкинлек бирә. Эрмитаж тупланмасындагы уникаль экспонатлар: корал, бизәнү әйберләре, хәрби киемнәр, савыт-саба, кием, сәнгать әсәрләре (аларның кайберләренә ике мең елдан артык) Александр Македонскийның гамәлләре турында сөйли һәм борынгы заман исләре белән тулыландырыла. Бу исләр борынгы тарихчылар һәм сәяхәтчеләр сурәтләве буенча сайлап алынган һәм яңадан ясалган. Сүз уңаеннан, программа тәмамлангач, күргәзмәнең бер хуш исе экскурсияләрдә катнашучылар арасында уйнатылачак.

һәр җомга 18-00 сәгатьтә

«Эрмитаж-Казан» Үзәге, 3 кат

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

«ТИМЕР» ДӨНЬЯ ПЕРСОНАЖЫ (12+)

Куллерво – «Калевала» эпосының иң бәхәсле һәм каршылыклы персонажларының берсе. Бу геройны сайлап, режиссер Вячеслав Поляков, беренче чиратта, мәхәббәт һәм аннан мәхрүм ителгән кеше турында сөйләргә уйлый. Куллерво кешеләрнең ваемсызлыгы, санга сукмавы һәм нәфрәте шартларында үсә. Ул бары тик җимерергә һәм үч алырга өйрәнгән, ул үзе өчен башка дөньяны күрми. Геройлар уртача «тимер» дөньяда яши. Анда чылбырлар шалтырый һәм сугыш шомы хөкем сөрә, ә караңгыда һәм кызгылт ут шәүләсендә биешкән тимер калайлар, тартылган нерв җепселләре кебек, күк белән җир арасындагы кичерешләр агымын үткәрә – бу баш тәңре Уккодан Маналаның иң ерак почмакларына кадәр җибәрелгән хисләр дулкыны. Монда хәтта хайваннар да – тимердән, алар салкынлык, ваемсызлык символы булып тора. Шомлы музыка сәхнәне биләп ала, хәрәкәт белән үрелеп бара, ул, эпос геройлары белән берррәттән, серле дөньяда яшәүче тулы персонажга әверелә.

21 сентябрь 18:00 сәгатьтә

Карелия Республикасы Дәүләт милли театры – Әлмәт татар драма театры бинасында, Зур зал. Әлмәт ш., Ленин ур., 37

«МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТАТАРСТАН!»

Җәйнең соңгы көннәренә республикабызның зур бәйрәме туры килә. 30 августта республика халкы Татарстан Республикасы көнен билгеләп үтә. Быел да бәйрәм чаралары башкаланың төрле мәйданчыкларында, район җирләрендә оештырылды.

Бу көнне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында Казанның Совет районында Нокса елгасы буенда яңа парк ачылды. Кабан күле буенда, Кремль ярында киң колачлы бәйрәм чаралары үтте. Чараларның берсе – ишетмәүчеләр өчен ишарәләр белән җырлый торган «Игелек дөньясы» төркеменең Кабан күле яры буенда уздырылган концерты.

Төп бәйрәм чарасы гадәттәгечә «Казан» гаилә үзәге янында оештырылган иде. Зур бәйрәм концертында татар эстрадасының танылган җырчылары Ришат Төхвәтуллин, Алия Карачурина, Гүзәл Уразова, Илдар Хәкимов җырлады. Бәйрәм чарасының хедлайнерлары булып рус эстрадасының популяр артистлары Клава Кока һәм Jony чыгыш ясады. Татарстан Республикасы көне уңаеннан Казансу елгасы өстендә музыкаль бәйрәм салюты атылды. Салют вакытында «Казан» гаилә үзәге янындагы сәхнәдән Салават Фәтхетдиновның «Мин яратам сине, Татарстан» җыры да яңгырады.

Фотохәбәрчебез әлеге чараларда булып, укучыларыбызга бәйрәм мизгелләрен тәкъдим итә.

Александр Ефремов фотолары



Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+